Безнең Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

08

август 2018

ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

МӘХМҮТ ГОСМАНОВ. «ИРТӘ. ИДЕЛ КИҢЛЕКЛӘРЕ».

Фото http://president.tatar.ru сайтыннан алынды

IX Бөтенроссия авыл Сабан туе

14 июль көнне Курган өлкәсенең Әлмән авылында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Курган өлкәсе губернаторы Алексей Кокорин һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашында IX Бөтенроссия авыл Сабан туе узды. Милли көрәшнең баш батыры булып Башкортстан Республикасыннан Рәдиф Акчурин калды. Киләсе елгы Сабан туен уздыру эстафетасы Самара өлкәсенең Камышлы районына тапшырылды.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
08 (296)
август 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

93

30 БӨЕКЛӘРНЕҢ ТУГАНЛЫГЫ. *Ринат Нуруллин*

62 ЧУАШЛАР. *Зариф Бәшири*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Равил Фәйзуллинга — 75 яшь!*
Триптих. *Равил Фәйзуллин*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Гәүһәршад.** *О.Иванова*
8 **Казан ханлыгының язмышы.** *Б.Хәмидуллин*
14 **Пугачев полковнигы Мәсәгуть Гомәров.** *В.Имамов*
16 **Татар телен гамәлгә кую мәсьәләләре.** *Х.Габидуллин*
20 **Эчкен татарлары.** *Р.Исакаев*
24 **Нигъмәтулла хаҗи.** *Р.Фәхреддин*
30 **Бөекләрнең туганлыгы.** *Р.Нуруллин*
36 **Мәгърифәт мәркәзе — Мәчкәрә.** *Р.Шәрәфиева*
40 **Японияне ачкан татар галиме (Әбрар Кәримуллин язмаларында япон темасы).** *Ф.Бәйрәмова*
45 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**

ТАТАР ГАМЕ

46 **Республикабызга һәм татар халкына фидакарь хезмәт итүче**
48 **Кукмара муниципаль районы башлыгы Сергей Димитриев: «Кукмараның төп байлыгы — аның халкы»**
50 **Үз заманын узып яшәде ул...** *Г.Морат*
54 **Данлы төбәк — Кукмара**

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

60 **Чуашның мәшһүр улы**
62 **Чуашлар.** *З.Бәшири*

ДИНИ МИРАС

68 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

72 **Аяз Гыйләҗевнең «Яра» романында милли һәм дини мотивлар.** *Рәҗәп Шүкрү Гүнгөр*
76 **Әсәрләрендә — милли керәш рухы.**
80 **Дуслыгыбыз гомерлек булды.** *К.Саттаров*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89520365448

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Бүлек мөхәррире
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

84 **Муса Җәлил**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

86 **Батыр йөрәкле Зәйнәп.** *И.Салихҗан*
92 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

93 **Әз-мәз үзем турында.** *Р.Шәрәфи*
98 **Җырлар артыннан илләр гизеп... (Фольклорчы көндәлегеннән).** *Э.Каюмова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

102 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
108 **«Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем...»** *Л.Мөхәммәтшина*
112 **Киез итекләр иле**

ЯҢА КИТАП

116 **Гамьле мирас.** *М.Хәйруллин*

118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Август*

Заказ №Е-1879. Тираж – 2230 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 25.07.2018
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Леpон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Иртә. Идел киңлекләре».
Мәхмүт Госманов рәсеме

ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ,
Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА – 75 ЯШЬ!



Равил Фәйзуллин

ТРИПТИХ

I

Туган җирең чүл булса да,
күңелдә ул гөл генә!
Ватан катлы-катлы булмый,
Ватан була бер генә!

II

Акыл да бар, каләм дә бар...
юк шул билдә... балтасы!
Өтек шул Шартнамәне дә
Турамакчы мең кайчы!

III

Кылычтан качып, «дуслык»ка –
(коллыкка) юл – иелү...
Тарих белми: Ирек өчен
кан түкмичә җиңүне. ■

Гәүһәршад

Ольга Иванова

Юлга кузгалыр алдыннан, Нурсолтан хан остаханәсенә барды. Кайткан көннәрендә үк ул бирегәге кул осталарыннан йөз бөркәнчекләре чигеп бирүләрен сораган иде. Кара челтәрле япмаларны ул Бакчасарайдан ук алып кайтты, шулай да, тыгыз ефәккә Казан Иле җыр кебек җиңел һәм нәфис бизәкләре белән җан өреп җибәрсен иде, дип теләде. Оста ханымнар аның үтенечен җиренә җиткереп үтәгәннәр дә хуҗабикәнең килеп алганын гына көткәннәр икән. Нурсолтан элеп куелган япмалар рәтен карап узды, чигүчеләрнең осталыгына соклануын яшермәде. Куе яшел ефәктә беренче нәфис яфраклар арасында энҗе белән чигелгән кардай ак чәчкәләр бөрчекләнеп тора. Вәлидәнең яраткан зәңгәр төсендәге ефәкне исә көмеш ука бизи, ә аңа Бадахшаннан кайтарылган күксел ләҗүрд ташы[1] беркетелгән. Бу кыйммәтле асылташ изге санала һәм дөньяның бер генә төшендә – баруы да, менүе дә кыен булган Көньяк Һиндукуш таулары итәгендәге Сары-Санги[2] базларында гына табыла икән. Ә шәмәхә бөркәнчеккә алтын чигеш, нәфис-алсу мәрҗән һәм энҗе бөртеге хуш килгән.

Нурсолтан бай бизәкләргә, төсләрнең зәвык белән чиратлашуына, асылташларның тылсымлы төсләргә кереп ялтыравына сөенеп карап торды. Ул белә: аны Казан осталарының хезмәте әле бик озак, бәлки, гомеренең соңгы көннәренә кадәр бизәп торыр. Ерак Бакчасарайда, Идел ярларындагы хатын-кызларның кул һәм йөрәк җылысын саклаган бөркәнчек белән Кырым вәлидәсе дә үзен болай ук ялгыз итеп санамас.

Бу көннәрдә ана кеше, ниһаять, улы белән ачыктан-ачык сөйләшергә җыенды. Шигърият яки ак таштан ясалган гөл-биналар турында түгел, ә күзгә күренмәс булса да, йөрәген әрнеткән, аңа агулы ук булып кадалган хәл-әхвәлләр, яшәү яки үлем хакында булырга тиеш иде ул сөйләшү. Нурсолтанның сүзе Мәскәү белән Казан арасындагы мөнәсәбәтләрдән башланды. Өлкән улы аны игътибар белән тыңлады, гадәтенчә тәсбих төймәләрен бармаклары белән барлап, анасының дулкынланудан янган йөзенә шундый якын, зәңгәр күзләрен төбәп карады. Ә Нурсолтан беренче тапкыр сүзен төзек һәм матур итеп оештыра алмады, буталчык итеп сөйләде, йөрәгендә еллар дәвамында, элекке заманнардан ук җыелганны тизрәк түгеп өлгерәсе килгәне тышка бәреп чыкты:

– Улым, тыңла әле, бу сүзләремдә йөрәгемнең бер өлеше ятканны кабул ит. Әниеңнең

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

[1] Ләҗүрд – лазурит (тәрҗ. искәрмәсе).

[2] Сары-Санги – Әфганстанның төньяк-көнчыгышындагы лазурит табыла торган төбәк.

«Нурсолтан». Рәссам Рушан Шәмсетдинов эше

уй-ниятләренә ышан: алар изгелек һәм хакыйкатьне тануга юнәлгән. Әтиеңнең язмышы миңа да кадерле, Мөхәммәдәмин, анда гомеремнең, җанымның яртысы калды, аны мин үзем белән йөртәм, әмма Кырымга алып китә алмыйм. Синең яныңда явыз телле, ач күзле әмирләрне күреп, йөрәгем әрни. Алар мәкерле гамәлләре, догаларыбәддогалары белән сине бервакыт атаң юлыннан яздырганнар иде инде. Энекәшең Габделлатыйфны да аларның кабахәт ялалары харап итте! Үз өметләреңне карачылар белән бәйләмә, улым, аларга карама. Йөзеңне чынлап торып дошманың санаган затка – кенәз Василийга таба бор. Дошманыңны дустың һәм яхшы күңелле туганың ит, чөнки урыс кенәзе генә тәкәббер, әшәке күңелле әмирләрне синең сүзеңне тыңларга, үзеңне хаким буларак хөрмәтләргә мәҗбүр итә алачак. Мәскәүдән кыска гомерле солых түгел, ә мәңге тыныч яшәүне, хезмәттәшлек итүне сора! Василий алдында үзеңнең гөнаһларың – урыс гаскәрен тар-мар китереп, Мәскәү калаларын таларга баруың өчен тәүбә ит. Василий тәүбәңне кире какмас, аңа хәзер Казан белән орышу һич тә файдага түгел. Әгәр яхшы ниятле, нык солых төзесәң, яшерен дошманнарың чигенер, кояш нурлары астында калган юеш томан кебек таралышыр. Болай итсәң, энекәшеңә, карындашыңа да урыслар җирендә яшәү җиңеләер, ул Юрьев белән иркенләп, тыныч кына идарә итә алыр иде. Сине яраткач, Мәскәү патшасы да Габделлатыйфны үзенең дусты итеп ныграк таныр, үз иленә сыендырган туганы күреп, ярата башлар!

«Габделлатыйф хан».
Рәссам Рушан Шәмсетдинов рәсеме

Ананың сүзләре ташкын булып акты да акты, Казан ханының йөрәгенә мөлдерәмә кереп тулды. Мөхәммәдәмин үзе дә күп очракта әнисе кебек үк уйлый, Нурсолтанның сүзләре аны хак юл сайлаганына инандыра гына бара иде. Ул инде бөек кенәз Василий III белән сөйләшүләр алып бару юлына басты. Ике ел элек, Мәскәү сүзенә колак салып, соңгы тар-мар итү сугышларында әсирлеккә төшкән урысларны иреккә чыгарды. Хәзерге кенәзнең атасы Иван заманында ук Мәскәү-Кырым арасында күптән яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыруга ирешкән вәлидә аша урыслар белән солыхны, тынычлыкны тагын да ныгытырга кирәклеген аңлый иде ул. Әнисен шундый изге ният белән аңа Ходай Тәгалә җибәрмәдеме икән? Дөрес, хан хакимиятне, байлыкны үзләренә тиз генә умырып алырга торган сукыр түрәләрдән, әмирләрдән күпкә ераккарак карый. Әгәр ул хәзердән үк ныклы килешүгә ирешмәгән булса, җилкәсен киреләнепборгаласа, урыс җирләрен таларга кешеләрен тагын җибәрсә, Мәскәү, озакламый Казаннан өскәрәк калкып, Русь ханлык өстенә аю кебек килер дә ябырылыр, ә казанлыларның ул аюны җиңәрлек көчләре күптән бетеп бара.

«Хан кызы».
Рәссам Искәндәр
Рәфыйков эше

Мөхәммәдәмин җитди, уйчан йөзен әнисенә таба борды. Нурсолтан аның каршында кулларын күкрәгенә кушырып, намаз укыгандагы кебек ялварып басып тора, улының башында нинди уйлар кайнаганын күзәткән шикелле иде. Казан ханы әнисенә таба атлады, аны кочагына алды. Мөхәммәдәминнең куллары шултиклем көчле, ышанычлы һәм тынычландыргыч булып тоелды ки, вәлидә мәңге шулай, улының иңенә башын салып басып торыр иде. Улы Габделлатыйф белән дә аңа бу кадәр тынычлык иңгәне булмады, ә үзен һаман да ят иткән кызы турында ана бөтенләй уйламаска тырышты. Бу мәлдә Нурсолтанның йөрәген әрнеткән ике генә баласы, ике генә мәхәббәте бар – Габделлатыйф белән Мөхәммәдәмин.

– Курыкмагыз, әнием, – диде хаким әкрен генә, – мин барысын да Сез теләгәнчә эшләрмен. Дошманнарыбызны без бергәләп җиңәрбез, иншә Аллаһ. Казан тәхетенә читләр аягы баса алмас, ышаныгыз, минем вәлидәм...

*Урысчадан **Мөдәррис Вәлиев** тәрҗемәсе*

Дәвамы бар ■

Казан ханлыгының язмышы

Булат Хәмидуллин

Кенәз Василий III һөҗүмнәре һәм Васильсурск белән Зөя калалары төзелү

Мәскәү тарафыннан тәкъдим ителгән Шаһгали ханның Казан тәхетеннән куылуы, Кырым гаскәрләренең Мәскәүгә һөҗүмен Сәхибгәрәйнең дә хуплавы һәм Казандагы «гарасат вакыйгалары» эзсез югалмый. 1523 елда кенәз Василий III, зур гаскәр туплап, Казан тарафына яу оештыра. *«Ул Сәхибгәрәйне рәсми хан итеп танымаган»*, – дип яза тарихчы С.М.Соловьев. Кенәз яугирләре сафларында касыймлы татарлар төркеме дә була. Бөек кенәз Түбән Новгород каласына гына килеп, үзенең яраннары белән шунда торып кала, гаскәр исә Казан тарафына юлын дәвам итә. Ике өлешкә бүленгән әлеге зур гаскәрне кенәз Борис Горбатый һәм воевода Василий Немой җитәкли. Б.Горбатый җитәкчелегендәге төркем Идел буйлап көймә-корабларда, икенче төркем яр буйлап җәяү хәрәкәт итә. Иделгә коючы Сура елгасы тамагында – Казан ханлыгы чигендә алар бергә кушылалар.

Яугирләр Казан ханлыгы биләмәсенә кергән мари авылы Цепель янәшәсендә яңа кальга төзергә керешәләр. Башта аңа Васильев Новгород исеме бирелә. Соңрак ул кирмән Васильсурск дип аталган калага әверелә. (Ул хәзер дә бөек кенәз Василий IIIкә нисбәтле исемне йөртә.) Киләчәктә бу кальганың төзелүен байтак белгечләр *«күрше дәүләт биләмәсен басып алу»* дип бәяләячәкләр. Шул вакыйганың замандашы, Австрия дипломаты, кенәз Василий III даирәсендәге кешеләр белән якыннан аралашкан Сигизмунд Герберштейн да әлеге хәлләрне үз сәяхәтнамәсендә терки: *«Рус гаскәрләре Казан ханлыгын яулап алу нияте белән шул адымны ясады. Бу кальганың төзелүе күп кенә бәлаләргә китерде»*, – дип яза. Әлеге илбасарлык гамәлен хуплаган Мәскәү митрополиты Даниил исә: *«Бөек кенәз шул кальга ярдәмендә тиздән барлык Казан ханлыгы*

«Шаһгали хан». Рәссам Рушан Шәмсетдинов рәсеме

*Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында

җирләрен яулап алачак», – дигән. Бу чор тарихының зур белгече М.Г.Худяков чит дәүләт җирендә крепость төзүне Мәскәү кешеләренең дә күпчелеге хупламаган, дип фикер йөртә. Р.Фәхреддин бу вакыйганың сәбәбендә Сәхибгәрәй ханның да өлеше бар, Казанда оештырылган үтерешләргә ул җитәкчелек иткән, дип саный.

Дошман көчләренең ханлык биләмәсендә кала төзи башлавы да сәер хәл. Ул заманнарда чик буйларын даими рәвештә саклау оештырылмаган шул. Мөгаен, әлеге бурыч чиктәге төбәкләрнең ыру башлыкларына һәм аларның гаскәри берәмлекләре карамагына калдырылгандыр. Тагын чирек гасырдан соң Казаннан кул сузымы ераклыгында – Зөя елгасы тамагында икенче бер дошман кальгасы – Зөянең (Свияжскиның) бина кылынуы – татар ханлыгы язмышының зур фаҗигасе. Шул вакыйгаларны да истә тотып булса кирәк, Россиянең атаклы тарихчысы, татар морзалары токымыннан чыккан Н.М.Карамзин, яңа оешкан татар ханлыклары турында сүз барганда: *«Татарлар – оста сугышчылар, ләкин ил, дәүләт белән идарә итәргә осталыклары җитенкерәмәгән»*, – дигәнрәк сүзләр язып калдырган, дип хәбәр итә Р.Фәхреддин «Казан ханнары» китабында. Бик хак әйтелгән сүзләр.

Василий III (1479-1533), 1505 елдан башлап, утыз елга якын Мәскәү кенәзлеге идарәчесе була. Берничә күрше рус кенәзлеген, шулай ук Бөек Литва кенәзлегенең зур бер өлкәсе үзәге булган Смоленск каласын да (1514) яулап ала. Аның атасы Иван III тә шундый ук яугир табигатьле зат була. Ул элек-электән Мәскәүгә карата сырт беләнрәк торган өч кенәзлекне (шул исәптән иң озак каршылык күрсәткән Тверь кенәзлеген дә) һәм иректе Новгород Республикасын, Казан ханлыгына орынып торган Нократ төбәген яулап алуга ирешә. Димәк, бөек кенәз Василий III заманында Мәскәү кенәзлеге җир биләмәләренең күплеге белән дә, гомуми халык саны буенча да Казан ханлыгыннан күпкә өстен чыга. Ихтимал, 1487-1521 елларда Казан ханлыгы тикмәгә генә Мәскәүгә карап яшәргә мәҗбүр ителмәгәндер. Безнең тарихта бу еллар «Мәскәү протектораты чоры» дип билгеләнгән, дидек. Кырым ханы Мөхәммәдгәрәйнең Мәскәүгә оештырган явыннан соң гына ул бәйлелек бераз кими төшкән.

Мәскәү гаскәрләренең Казан тарафына яуга җыенуын ишеткәч, Сәхибгәрәй 1523 елда, ярдәм сорап, Кырым ханлыгына чапкын җибәрә. Аннан ярдәмгә яшүсмер Сафагәрәй җитәкчелегендәге бер кечерәк гаскәри берәмлек кенә килә. 1524 елның башында хан шундый ук үтенеч хатын Төркия солтанына да юллый. Илчеләр аннан буш кул белән кайта. Урта Идел буенда – бик еракта урнашкан ханлык язмышы ул вакытта Төркия идарәчеләрен борчымый, ярдәм килми. Шиһабеддин Мәрҗани дә Болгар белән Казан дәүләтләре тарихына багышланган хезмәтендә Төркиянең 1520-1566 еллардагы идарәчесе солтан Сөләйман Кануниның ул чорда күбрәк Көнбатыш Европа илләрен яулауга йөз тотканлыгын билгеләп үтә, *«Казан илә Дәште кыпчак тирәләренең көчәюләре Төркия өчен файдалы саналмаган»*, дип яза.

Кенәз Василий III, Казанны яулап алу өчен, 1523 елда 150 мең кешелек гаскәр туплаган була. Җәяүле гаскәрнең авангард өлешен 18 яшьлек Касыйм ханы Шаһгали җитәкләве турында мәгълүмат бар. (Шаһгалинең киләчәктә дә, Мәскәү кенәзлеге гаскәрен әйдәп авангардта барып, үз атлылары белән Ливон сугышында һәм башка сугыш вакыйгаларында катнашуы да тарихи язмаларда һәм хезмәтләрдә теркәлгән. *«Болар дошман өстенә башлап ташлансын, аннары без ярдәмгә килербез»*, – дигән тәртип патша армиясендә шул заманнан бирле гамәлдә була.)

Мәскәү явы Казанга якынлашып килгәндә, 1524 елның язында Сәхибгәрәй хан Казаннан китәргә карар кыла. Шулай ашыгып китәргә теләвен ул хаҗ кылырга ниятләве белән аңлатса да, сәбәбе аның Мәскәү тарафыннан зур яу килүен белгәч тәхеттән ваз кичүе дип фаразлана. Сәхибгәрәйнең чынлыкта хаҗга бармаганлыгы, Кырым

«Сәхибгәрәй хан». Рәссам Рушан Шәмсетдинов эше

тәхете өчен Мөхәммәдгәрәй хан үтерелгәннән соң башланган көрәштә катнашырга ниятләгәнлеге мәгълүм булачак. Казан тәхетендә ул бертуганының улын, яшүсмер Сафагәрәйне калдырып китә. Соңрак, 1538 елда, Иван IVкә – кенәз Василийның улына язган хатында Сәхибгәрәй хан Казанны калдырып китү вакыйгасын туган-үскән Кырымын сагынуы, анда кайту теләге булуы белән аңлатырга тырыша. Әйе, Сәхибгәрәй ул вакытта Кырым тәхете өчен көрәштә катнаша. Әмма үз максатына 8 елдан соң – 1532 елда гына ирешә. Миңлегәрәй ханның вафатыннан соң, Кырым тәхетенә идарәчеләрне Төркия солтаны билгели башлый. Максатына ирешү өчен, Сәхибгәрәйгә дә берничә ел Төркиядә яшәргә туры килә, М.Г.Худяков бу вакыйгага нисбәтле рәвештә: *«Сәед Мөхәммәд Риза, Сәхибгәрәй, изге урыннарга тәкъва сәфәр кылу сылтавы белән, кодрәтле*

солтан Сөләйман бусагасына барып сыенды», – дип яза. Сәед Мөхәммәд Риза – «Кырым ханнары тарихы» китабы авторы. Алдарак әлеге китап турында сүз булыр әле.

М.Г.Худяков элегрәк аталган хезмәтендә Сәхибгәрәй турында: *«Хан буларак үзен Казанда танытып өлгерә алмады, ә Кырымда зур уңышларга ирешә»*, – дип ассызыклый. Ләкин бу ханның, яшьләрчә дуамалланып, күрше дәүләт илчеләрен һәм сәүдәгәрләрен таларга һәм үтерергә юл куюы Казан ханлыгы тарихында тап булып калачак.

Сафагәрәй белән Василий III: килешүләр һәм яңадан һөҗүм

Казан тәхетенә 1524 елда яшүсмер Сафагәрәй утыртыла. Аның Казан тәхетенә тәгаенләнүен элек Мәскәү тарафдарлары булган ыруг башлыклары, шул исәптән олуг карачы бәк Булат Ширин дә, башка бәкләр дә хуплый. *(Ханлык хөкүмәтен – диванын ханлыкка кергән дүрт эре ыруг башлыгы – Аргын, Барын, Кыпчак, Ширин ыруглары бәкләре җитәкли. Олуг карачы бәкне, ягъни әлеге бәкләр өстеннән идарә иткән затны «бәкләр бәге» рәвешендә дә күрсәтәләр. «Диван» буларак аталган әлеге хөкүмәт исә ханга идарә итүдә булышырга тиеш булган. Кирәккәндә зур гаскәр туплауда, чит илләр белән элемтә тотуда, солых килешүләрен төзүдә катнашу – шушы бәкләрнең төп бурычы саналган. Ханнарны билгеләүне һәм төшерүне дә алар хәл итә алганнар.)*

Мәскәү гаскәрләре Казан тирәсенә шул елның июль урталарында килеп җитә. Дошман явына каршы көрәшне ыруг башлыклары оештыра. Хәер, берәр төрле яу килгәндә, яисә яуга чыгасы булганда да ханлык гаскәре элек-электән алар тарафыннан тупланган. Гаскәр туплау бурычы, әйтелгәнчә, әлеге диван әгъзалары карамагында була. Хан кул астында фәкать аның аз санлы сак гаскәре генә исәпләнгән. Бу юлы да ыруг башлыклары яшь хан белән бергә зур гаскәр туплап өлгерәләр. Тау ягы, чирмеш һәм чуаш төркемнәре дә беркадәр ярдәм иткән. Идел буйлап килүче дошман гаскәренә каршы алар да һөҗүмнәр оештырган, дип яза Р.Фәхреддин. Шул вакытта мәскәүлеләрнең зур көймәләргә урнаштырылган берничә тәфәнгесе – тубы да су астына киткән икән.

Р.Фәхреддин: *«Бу вакытта казанлылар гаскәре башында Отуч бәк белән Аталык бәк торган»*, – дип хәбәр итә. Ә М.Г.Худяков мәгълүматлары буенча, Талыш Аталык дип йөртелгән зат яшүсмер хан Сафагәрәйнең бер остазы, тәрбиячесе була. Канкойгыч зур сугыш Казан диварлары янында берничә көн дәвам итә. Елъязмада: *«Дошман көчләре шәһәрнең гади халык яшәгән өлешен – посадны алып, күп кешене үтерде, йортларны җимерде ... ләкин Кремльгә үтеп керә алмыйлар»*, – дип хәбәр ителә. Бу сугышта Мәскәү кенәзлеге гаскәренең 50 меңләп гаскәрие һәм барлык көймә-кораблары юк ителә. Казанлылар арасында да югалтулар шул чама булган, дип фаразлана. Ризаэддин Фәхреддин дә «Казан ханнары» китабында: *«Казанлылардан яралы һәм үлүчеләр барлыгы 42 мең булмыштыр»*, – дип яза. Бу вакыйгаларда яшүсмер Сафагәрәй хан да, кулына кылыч алып, яугир буларак таныла. Сәлам Алишев әлеге сугыш барышының Австрия дипломаты Сигизмунд Герберштейн китабында да чагылуын искәртә. Шул ук автор, рус тарихчылары хезмәтләренә нигезләнеп, 1524 елда Сафагәрәйнең Мәскәү кенәзлегенең өстенлеген таныганлыгын да хәбәр итә («Сафа-Гирей дал шертную грамоту Василию III, признав свою зависимость от Москвы»). С.М.Соловьев, кенәз Василий да Сафагәрәйне Казан ханы буларак тануын белдерә, *«но против воли»*, дип яза.

Ә киләчәктә бу хан әлеге «шертная грамота»да биргән антын бозачак. Кайбер хезмәтләрдә ул үзен гайрәтле, булдыклы гаскәр башлыгы буларак та, дипломат буларак та танытырга тырышачак, диелә. Шагыйрь Шәриф Хаҗитархани казанлыларның чираттагы, 1550 елгы җиңүенә багышлап иҗат иткән «Зөфәрнамәи вилаяте Казан» («Казан вилаятенең җиңүе») әсәрендә бу вакыйгага чаклы ук вафат булган Сафагәрәйне

оста җитәкче, батыр яугир буларак искә ала; дөресрәге, 1550 елга чаклы булган вакыйгаларны тасвирлаганда фәкать аны гына аерып, *«куркусыз бер гаскәр башлыгы һәм каләм сахибе»*, дип атап үтә. Аны «әгәр җәфалаучылардан үч алсам, изге динем яклап аламын» рәвешендәрәк уйлар белән гаярьләнеп яшәүче ил башлыгы итеп күрсәтергә тырыша. (Шагыйрьнең бу дастаны 1990 нчы елларда Төркиядән Казанга кайтарылды. С.Х.Алишевның бер хезмәтендә ул Казан шагыйре буларак искә алына.) *«Казанга һичбер җирдән ярдәм һәм таяныч ирешмәс, бары тик Тәңре якын вә фәрештәләр ярдәмче. Шушы авыр сәбәптән Казан иленең падишаһлары кяфер иле (ягъни Мәскәү) белән килешүләре аркылы мәмләкәтләренең җитешлеген тәэмин иттеләр... Мәскәү белән солых булып, ике арада илчеләр йөрешкән. Шулай аңлашып һәм барышып-килешеп йөрмәктә иделәр... Инде кылыч һәм каләм сахибе, асыл нәселле, затлылык чишмәсе, Тәңренең рәхмәтенә тиенгән, Тәңре ярлыкавын алган Әбелгазый Сафагәрәй Баһадир хан Казан өлкәсенә падишаһ булгач, кяферләр аның бу дөньядагы дине һәм ахирәттәге йортыннан аерылмаслыгын белде»*, – дип, шагыйрь Сафаны мактап искә ала.

Әйе, Сафагәрәй Казанда егерме елдан артыграк идарә иткән дәвердә *«кылыч белән дә, кулга каләм алып, солых-килешүләргә ирешү юлы белән дә»* дошманны Казанга яу чабулардан берникадәр вакыт тоткарлап торуга ирешә алган. 1524 елгы зур сугыш-бәрелештән соң ук бу хан һәм аның идарәдәшләре Мәскәү белән солых килешүен төзү карарына килә. Әмма солых карарына килү өчен 1525 елда башланган утырышлар 2-3 ел нәтиҗәсез дәвам итә. Мәскәү кенәзлеге җитәкчеләре Казан ханлыгын үз йогынтылары даирәсендә калдырырга, элекке протекторат тәртипләрен сакларга тырышалар, кенәз Иван III Казанны бер яулап алды, буйсындырды бит инде, шул тәртип сакланырга тиеш, дип дәгъва белдерәләр. Казанлылар исә андый таләпне кире кагалар. Австрия дипломаты Сигизмунд Герберштейн язмаларында бу солых килешүе мәсьәләсенә карата: *«Мәскәүгә икенче баруымда, 1526-1527 елларда, Казан илчеләре әле шунда иде. Әмма ике дәүләт арасындагы солых килешүенең хуплануына өмет юк иде»*, – дип яза. Бу елларда Мәскәүдә Казан ханлыгы вәкилләре буларак Чура Нарыйк улы, Табай, Данай бәкләр, Тәвәккәл (Тәвкил) һәм Ибраһим бакшилар (сәркатипләр) катнашкан. Алар Мәскәү кенәзлегеннән соңгы сугышларда әсир ителгән якташларын һәм мылтык-коралларны (пищальләрне) кайтарып бирүне дә таләп иткәннәр. Мәскәүлеләр дә аларга шундый ук таләп куйганнар, ханлыкның элеккечә үк Мәскәү йогынтысында калуын, ханнарның бөек кенәз белән килешеп билгеләнүен теләүләрен белдергәннәр. Ике як та үз сүзен сүз итәргә тырышуы сәбәпле, бу очрашу уртак нәтиҗә бирми. Әмма ул еллар ике тарафтан да яу-һөҗүмнәрнең оештырылмавы белән тарихта калган.

Биш елдан артыграк тыныч яшәгәннән соң, 1530 елның язында Василий III яңадан Казанга яу белән бару хәстәренә керешә, гадәттәгечә ике төркемгә бүленгән зур гаскәрен Казанга каршы җибәрә. Идел буйлап йөзеп килгән флотилия башлыклары итеп Ф.И.Бельский белән М.В.Горбатов кенәзләр, коры җирдән килүче гаскәр башлыклары итеп М.Л.Глинский белән В.А.Шереметев билгеләнгән була. Казанлылар да ул яу киләсен белеп, Нугай Урдасы белән Әстерхан ханлыкларыннан һәм мари ыругы башлыкларыннан ярдәм сорап, аерым гаскәри берәмлекләр туплап өлгерәләр. Күренекле тарихчы В.Н.Татищев ике якның да гаскәре йөз мең кешедән ким булмаган, дип хәбәр итә. Башка тарихчылар исә көчләр тигез булмаган, дип исәпли. Июль урталарында Казан диварлары тирәсендә аяусыз сугыш башлана. Тарихчы С.М.Соловьев, мәскәүлеләрнең туп һәм мылтыклары яу барышында юкка чыгуы сәбәпле (*«потеря наряда пушек и пищалей»*), Казан кирмәне яулап алынмый калды, дип яза. Дошманны шәһәргә кертмәс өчен, казанлылар ясак түләргә ризалашалар һәм 30 июльдә сугышны тәмамлау турында уртак килешү хуплана. Бу килешүне оештыручылар Булат, Табай

бәкләр, Апай углан була. Мәскәүлеләр гаскәре, түләнгән ясакка ризалык белдереп, кайтып китә. Шушы солых шартнамәсендә Сафагәрәйне Мәскәү кенәзлеге исеменнән кабат хан буларак тану пункты да теркәлә.

1532 елның гыйнварында Сафагәрәй хан, әлеге солых килешүен бозып, Түбән Новгород тирәләренә зур һөҗүм оештыра. Башлыча күрше ил яисә ыруг халкын талау нияте белән оештырылган мондый яулар төрки әдәбиятта, гадәттә, *«барымтага бару»* дип атала. Шушы барымтаны оештыручы хан шул ук вакытта Казанга килгән Мәскәү илчеләрен кулга алырга да боерык бирә. Күрше дәүләт илчеләрен кулга алу вакыйгасы Казан халкына, ханлыкның бәк-морзаларына ошамый. Һәм шул елның язында идарәче бәкләр утырышында Сафагәрәйне тәхеттән төшерү мәсьәләсе куела. Бу карар кабул ителә. Ханның үз ырудашлары белән нугайлардан торган сак гаскәре өлешчә кырыла. Яңа вакытлы хөкүмәт оештырыла. Аны җитәкләүчеләр Ибраһим хан кызы Гәүһәршад (кайбер чыганакларда ул Хөршидә буларак та теркәлгән) белән диван башлыгы, олуг карачы бәк Булат Ширин була. Алар төркеменә кергән бәк-морзалар Кырымнан килгән төркем йогынтысы көчәюенә каршы чыгалар. Мәскәүгә алар: *«Бөек кенәз безгә үзе теләгән кешене куйсын»*, – дигәнрәк эчтәлекле хат юллыйлар, диелә. Р.Фәхреддин: *«Мәскәүгә илче буларак җибәрелгән Табай бәк төркеме казанлыларның кырымлылар идарәсен кабул итмәвен, Казанга Шаһгалине кайтаруны сораганлыкларын белдерә»*, – ди. Соңрак илчеләр Василий кенәздән: *«Шаһгали урынына Җангали булсын»*, – дип үтенәләр. Шаһгалинең, Казанга килгәч, элек үзен тәхеттән төшерүдә катнашканнардан үч алуы, җәбер вә золым кылуы ихтималыннан шикләнәләр, дип яза Р.Фәхреддин. Бу илчеләр Җангалине Васильсурск каласына чаклы озата барачакларын да белдерәләр. Касыйм ханлыгы тарихы белгече В.В.Вельяминов-Зернов фикеренчә, *«Бөек кенәз вәкилләре Түбән Новгород каласында чакта Җангалидән Мәскәү кенәзлегенә турылыклы булып калачагы турында ант иттерәләр»*.



«Сафагәрәй хан». Рәссам Рушан Шәмсетдинов рәсеме

Дәвамы бар ■

Редакциядән:

Даими авторыбыз, танылган галим, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүләге иясе **Булат Лирон улы Хәмидуллин***га 13 нче августта 50 яшь тула. Аны гомер бәйрәме белән котлап, сәламәтлек, иминлек һәм игелекле олы хезмәтендә уңышлар телибез!*

Пугачев полковнигы
Мәсәгуть Гомәров

Вахит Имамов

Горелов Г.Н. «Казанда Пугачев суды»

Мәсәгуть Гомәров 1746 елда туган. Татарстандагы Кукмара районының Пычак авылыннан. Казан Адмиралтействосына беркетелгән лашман, ягъни урман кисүче, агач хәзерләүче. Баш күтәрүчеләргә 1773 елның ноябрендә кушыла. Үзенең туган төбәгендә, Казан өязенең Арча юлында отряд туплый башлый. 200 кешелек отряд белән ул әүвәл сәүдәгәр И.Осокинның Бемыш заводын, хәзерге Удмуртиядәге Аргабаш, Кизнер авылларын, Кобелевларның Пыжман заводын ала, 7 тупны кулга төшерә. Соңрак Асаф Иноземцевның Туеш заводы һәм андагы 4 туп та мәсәгутьчеләргә күчә.

Декабрь аенда Мәсәгуть кул астында тупланган баш күтәрүчеләр саны 1700гә җитә. Гомәров үзе полковник дәрәҗәсен йөртә башлый (кайбер мәгълүматларга караганда, ул декабрьдә Бирдәгә бара һәм Пугачев шәхсән үзе аңа полковник дәрәҗәсен бирә). Бүгенге Татарстанның – Кукмара, Мамадыш, Саба, Арча, Балтач, Питрәч; Киров өлкәсендәге – Нократ Аланы, Малмыж; Удмуртиядәге Кизнер, Бемыш районнарындагы бик күп авыл крестьяннары Мәсәгутьне үзләренең җитәкчесе дип таный.

Казан хакимияте декабрь ахырында Мәсәгуть Гомәровка каршы капитан Г.Кардашевский җитәкчелегендәге отряд юллый. Балтач районының Кариле авылы янында зур яу була. 38 баш күтәрүче әсирлеккә төшә. Моннан тыш, Мәсәгутьнең әтисе Гомәр Әширов, хатыны Мәрфуга, абыйлары Мәгъсүт белән Мансур да кулга алына. Карательләр Мәсәгутьнең баш иеп килүенә өметләнә. Ләкин гыйнвар башында Мәсәгуть тагын да зуррак активлык күрсәтә. Аның отрядындагы баш күтәрүчеләр саны 3000нән арта. Мәсәгуть шул көч белән Казанга һөҗүм итәргә әзерләнә. Әмма аңа Бирдәдән «падишаһ» фәрманы килеп төшә. Мәсәгуть 1500 кешелек бер отряд-

ны – Минзәләне, 250 кешелек икенче отрядны Алабуганы штурмлау өчен озатырга мәҗбүр була.

4 гыйнвар көнне Казаннан капитан Г.Кардашевский отряды икенче мәртәбә җәза походына чыга. Мәсәгутьчеләр Камышлы, Чокырчы һәм Пычак авыллары янында җәза отряды белән берничә мәртәбә яуга керәләр, әмма җиңеләләр. Мәсәгуть үзе әүвәл Нагайбәк крепостена, аннан Эстәрлетамак авылына чигенә. 10 мартта биредә дә тар-мар ителгәннән соң, Мәсәгуть Уфа провинциясенең Уса юлына китә. Уса, Көнгер төбәгендәге авыллардан 60 кешелек отряд туплагач, ул Чесноковка лагерендагы атаман Зарубин-Чика янына юнәлә, аның 24 март көнне тар-мар ителүен белми. Юлда ул хыянәтче мишәр старшинасы Миндәй Тупеев кулына эләгә. Тупеев аны – Уфага, подполковник И.Михельсонга илтеп тапшыра. Мәсәгуть Троицк чиркәве астындагы зинданга ябыла. Михельсон «бөек Казан юлбасары» Гомәровның әсирлеккә эләгүен 16 апрель көнне башкомандующий А.Бибиковка зур горурлану белән хәбәр итә.

Восстание бастырылганнан соң, Мәсәгуть, туган ягындагы авыллардан-авылларга йөртеп, чыбыркы белән суктырып җәзалана. Җәлладлар аның борынын кисәләр, маңгаена һәм яңакларына кыздырылган тимер белән мөһер сугалар. Мәсәгуть Таганрог сөргененә, каторга эшләренә җибәрелә. Шәхсән Мәсәгутьнең дә, аның әтисе, хатыны, абыйларының да шуннан соңгы язмышлары билгеле түгел («Крестьянская война... Башкирии», док. 80; С. Алишев; ЦГАДА, 6 фонд, 467 эш, I кисәк) .

1994 елның 22-25 ноябрьләрендә «Башкортостан» газетасының берьюлы 4 санында «Ялганга батырылган яу» исемле күләмле мәкалә дөнья күрде. Авторы – Эстәрлетамак каласында тарих фәнен укытучы Салават Таймасов атлы кеше һәм, әлбәттә, аның мәкаләсе без фәкыйрегезнең «Сәет батыр», бигрәк тә андагы «Татарлар Пугачев явында» хезмәтенә каршы юнәлтелгән иде. Ошбу Таймасов әфәнде безне Пугачев явыннан ялган татар каһарманнары уйлап табуда, «үзе уйлап тапкан геройлары белән милли батырыбызның (Салават Юлаевның) ролен киметергә, шуның белән аны кимсетергә омтылуда» гаепләде. Аның мәкаләсендә мондый гаеп тарих фәннәре докторы Сәлам Алишев өстенә дә байтак ыргытылды. Таймасовча кызык: башкорт милләте Салават кебек каһарманнарны үстерергә лаек, ә татар милләтендә аңа тиңнәр һич булмаска тиеш. Тибешкәндә тиңең булсын, диләр, Таймасов әфәнде белән бәхәсләшеп тормыйбыз. Ләкин аның мәкаләсендәге мондый юллар үтебезгә тия: «1773 елның ноябрь азакларына тиклем ул яктагы (Казан губернасындагы) чуалышлар турында бер мәгълүмат та юк, кыскасы, алар булмаган... Әгәр анда баш күтәрүләр башланса, хәрби эшкә өйрәнмәгән татарлар бик тиз кыйратылыр һәм юк ителер иде...» Алга таба китик, ул юллар турыдан-туры М.Гомәров язмышына кагыла: «Мәсәгуть Гомәров баш күтәрүчеләргә Пугачев гаскәре Казан губернасына килгәч кенә кушыла... Татар полковнигы зур хәрби җитәкчеләр сафына иңмәгән... Тарихта ул җитәкчелек иткән бер яу да билгеле түгел, кыскасы, алар юк...» Бу күңеле сукыр башкорт патриотына җавап сүзләре урынына тарихи даталарны гына кабат исенә төшерик: Пугачев Казан губернасы туфрагына гаскәр белән 1774 елның 29 июнь көнендә генә аяк баскан. Ә безнең каһарманыбыз Мәсәгуть Гомәров 16 апрель көнне үк Михельсон кулына әсирлеккә төшкән һәм Пугачев җиңүләрдән тантана кылып йөргән көннәрдә Уфа каласының Троицк чиркәве астындагы зинданда җәфа-газап чиккән. Аннары Таймасов әфәнде: «Мәсәгутькә полковник дәрәҗәсен Каранай Моратов биргән», – дип бара. Тик инде март аенда ук җиңелеп хәзерге Татарстан җиреннән чыгып киткән Каранай Моратов Таймасовча фәкать 1774 елның июлендә генә фетнәгә кушылган Мәсәгутькә ничек итеп дәрәҗәләр бирә алды икән? Аерма өч ай, Таймасов арифметиканы бутый, мантыйк бөтенләй юк. ■

ТАССР 100 лет ел
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

ТАТАР ТЕЛЕН ГАМӘЛГӘ КУЮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ*

Хаҗи Габидуллин

ВОЛБАШКАРМАЛАР

Волбашкармаларда татар телен гамәлгә кую бурычлары түбәндәге моментларга кайталар: 1) халыкның күпчелеге татар булган волостьларның волость чигеннән бөтен учреждениеләрендә татар телен актив формада кую, ягъни бөтен төп эчке кәнсәләрия эшләрен татар телендә йөртү, ләкин волостьта азчылык булган урыслардан урыс телендә язылган кәгазьләрне кабул итүне һәм боларга урыс телендә җаваплар бирүне калдыру; 2) халыкның азчылыгы татар булган волостьларда татар телен пассив формада гамәлгә кую, ягъни кәнсәләрия эшен актив формада урыс телендә йөртеп, татарлардан татар телендә язылган кәгазьләрне кабул итүне саклап калдыру.

Волость башкармаларының сайланган составы Татарстан Җөмһүриятенең 5 ел гомере буенча түбәндәгечә үзгәрде: 1921 елның сайлаулары буенча волбашкармаларда 30,4 % татарлар, 1922 елда – 40,4%, 1923 елда – 46,3%; 1924 елда – 51,4% һәм соңгы сайлаулар буенча 52 % татарлар.

Волбашкармаларның сайланган составына аерым милләтләрнең кергән процентлары тормыштагыга якын булу сәбәпле, татар телендә эш йөртүне генә түгел, бәлки татар телендә кәгазьләр кабул итүне дә җиңеләйтә иде. Ләкин татар телен югарыда күрсәтелгән күләмдә гамәлгә куяр өчен, волбашкармаларның эш аппаратларын да тиешенчә татарлаштырырга кирәк иде. Без монда ике киртәгә килеп терәлдек: бер яктан, татар теле дәүләтнең кәнсәләрия эшен йөртү өчен җитәрлек дәрәҗәдә эшләнмәгән булуы, икенче яктан, кәнсәләрия эшен ике телдә йөртә алырлык квалификацияле эшчеләрнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы. Шуңа татар телен гамәлгә кую өчен аерым төзелгән курслар аркылы ике телне дә белгән волость эшчеләрен хәзерләүгә һәм татар телендә кәнсәләрия эшен йөртү юлында кулланмалар һәм инструкцияләр эшләп чыгарып, боларны киң рәвештә таратырга керешергә туры килде. Без бу җирдә волостьларны зурайту мәсьәләсенә аерым тукталырга тиешбез.

*Бу мәкалә «За 5 лет к V годовщине провозглашения ТССР» (1925) исемле китапта рус һәм татар телләрендә басылган. – *Ред. иск.*

1921 елның 25 июнендә «Татар телен гамәлгә кую турында»гы декретны имзалаучылар – ТАССР ҮБКның беренче рәисе (1920-1921) Борһан Мансуров (сулда) (1889-1942) һәм ТАССР ХКСның беренче рәисе (1920-1921) Сәхибгәрәй Сәедгалиев (1894-1939)

ВОЛОСТЬЛАРНЫ ЗУРАЙТУ

Волостьларның 1924 елга кадәрге составының ваклыгыннан, икътисади йомшаклыгыннан һәм бөтен җитешсезлекләреннән башка татар телен гамәлгә кую моменты белән бәйләнештә булган тагы да зур гына ике җитешсезлеге бар иде. Безнең элеккеге волостьларның чикләре этнография чикләре белән, ягъни ике телнең берсе таралган тупракларның чикләре белән туры килмиләр иде һәм татар волостьларының бик күбесенең үзәкләре урыслар тора торган урыннарда иделәр.

Милиция, салым, суд һәм бөтен ведомство участкаларының һәм районнарның чикләре күбесенчә волость чикләре һәм үзәкләре белән бер булганлыктан, бер волостьта берничә телдә сөйләү аркасында күп ведомстволарның линиясе буенча татар телен гамәлгә кую эшендә уңайсызлыклар туа иде. Шуның өчен волостьларны зурайту вакытында, икътисад принцибы белән бергә, халыкның кайсы телдә сөйләү принцибы да күз алдында тотылды. Зурайтылган волостьларның чикләрен билгеләгән вакытта болар эченә мөмкин кадәр бер телдә сөйли торган халыкны җыярга, һәрбер аерым халыкның авылларын билгеле бер волость тирәсендә оештырырга, волостьның үзәген шул ук халыкның берәр авылында эшләргә тырышылды. Бер районда төрле халыкның авыллары булу (татар районнарында урысларның бик күп авыллары таралган), икътисади үзәкләрнең тигезсез бүленүе, җир аркылы бүлүне бетерү кирәклеге бер телдә сөйләүчелек принцибын тулы үткәрергә мөмкинлек бирмиләр иде. Шулай булса, волостьларны зурайту бу турыда зур гына нәтиҗәләр бирә алды. Волостьларны эреләткәнчегә кадәр бер телдә сөйләшә торган волостьлар 22% кына иде, волостьларны зурайтканнан соң 45%ка күтәрелде. 125 волостьтан 55 волость тирәсендә бер телдә сөйләүче халык оештырылды. Бу волостьлар тирәсендә башка телдә сөйләүче азчылык та бар, ләкин боларның саны 10%тан артмый. Болай булганда, тик 95000 татарлар, ягъни татар халкының 8%ы гына урыс волостьларында азчылык булып калалар. Элек волость үзәкләренең гомуми саныннан 32%ы татарларда иде, волостьларны эреләткәннән соң 45% татарларда булып, 15% тора торган халкы катнаш булган шәһәрләргә һәм авылларга калды. Бу шәһәрләрдә һәм авылларда татар халкы да бар.

Волостьларны зурайту сәбәпле, боларның гомуми саны кимегәнлектән һәм кал-

Рәүф Сабиров

1921-1924 елларда Татарстан Үзәк башкарма комитеты президиумы рәисе Рәүф Сабировның ВКП(б)ның IV киңәшмәсендә Милләтләр эшләре буенча халык комиссары Иосиф Сталин каршында сөйләгән нотыгыннан:

«Бездә татарлар – 51%, руслар – 40%, калганнар – 8%... Күп кантоннарда татар халкы күпчелекне тәшкил итә һәм татар телен гамәлгә кую алай кыен булмас. Без инде моңа гамәлдә ирештек һәм бу өлкәдә өлешчә уңышларыбыз да бар. 56 волостьта татар теле гамәлгә куела, ягъни бу төбәкләрдә барлык кәнсәләрия эшләре дә татар телендә бара. Хәзер 4 кантонда тәҗрибә бара һәм аларның күп кенә бүлекләре язу эшләрен волостьлар белән татар телендә алып бара. Шулай итеп, бер ел дәвамында эшне хәзерге кебек эзлекле һәм ныклы дәвам итсәк, бер елдан соң татар телен һәр волостьларга, кантоннарга һәм Татреспубликаның барлык үзәк учреждениесенә дә кертү мөмкин булачак».

Тайны национальной политики ЦК РКП. Стенографический отчёт IV совещания ЦК РКП. 1923, 1992. – С.139.

ган волостьлардагы эшчеләр матди яктан яхшырак тәэмин ителгәнлектән, волостьтагы татар эшчеләренең санын киметеп, боларның араларыннан иң квалификациялеләрен сайлап алырга мөмкинлек булды. Ләкин бу квалификацияле татар эшчеләре бик аз булганлыктан һәм акча юк сәбәбеннән, боларны күп итеп хәзерләү мөмкин булмаганлыктан, волостьларны эреләткәннән соң туган уңайлы хәлләр эчендә дә волостьларда татар телен актив формада тулы итеп гамәлгә куеп булмады.

1925 елның 1 февраленә бирелгән мәгълүматларга караганда, волостьларда татар телен гамәлгә кую түбәндәгечә бара: Татарстан Җөмһүриятендә 125 волость бар. Боларның 80ендә, ягъни 64%ында халыкның күпчелеге татарлар. Боларның 43ендә (53,7%) кәнсәләрия эше бөтенләй татар телендә куелган, 18 (22,6%) волостьта яртылаш куелган, 12 (15%) волостьта яртыдан аз куелган, 7 (8,7%) волостьта татар теле гамәлгә бер дә куелмаган.

11 кантонның 1925 ел 8 апрельгә биргән мәгълүматларына караганда (Тәтеш волосте боларның санына керми), волбашкармалардагы җаваплы эшчеләр арасында 49,1% – татарлар, техник эшчеләр арасында – 32,2% һәм түбән катлау хезмәтчеләр арасында 49,4% татарлар.

КАНТОН УПРАВАЛАРЫНДА

Татарстан Җөмһүриятендә 12 кантон бар. Боларның 7сендә 55%тан 76%ка кадәр татарлар, 5есендә 35%тан 49%ка кадәр татарлар бар. Татар телен гамәлгә куюның төп принциплары һәм перспектив планы буенча, халыкның күпчелеге урыслар булган кантоннарда татар теле пассив формада гамәлгә куеларга тиеш. Ләкин кантон учреждениеләренең аппаратларын татарлаштыру өчен, эшнең күләме буенча да, аны татар телендә һәм урыс телендә йөртү буенча да тагы да артыграк квалификация кирәк.



Милли байрагыбызны чигүче татар хатыны. Казан. 1920 нче еллар

Шулай да булса, үткәнгә бераз күз йөртсәк, кантон аппараты, кантон башкарма комитетларының сайланган составлары буенча һәм боларның эш аппаратлары буенча без теләгән дәрәҗәдә үк булмаса да татар массаларына байтак кына якынлашканын күрәбез. Кантон башкармаларының 1921 елдан 1925 елга кадәр сайлаулы составы түбәндәгечә үзгәрде: 1921-1922 елның сайлаулары буенча, кантон башкармаларында татарлардан 34,3%, 1922-1923 елда – 41,4%, 1923-1924 елда – 51,7% һәм соңгы сайлауларда – 52%. 1924 елның мәгълүматлары буенча, кантон учреждениеләренең хезмәткәрләре составы түбәндәгечә: җаваплы эшчеләр арасында татарлар – 29%, техник-кәнсәләрия арасында – 19% һәм түбән катлау хезмәткәрләре арасында – 19%, уртача хисап белән – 20%. 1925 елның 1 апрелендәге мәгълүмат буенча, кантон башкармаларындагы эшчеләрнең милли составы түбәндәгечә: барлык эшчеләр саны – 173. Болардан 59 (34%) – татарлар, 107се (62%) – урыслар, бүтән милләтләр – 7 (4%).

Хәзерге вакытта бөтен кантон учреждениеләре, татар телен дә, урыс телен дә белгән квалификацияле эшчеләр җитешмәгәнлек сәбәпле, төп кәнсәләрия эшен урыс телендә йөртәләр. Шулай да булса, кантон башкармаларының күбесе һәм бүтән кантон учреждениеләре татар волостьлары белән мөнәсәбәтне татар телендә йөртәләр.

Ахыры ■

Безнең мирас №8 август 2018

ЭЧКЕН ТАТАРЛАРЫ

Рафаил Исакаев

Изге күл (Әлмән районының Изге Күл авылы)

ЭЧКЕННӘРНЕҢ 1773-1775 ЕЛЛАРДАГЫ КРЕСТЬЯН СУГЫШЫНДА КАТНАШУЫ

Русларга Урал аръягында җир бүлеп биреп, аларны шул җирләрдә урнаштыру белән бәйле XVII гасыр ахырындагы вакыйгалар үзәге Әлмән булган, 5 авыл кергән Эчкен волосте эчкен-мишәрләренең мәнфәгатьләренә дә кагылмый калмый. Екатерина II 1767 елда Россия империясенең кануннар җыелмасын булдыру өчен комиссия («Уложенная комиссия») төзергә карар кыла һәм шуның өчен бөтен Россиядән 540 делегат чакырыла. Комиссиягә чакырылганнар арасында Эчкен волосте вәкилләре – йөзбашлары Ибраһим Тенәкәчев (Тынкачев) һәм Мансур Сөбханколов та була. Эчкеннәр аларны сайлаган җыенда үз теләк-зарларын җиткерәләр: җирле хакимият, аларның җирләрен тартып алып, Россиядән күчеп килүчеләргә өләшә башлаган. Билгеле, бу Исет буе татарлары һәм башкортларында зур ризасызлык уяткан.

Эчкеннәрнең Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьян сугышында (1773-1775 еллар) катнашуларының бер сәбәбе шул була. Бу турыда берничә тарихи факт китерәм. Урал аръягында яшәүчеләр Пугачев турындагы хәбәрне хуплап каршы алалар. Аларның күңеленә бигрәк тә Пугачевның «кара халык»ны ирексез хезмәттән, гадел булмаган төрле йөкләмәләрдән, рәнҗетелү һәм талаулардан коткару турындагы вәгъдәсе хуш килә һәм гадел патшага өмет уяна.

____

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

Урал аръягы крестьяннарының баш күтәрүе 1774 елның 10 февралендә Куртамыш каласы бистәсендә башлана. Баш күтәрүчеләр Куртамыш өязе идарәчесе поручик Никита Губинны һәм идарә эшләре хезмәткәрләрен кулга алалар. Алар, дәүләт биналарын яулап алып, отряд оештыралар, Куртамышка илтүче юлларга каравыл куеп, Окунев бистәсенә Пугачев есаулы Иван Алферовка чапкыннар юллап, аннан Куртамышка килүен Һәм бергә Звериноголовск ныгытмасына юнәлеп, халыкны азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары, гаскәриләрне китерү йөкләмәләре белән җәфалаучы офицерларга җәза бирүне сорыйлар.

Иван Алферов 1774 елның 12 февралендә эчкеннәр (яңа җирләргә күченүчеләр арасында Алферов фамилияле кешеләр булуын элегрәк язып үткән идек инде, димәк, есаул Иван Алферов – шулар нәселеннән) отряды белән Куртамышка килә. Аның отрядына Павловский һәм Каменский бистәләре крестьяннары да кушыла. Бу бистәләрдә узган крестьян җыеннарында Пугачев манифесты укыла, җирле крестьян үзидарәсе булдырыла, канцелярия документлары юк ителә. Алферов отрядына һәр бистәдән 100әр казак сайлап алына. Кулга алынган поручик Никита Губинны баш күтәрүчеләр Чөмләк бистәсенә озаталар, анда ул есаул Ерусланов әмере буенча асып үтерелә.

Себер губернаторы Чичерин, восстаниенең Ялутор өязенә үтеп керүеннән куркып, солдатларга ярдәмгә «чакыртып алынган казаклар»дан өстәмә командалар төзи. Крестьяннар аларга, кулга корал алып баш күтәрүчеләр ягына күчү өчен, үз теләкләре белән керәләр.

Оренбург губернасы чигенә, Курган һәм Өтәк бистәләренә, Смолянинов һәм Касьянов җитәкчелегендә, солдат һәм «чакыртып алынган казаклар»дан торган команда җибәрелә. Әмма Смолянинов разведкага җибәргән «чакыртып алынган казаклар», Алферов отряды белән очрашкач, бергә хәрәкәт итәргә килешәләр. Үзләрен җибәргән командирларның игътибарын Өтәк һәм Курган бистәләреннән читкә юнәлтер өчен, разведкага җибәрелүчеләр, «алда бернинди куркыныч юк», дип хәбәр итәләр. Бернәрсәдән дә шикләнмичә, Смолянинов һәм Касьянов, казакларның бер өлешен чик буен саклау өчен калдырып, команда белән Иковский бистәсенә юнәлә һәм анда лагерь булып урнаша. Алферов отряды, моннан файдаланып, Өтәк һәм Курган бистәләрен яулап ала. Чиновниклар һәм сәүдәгәрләрнең йортларын туздырып, крестьяннар биредә җирле үзидарә урнаштыралар, казнаны һәм тоз сатучы кибетләрне кулга төшереп, тозның потын (1пот 16кг га тигез) 40 тиен урынына 20 тиеннән сата башлыйлар.

1774 елның 24 февралендә Алферов отряды Иковский бистәсе янына килә. Капитан Смолянинов һөҗүмне кире кайтарырга әзерләнә, әмма элек Алферов белән килешкән «чакыртып алынган казаклар» хәлиткеч мизгелдә баш күтәрәләр. Аларга бистә крестьяннары да кушыла. Баш күтәрүчеләр, каравылга һөҗүм итеп, мылтыкларны һәм пушкаларны кулга төшерәләр, офицерларны кулга алып, Курган бистәсенә озаталар. Анда Смолянинов асып үтерелә, ә башка офицерлар Чиләбегә җибәрелә. Солдатларның күпчелеге баш күтәрүчеләргә кушыла.

25 февральдә Курган бистәсенә тал, окунев һәм чөмләк крестьяннарыннан торган 800 кешелек отряд белән Куртамыш һәм Ялутор өязләре баш күтәрүчеләренә җитәкчелек иткән атаман Ковалевский килә. 1774 елның 6 мартында Пуховая бистәсе астында аяусыз сугыш була. Ул көне буена сузыла һәм крестьяннарның җиңелүе белән тәмамлана. 3000 баш күтәрүченең 600е үтерелә, алар 6 пушканы югалталар һәм Пуховая бистәсеннән чигенергә мәҗбүр булалар. Ковалевский гаскәре, 3 отрядка таркалып, Курган, Белозерье һәм Лебяжье бистәләрендә кала. Бу таркаулык җәза командаларының хәрәкәтен җиңеләйтә.

Утятский бистәсенә кайткач, Новгородов Ялутор һәм Куртамыш өязләре авылла-

Шуңа күрә алар 1767 елда Россия империясенең кануннар җыелмасын булдыру комиссиясенә делегатлар итеп сайланган йөзбашлары Ибраһим Тенәкәчев (Тынкачев) һәм Мансур Сөбханколовлар аша Екатерина II гә җирләрен тартып алу турында шикаять бирәләр.

рына Пугачев манифесты күчермәләре белән чапкыннар җибәрә һәм хөкүмәт гаскәрләренә каршы яңа поход өчен кичекмәстән көч тупларга чакыра. Куртамыш шәһәр бистәсе, Каменский һәм Таловский бистәләре крестьяннары, эчкеннәр һәм башкортлар отряды, есаул Алферов җитәкчелегендә, Утятский бистәсенә Новгородовка ярдәмгә китәләр. Куртамыш өязеннән барлыгы 3000ләп баш күтәрүче килә. Новгородовка бер үк вакытта Ялутор өязе крестьяннарының таркау отрядлары да кушыла.

Новгородов 5 меңле отряд белән Курган бистәсен ала һәм Эртман белән Фадеев командалары торган Иковский бистәсенә походка әзерләнә башлый. Ул Чиләбегә атаман Грязнов һәм Зарубиннарга (Пугачевның көрәштәшләренә) чапкыннар җибәреп, алардан 1000 казак һәм пушкалар, шулай ук байрак җибәрүне сорый.

Новгородов атаманнардан өстәмә көчләр ала алмый, ә байракны үзенә ясарга боералар. Шунда Новгородов үзе хәрәкәт итәргә карар кыла. Ул, 1 меңле отряд белән, восстаниенең төп үзәге булган Курганга җәза отрядларының юлын бүләр өчен, Иковский бистәсенә юнәлә. Новгородов сугыш барышында Эртман солдатларын баш күтәрүчеләр ягына тартып, үз көчләрен тулыландырырга һәм аннары Тобольскига барып, аны яулап алырга исәп тота. Отряд 1774 елның 20 мартында Иковский бистәсенә якынлашкач, Эртман ике атлы һәм бер мушкетер ротасы белән аңа каршы чыга. Әмма ул баш күтәрүчеләрне бер талпынуда тар-мар итә алмый, үз командасы белән бистәгә чигенеп, аны бөтен яктан артиллерия батареялары белән ныгытып, төн җиткәнче мылтык һәм пушкалардан атып торырга мәҗбүр була. Ә баш күтәрүчеләр исә, көчле ут ачып, бистәне уратып алалар һәм аңа илтүче бөтен юлларны кисәләр. Камалышта калган командага сугышка керергә туры килә, бәрелеш ике көн бара. Крестьяннар бистә тирәли кардан чокыр һәм ныгытмалар булдыралар.

Хөкүмәт гаскәрләре 21 мартта иртән һөҗүмгә күчеп, пушкалар торган Текә яр ермагын кулга төшерү омтылышы ясыйлар. Атаканы җиңел генә кире каксалар да крестьяннар һөҗүмгә күчмиләр. Каршы як икенче көнне ермакны алуга яңа ыргым ясый. Озакка сузылган бәрелештән соң, алар, ныгытманы алып, 3 пушканы кулга төшерәләр. Пушкаларын югалткач, баш күтәрүчеләр чигенәләр. Алар бу бәрелештә 700дән артык кеше югалталар, 52се әсирлеккә төшеп, күбесе асып үтерелә.

Новгородов, чигенеп, бөтен отрядларны туплау һәм Иковский бистәсенә атаканы кабатлау өчен, Курган бистәсенә юнәлә. Әмма аңа бу планын гамәлгә ашыру насыйп булмый. Эчкеннәрнең бер җитәкчесе – есаул Алферов, Новгородовны тыңламыйча, ашыгыч рәвештә, Оренбург губернасына китеп бара. Бу Алферов отрядының күп санлы булуы һәм Новгородов гаскәрләрендә хәлиткеч роль уйнавы турында сөйли. Есаул Алферов җитәкчелегендә биш авыл эчкеннәре, шул исәптән өчкүллеләр дә сугыша. Алферов исә чынлыкта, Оренбург ягына киткән булып, үз кешеләре белән Әлмәнгә әйләнеп кайта. Аның киләчәктәге язмышы турында бер документ ачык сөйли. Бу документ – майор Декастроның Урал аръягында баш күтәрүчеләргә каршы җәза экспедициясенә җитәкчелек иткән генерал И.А.Деколонгка 1774 елның 29 мартында юлланган рапорты. Аның эчтәлеген хәзерге телгә тәрҗемәдә китерәм: *«Хәзерге (мартның) 27сендә Сез галиҗәнапка җибәргән рапортымда хәбәр итүемчә, Могильная (Әлмән) авылында явызлык тарафдарларының булуын ачыклау өчен җибәрелгән атчабарлар шул ук көннең төн*

уртасында ук әйләнеп кайттылар. Алар, чыннан да инде, мин урнашырга өлгергән Куртамышка килделәр, ягъни 28ендә миңа Могильная авылында булган явыз есаул Алферовның, биш татар гаиләсе һәм 100ләп урыс кабахәте белән, таланган мал-мөлкәтне төяп, Башкириягә китүен игълан иттеләр. Ә бу авылның (Әлмәннең) калган кешеләре, торган җирләрен калдырып, өйдәгеләр һәм олау белән Птичье авылына күченгәннәр». (Монда бернәрсә аңлашылып җитми: әлмәнлеләр әле бу вакытта нигез салынмаган Птичье авылына ничек күченергә мөмкин, әлеге җирләр эченнәрнеке булган бит һәм алар Өчкүлгә якынрак урнашканнар. – *Автор иск.*)

Баш күтәрүчеләрнең гаскәрләре тар-мар ителгәч, хакимият Куртамыш һәм Ялуторовский төбәгендә яшәүчеләрдән рәхимсез рәвештә үч ала – тикшерү барышында восстаниедә катнашучылардан 11 кеше җәзалаулардан вафат була, 16 кешене гомерлек сөргенгә җибәрәләр. Атаман Семен Новгородов сорау алу вакытында үзен батыр тота, үкенми. Екатерина II нең әмере белән аны, «үлгәнче богауда тотарга» дигән шарт куеп, гомерлек каторгага озаталар.

Рапортта алга таба болай диелә: *«...ә Могильная авылыннан татарлар шул ук көнне миңа, император галиҗәнапларына буйсынуларын белдереп һәм килешү сорап, баштарак ике, аннары тагын ике татарны җибәрделәр. Алар исә авылларындагы башка татарларның да Птичьедан Әлмән (Могильная) авылындагы үз йортларына кайтуларын игълан иттеләр һәм барысы бергә минем янга гаепләрен танып килергә вәгъдә бирделәр. Ә есаул Алферов, үзе кебек караклар белән, башкорт җирләренә киткән, ә кая китүе төгәл билгеле түгел, мин биредә бүген кич монда киләчәк калган эчкен татарларын көтәргә мәҗбүрмен.*

Мин аларны император галиҗәнапларына (Екатерина II гә) тугрылыкларын раслап кул куярга мәҗбүр иттем».

Халык, үз авылын калдырып, Птичье авылына күченгән, дигән мәгълүматны шәрехләп китәргә кирәк. Алдарак билгеләп үткәнемчә, рус крестьяннары Урал аръягына күченгәнче, бу җирләр эченнәрнеке булган. Шуңа күрә алар 1767 елда Россия империясенең кануннар җыелмасын булдыру комиссиясенә делегатлар итеп сайланган йөзбашлары Ибраһим Тенәкәчев (Тынкачев) һәм Мансур Сөбханколовлар аша Екатерина II гә җирләрен тартып алу турында шикаять бирәләр.

Докладнойдан чыгып фикер йөртсәк, әлмәнлеләргә, авылларына кайтып, Куртамыштагы хөкүмәт вәкиле майор Декастрога, килешү сорап һәм Екатерина II гә буйсынуларын белдереп, биш авыл исеменнән вәкилләр җибәрергә туры килгән. Урал аръягындагы крестьян күтәрелеше турында йомгак ясап шуны әйтергә кирәк: баш күтәрүчеләрнең гаскәрләре тар-мар ителгәч, хакимият Куртамыш һәм Ялуторовский төбәгендә яшәүчеләрдән рәхимсез рәвештә үч ала – тикшерү барышында восстаниедә катнашучылардан 11 кеше җәзалаулардан вафат була, 16 кешене гомерлек сөргенгә җибәрәләр. Атаман Семен Новгородов сорау алу вакытында үзен батыр тота, үкенми. Екатерина II нең әмере белән аны, «үлгәнче богауда тотарга» дигән шарт куеп, гомерлек каторгага озаталар.

Ә безнең эчкен каһарманы есаул Алферов, белүебезчә, туганнары белән башкорт җирендә яшеренеп өлгерә. Аның отрядындагы гади эченнәр исә, буйсыну белдереп, Екатерина II нең хакимиятен таныйлар. Озын сүзнең кыскасы, тормыш дәвам итә.

Дәвамы бар ■

ТАТАР БАЙЛАРЫ

НИГЪМӘТУЛЛА ХАЖИ

Ризаэддин Фәхреддин

Нигъмәтулла хажи Сибириядә «Бухарец» дип йөртелә торган мөселманнардан иде. Ерак бабалары, сәүдә өчен Бохарадан килеп, ислам хөкүмәтләре заманында ошбу җирдә урнашып калганнар. Нигъмәтулла хажи Карамшак бине Сәедүк бине Касыйм бине Шәриф бине Әш-Шәрәф исемле кемсәнең углы иде. Атасы Карамшак яшь вакытында Төмән шәһәре янында Манчыл карьясенең Габделкәрим исемле байда приказчик иде. Әлеге бай Семи берлә Павлодар арасында Ямеш исемле казак-рус авылында сату кылып торды. Шул җирнең гадәт-горефләрен белеп бетердегеннән, баеннан рөхсәт алып, үзенә кәсеп башлады вә үзе илә берлектә Габделкәрим байда хезмәт кылучы Ишморад Илбәков исемле авылдашы илә берлектә сәүдә кылырга керештеләр. Әүвәлләре казакъ арасында вак-төяк галантерия берлә йөреп сәүдә кылырлар вә алардан җон-ябага, чимал алып, Төмән шәһәренә китереп сатарлар иде. Акчалары артып, эшләре бәрәкәт таптыгыннан соң, Эрбет ярминкәсеннән аршынлы маллар китереп, яхшы бәһаләр илә казакъларга бурычка таратырлар иде. Моннан соң Павлодар шәһәрендә кечек бер кибет ачып, үзләренә күрә яхшы гына мөгамәлә кыла башладылар.

Нигъмәтулла хажи мәчете. Төмән өлкәсенең Янбай авылы

Гомерләрендә газета исемен ишетмәгән меллаларның, багана сызыкларына игътибар итми, сызыклардан атлап тоташтан укып китүләренә мыек астыннан көлеп утырыр вә бәгъзе вакыт: «Йә, дамелла! Газета ни сөйләде?» – дип сорар иде.

Ул вакытларда кыргыз җирләре иркен, аяклы мал күп булу сәбәпле, тире, җон-ябага, кыл бихисап булу өстенә, шул нәрсәләрне алучы аз булыр иде. Безнең тырыш Карамшак бабабыз ошбу форсатларның кадерен белде. Казаклардан нәрсәне арзан вә күбесен дә алмашып алыр вә Төмән шәһәренә китереп тә яхшы бәһагә сатар иде. Эрбеттән фабрика нәрсәләрен очсыз алып, казакларга файда илә таратыр иде. Ошбу сәбәпле Карамшак бабай акчалы вә яхшы байлар җөмләсенә керде. Бу вакытта угыллары да, җитешеп, кул арасына керделәр вә Карамшак бабай, үзе Төмәндә торып, угыллары Рәхмәтулла илә Нигъмәтулланы үзенең иптәше Ишморадка тапшырды. Алар исә, Семи шәһәренә барып, кибет ачтылар. Соңрак Нигъмәтулла хаҗи атасы янына Төмәнгә кайтты вә аның урынына Хәбибулла Семигә китте.

Нигъмәтулла хаҗи. Нигъмәтулла хаҗи 1829 елның 18 октябрендә Табул губернасы Төмән өязе Олуг Манчыл (русча – Янбай) авылында дөньяга килде. Анасы Зарифә бинте Габделхәй иде. Карамшак бабай вафатыннан соң, угыллары Ишморад Илбәков илә аерылыштылар вә, риваятьләргә күрә, иллешәр мең сум акча бүлмешләрдер.

Кабере. Нигъмәтулла хаҗиның кабере үзенең карьясе булган Олуг Манчыл зиратында. Кабере өстендәге язуы: *«1901 елда 73 яшендә хаҗи Нигъмәтулла мәрхүм бине хаҗи Карамшак мәрхүм рамазан шәриф 21дә [17 декабрьдә] дәфен булды. Рәхмәтулла галәйһи вәсәгат»*тер. Рәсеме табылмады. Юклыгы катгый, диләр.

Укуы вә әдәбият белән шөгыльләнүе. Нигъмәтулла хаҗи яшь вакытында Манчыл карьясендә Мөхәммәдрәхим мелла, Ибраһим ахун, мелла Хәмидулла Сәгыйдов, Галимҗан бине Гүиджан, мелла Бакый хаҗи исемле затлардан белем алды. Сарыф гарәби башлап шул заман рәсеменә муафыйк гакаидәләргә кадәр укып барды. Фәкать Нигъмәтулла хаҗиның гыйлеме мәдрәсәдән түгел, бәлки үз иҗтиһады илә соңрак хасил булган гыйлем иде. Төрле рисалә вә китапларны укыр, гыйлем әһелләре илә аралашыр иде. Ханәсе әдәби бер мәҗлес булып, күңелләргә сөенеч вә гайрәт бирер иде. Кыйраәт гыйлемендә сәләте бар адәмнәргә очраса, Коръән Шәриф укыттырыр вә үзе дә: «Мәрхәмәт кылып кыйраәтемне тыңлагыз да хаталарымны әйтегез!» – дип, укып күрсәтер иде. Хаҗ сәфәренә бардыгында Мисырда туктап, шәех Мөтәвәлли хәзрәтләрендә кыйраәт өйрәнде вә мәшһүр Кәмал әфәнде җәнапларыннан кыйраәт гыйлеменә өйрәнде. Бөтен мәҗлесе гыйлем мәҗлесе булып, гыйлемнән, мәктәп вә мәдрәсәләрдән, китап вә матбугаттан, китапханә вә мәсҗидтән сөйләнер иде. Тарих вә география, хисап вә астрономия фәннәрендә, аеруча ислам тарихыннан белемле булып, гыйлем фикъһедән дә хәбәрсез түгел иде. Сөйләгәне кагыйдәле, җөмләләре чыгышлы, язуы гүзәл булыр иде. Китапханә вә мәсҗид хакындагы вәкыфнамәсен үзе тәртип итмештер. Гыйлем вә мәгърифәткә булган мәхәббәте Нигъмәтулла хаҗиның башкалардан аерган бер сыйфаты булса кирәк. Башлап русча тарала торган «Всемирная иллюстрация» исемле газетаны укый башлады. Соңрак мәшһүр «Новая время»не укуны дәвам итте. Чыккан саннарыннан башлап, «Тәрҗеман»ны укый барды. Болардан да башка Истанбулдан – төрекчә, Бәйрут вә Мисырдан гарәпчә газета вә журналлар алдырып укыр иде. Бер җирдә ят бер китап барлыгын ишетсә, шул ук вакытта сатып алыр, хакы

Юмартлыгы адәм ышанмаслык иде. Берьюлы бер кешегә мең сум сәдака иткән вакытлары булды. Бәгъзе бер чакларда кесәсендә бер тиен акчасы калмас, шушы вакытта килгән сәдака әһелләренә бурычка алып бирер иде.

бәһале булуына карамас, бәлки мондый сирәк китапларның кулына төшүе өчен сөенер иде. Ошбу юл илә бик күп китап җыйды. Ләкин килгән меллалар, үзләренең иске гадәтләренчә: «Мин моны алып торыйм әле!» – дип, кирәк булса-булмаса алып китәрләр вә күбесенчә китереп бирмәсләр иде. Ошбу рәвештә китапларының югалганын белеп, Нигъмәтулла хаҗи китапларына махсус бер китапханә ачарга карар бирде. Йортына килгән меллаларга: «Менә газета укыгыз, ул бик файдалы нәрсә», – дип, кулларына «Тәрҗемән» газетасын тоттырыр. Гомерләрендә газета исемен ишетмәгән меллаларның, багана сызыкларына игътибар итми, сызыклардан атлап тоташтан укып китүләренә мыек астыннан көлеп утырыр вә бәгъзе вакыт: «Йә, дамелла! Газета ни сөйләде?» – дип сорар иде.

Гыйлемгә хөрмәте. Гыйлемгә, дингә хезмәт итү тугрысында Нигъмәтулла хаҗиның мисалы аз табылыр. Сибириягә гыйлем нурын башлап кертүче адәм – Нигъмәтулла хаҗидыр. Үзенең яшь заманнарында мәдрәсәсенә мөдәррис итеп Гыйсмәтулла хәзрәтне алды. Ошбу мәдрәсәдә һәрвакыт 300 микъдарында шәкерт булыр вә фарыз сәдакасының күбрәген хаҗи ошбу мәдрәсә шәкертләренә бирер иде. Сыйныфка аерылган шәкертләрнең иң аз алучыларына 15 сум микъдарында өлеш чыгар иде. Үз байлыгы илә һәрвакыт Мәккә вә Мәдинә, Бохара вә Мисыр, Истанбул вә Казанда шәкертләр укытыр, Троицкий, Кышкар вә Эстәрлетамак кеби урыннарда моның акчасына укучы шәкертләр күп булыр иде. Ләкин бу кадәр акчаны тотып, читләрдә укыткан кешеләре арасында һиммәтле адәм аз чыкты. Фәкыйрь адәмнәрнең балалары да гыйлемнән өлеш алсыннар өчен, 1890 елда үзенең карьясендә бер ысуле җәдидә мәктәбе ачып, Истанбулдан (асылы Русияле) Мостафа әфәнде исемендә бер мөгаллим китерде. Бу вакытта Русия мөселманнары арасында ысуле җәдидәнең исеме дә юк иде. Мостафа әфәнде кайтып киткәннән соң, Хәйрулла әфәнде Госманов килде, аңа да берникадәр хезмәт хакы тәгаен кылып, якынча йөз кадәр баланы ысуле җәдид илә укыттырды. Үзе һәр көн, мәктәпкә кереп, балаларның укуларын тикшерер, үзе кыйраәт укытыр вә дәресләренең яхшылануын күрсә, гаять шатланыр иде. Балаларның күңелләре күтәрелсен, мәхәббәтләре артсын өчен, һәрберенә бер формада җөббәләр кидерер, Эрбет ярминкәсеннән һәрберенә читек, кәвеш, кәләпүш кеби бүләкләр китерер иде. Балаларның дәрес китапларын Истанбул вә Бакчасарайдан үз хисабына алдырып өләшер иде. Кырымда Гаспринский хәзрәтләре тарафыннан ачылган үрнәк мәктәбенә Манчылдан адәм күндереп укыттырды вә ысуле җәдид тәртибе өйрәнеп кайтканнан соң, шул затны үз мәктәбенә мөгаллим итте. Соңрак таштан бик яхшы итеп ысуле җәдид мәктәбе бина кылды вә моның барлык чыгымын үзеннән тотып, вафат көненә кадәр дәвам иттерде. 1892 елда мәшһүр Кәмалетдин хәзрәтләрен үзенә китереп, аннан кыйраәт өйрәнде вә Коръән Кәримне башыннан ахырына кадәр мәгънәсе илә укып чыкты. Тирә-якта булган мелла вә мөгаллимәләрне, хәлфә вә шәкертләрне җыеп, Кәмал карыйдан кыйраәт иттерде. Манчыл вә аның тирә-ягында кыйраәт гыйлемен яхшы белүче меллаларның күп булуына сәбәп ошбудыр. Дамелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләре Кәмал әфәнде илә берлектә булып, хаҗинең авылдан өч чакрым ераклыктагы утарында бергә яттылар. Нигъмәтулла хаҗи, үзенең мәктәп вә мәдрәсәләренә хисапсыз акчалар тоту беләң бергә, чит авылларда булган мәктәп вә мәсҗидләр өчен дә күп иганәтләр кылыр иде. Биш мең сумнарга төшереп үз авылында бер кызлар мәктәбе дә төзеде.

Ошбуның өчен Манчыл карьясендә 25 яшьтән түбән булган ирләр вә кызлар арасында язу яза һәм укый белмәгәне юктыр.

Изгелекне кылдылар, ләкин милләт өстенә ташлап китми, бәлки бөтен эшен бетереп киттеләр.

Юмартлыгы, нигъмәт бирүе вә ярдәм-изгелеге. Нигъмәтулла хаҗиның капкасы бөтен халык өчен ачык булып, кунакларга махсус бер мосафирханә бина иттерде вә аңа да кирәк кадәр хезмәткәрләр куйды. Мөселманнарны ачык йөз илә каршы алыр иде. Азия, Казан, Төркия вә Гарәбстан мосафирлары өчен хаҗиның гомуми бер йорты булып, һәркем шунда төшәр вә хаҗәтләрен табып китәрләр иде. Моның ялгыз гына ашавы күрелмәмештер. Аеруча шәкертләр, гыйлем әһелләре, фәкыйрь вә гаҗизләргә изгелеге мул булыр иде. Шушы кадәр мал вә гомер сарыф итүе илә дә кәсепләренә зарар китермәс, бәлки көннән-көн иҗтиһадын арттырыр, баеп торыр иде. 1881 ел 16 майда Олуг Манчыл карьясендә ут казасы булып, бөтен авыл диярлек (җәмгысы 160 йорт) янды. Бу вакытта Нигъмәтулла хаҗи хаҗ сәфәрендә булып, янып торган ут өстенә кайтып төште. Ошбу вакыт Нигъмәтулла хаҗи үзенең ир туганнары Рәхмәтулла, Хәбибулла илә утыз мең сумлык агач алдылар вә бөтен карьяне бер фасадта үз кесәләреннән салдылар. Фәкыйрь вә гаҗизләр өчен 175 йорт бина иттекләре мәгълүмдер. Өйләр һәркаюсы алты почмаклы булып, башлары такта илә ябылды, йорт урыннары егерме сажин булып, ихаталары вә йорт әсбаплары тәмам кылынды. Йортларның һичбере мең сумнан кимгә төшмәгәндер. Хакларын кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләдән алмак шарты илә фәкыйрьләрне, гаҗизләрне ошбу йортларга кертеп утырттылар. Читтән килүчеләр Манчыл карьясенең төзеклегенә вә бер фасадта тәртипле салынуына гаҗәп итәләр. Аның сәбәбе исә ошбуында язган нәрсәдер. Юмартлыгы адәм ышанмаслык иде. Берьюлы бер кешегә мең сум сәдака иткән вакытлары булды. Бәгъзе бер чакларда кесәсендә бер тиен акчасы калмас, шушы вакытта килгән сәдака әһелләренә бурычка алып бирер иде.

Мәсҗиде вә китапханәсе һәм мәдрәсәсе. Нигъмәтулла хаҗи илә туганнары Рәхмәтулла вә Хәбибулла әфәнделәрнең иң олуг хәератлары – үзләре дөньяга килгән ватан асыллары Олуг Манчыл карьясенә салган мәсҗидләредер. Бу мәсҗид ике катлы булып, мавритански стильдә, алты чуен баганага корылган. Бинасы 1884тә башланып, 1888дә тәмам булды. Моның асыл фасадын Нигъмәтулла хаҗи үзе төзеп бирмештер. Гәрчә тыштан күренүдә башка мәсҗидләрнең биналарыннан күп аермасы булмаса да, эчендә аермасы күптер. Тәрәзә түшәме вә баскычлары саф мәрмәр ташыннан ясалмыштыр. Эчендә исә солтан Габделхәмид хан тарафыннан һәдия ителгән [пәйгамбәребезнең] чәч бөртеге мөбарәк булып дикъкать илә искә алыныр.

Мәсҗиденең ихатасы эчендә таштан бина кылынган өч бүлмәле биек бер китапханәсе бар. Бер бүлмәсе – китаплар торыр өчен, икенчесе – уку урыны, өченчесе – китап укучыга ял итү урыныдыр. Китапханә һәр көн ачык торыр, сүз язып алучылар өчен каләм, кәгазь, кара хәзердер. Китапханәдә 2200 томнан артык язма вә басма китап бар. Кулъязмалар арасында бик иске әсәрләр вә тарихи ядкәрләр бихисап. Бу китапларны Бохара вә Төркестан тарафыннан вә 1880 ел икенче мәртәбә хаҗ сәфәрендә төрле шәһәрләрдән сатып алып китермештер. Китапханәнең байтак меңнәргә төшүендә шөбһә юк. Мәсәлән, өч җилд кулъязма Мохит Борһани китабын Бохарадан 700 сумга алдырган иде. Соңгы хаҗ сәфәрендә сарыф ителгән утыз алты мең сум акчаның иң күп өлеше дә китаплар өчен киткән булуында шөбһә юк.

Ошбу мәсҗид янында асты таш вә өсте агачтан бина ителгән мәдрәсәсе вә аның

Нигъмәтулла хаҗи үзе яшәргә тиешле булган заманнан беркадәр алдарак килгән адәм иде. Шуның өчен дә гыйлем юлына түккән байлыгына нисбәт илә нәтиҗәсе азрак күрелде.

янында да таштан салынган ашханә вә җылы госелханәсе, мөгаллим өчен урыннары бар. Шулай ук мәдрәсә янында ике бүлмәле, ике коридорлы таштан эшләнгән ысуле җәдид мәктәбе бар. Ошбу мәсҗид вә китапханә, мәдрәсә вә мәктәпләр өчен никадәр акча тотылдыгы ачык мәгълүм булмаса да (чөнки хаҗи үзе моны үзе һич кешегә сөйләмидер, сораучыга әйтмидер иде), сәламәт вакытында вәкиле булып хезмәтләрен кылучы Гайнулла әфәнде Салихов риваятенә күрә, якынча ике йөз мең сумнар акча тотылмыштыр. Рәхмәтулла, Нигъмәтулла, Хәбибулла байлар, безнең Русияле мөселман байларының күбесе мисалында, ошбу биналарны салдырып та, милләт өстенә ташлап китмәделәр, бәлки ошбу кылган хәератларының кыямәт көненә кадәр дәвамы өчен мәсҗид, китапханә файдасына унтугыз мең сум акча вакыф итеп, дәүләт банкына тапшырмышлар иде. Моннан һәр сәнә өчен алты йөз җитмеш сум процент килә вә шуннан имам вә мөәзин һәм дә хафиз кятиб вә мәсҗид караучы хезмәткәрләргә айлык вазыйфа бирелә, керосин вә шәм кеби хаҗәтләргә сарыф ителенә вә шуннан артканы да сберегательная кассага салынадыр. Кирәк вакытта моннан алынып, чыгымнарга тотыладыр. Кылган эшне җиренә җиткереп кылу ошбу рәвештә булса кирәк. Изгелекне кылдылар, ләкин милләт өстенә ташлап китми, бәлки бөтен эшен бетереп киттеләр. Ысуле җәдид мәктәбен исә: «Бу мәктәп инсаннарның хөкемендәдер, шуның өчен аны халык үзе алып барыр, авылыбызда бездән башка да байларыбыз күп һәм саваплы эшне без үзебез генә җыеп алып, башкаларны мәхрүм итәргә теләмибез, аларга да калсын!» – дип булса кирәк, халык өстенә калдырганнардыр. Ләкин мәрхүмнәрнең калдырган адәмнәре, үзара низаглашып, мәктәпне көч-хәл илә генә алып баралар. Бу эшләрдә дә: «Шулкадәр дәүләтле була торып, бер мәктәп тә тәрбия итә алмыйлар», – дип кешеләрдән сүз ишетмәс өчен генә булуы аңлашыладыр. Мәсҗид хозурында имам һәм мөдәррисләр өчен вакыф иткән биналар да бар. Дәресханәсе дә таштан бина ителгән.

Әхлагы. Нигъмәтулла хаҗиның әхлагы игътибарга алынса, һәркем өчен үрнәк булырга ярарлыктыр. Юмартлыгы илә мәшһүр булу кеби күркәм холкы вә адәмчелеге илә дә башкалардан аерылган иде. Бала вакытында иптәшләре илә орышып-сугышып йөрмәде, кирәк яшь вә кирәк олуг вакытында яман сүзләр әйтмәде, үзе һичбер адәмне рәнҗетмәде вә гомерендә гайбәт сөйләгәне ишетелмәде. Хәтта янында иң бозык бер адәмнең гайбәтен сөйләгәндә дә хуш күрмәс вә риза булмас, әгәр дә сүз озынга китә башласа, икенче бер сүз табып, шуңа борыр иде. Бер адәмнең гыйлем вә кәмиллеге, күркәм холкы вә тырышлыгы илә танылуын ишетсә, шуңа кәефе килер, хозурланыр вә шул сүзгә каршы: «Аны мин дә шулай уйлый идем, дөрес икән!» – дип кушылыр иде. Мәҗлесендә бай вә фәкыйрь, карт вә яшь, сәламәт вә авыру, надан вә галим өчен якты йөз күрсәтер вә һәрберенә туры килгән сүз табар вә барчасын риза кылыр иде. Бәгъзе адәмнәр хаҗины үзләренә дошман хисап кылып йөрсәләр дә, ул, мондый эшләрен белә торып, аларга өлфәт вә мәхәббәттә булыр иде. Гомерендә бер адәмне оялтканы вә йөз пәрдәсен җыртканы булмагандыр. Хадимнәре бер адәмне үз хозурына якалап китереп: «Фәлән нәрсәне угрылаган вакытта тоттык», – дигәндә: «Юк, бу адәм андый угры түгел, ни булса да бер ялгышлык булгандыр, җибәрегез!» – дип азат итмеш вә соңра, шул адәмне аулакка чакырып: «Хадимнәрем сине рәнҗеттеләр, риза бул!» – дип, бишәр сум сәдака биреп җибәрмештер. Иң хозурланган нәрсәсе адәм шатландырмак,

кешеләрнең зарур нәрсәләрен җитештермәк, йомышларын үтәмәк, мәшәкатьтән коткармак вә ике дошман арасын килештермәк иде. Кыз карендәшләренә гаять шәфкатьле булып, берәр җирдән йөреп кайтканда, аларга бүләкләр алып кайтыр иде. Бәла вә казаларга дучар булып никадәр кыз балалары вә бөтен ир баласы үзе сәламәт вакытта вафат итеп беттеләр исә дә, зарланып-моңланып сөйләве беленмәде. Зирәклек вә батырлык галәмәтләре күрелгән Гатаулла исемле углы вафат булганнан күңеленә гаять йомшаклык килсә дә, һичбер шикаять итмәде. Бер кызы вафат булган вакытта, шуны кунакларына белдерми алар илә сөйләшеп утырдыгы билгеле. Манчыл яндыгыннан соң халыклар Нигъмәтулла хаҗи хозурына барып: «Алланың казасына, ачуына очрадык, яндык-көйдек, харап булдык бит!» – дидекләрендә хаҗи: «Һич кайгырмагыз, зарланмагыз, шикаять кылмагыз, бу – Алланың ачуы түгел, бәлки нигъмәте! Алла насыйп итсә, авыл әүвәлгедән яхшы сурәттә бина кылыныр, сез әүвәлгедән бай булырсыз, югалган бернәрсә дә юк, ни өчен кайгырасыз?» – дип, бәхетсезлеккә дучар булганнарның янган йортларына салкын су сибеп җибәрде вә йортларын төзеп бирде. Чынлыкта халыклар бернәрсәләрен дә югалткан булмадылар.

***

Нигъмәтулла хаҗины без үзебез күрдек. Уфа шәһәрендә тордыгыбыз вакытларда ике мәртәбә безгә килеп, һәрбер мәртәбәсендә байтак көннәр торып китте. Гомуми мәҗлесләрдә бергә булдык. Вакытыбызны белештереп, йортыбызга килеп тә күп мәртәбәләр утырды. Мөселманнарның киләчәкләренә өмиде зур иде. Бер кеше өстеннән шикаять кылмады, дөньядан бервакытта зарланмады, иҗтимагый түбәнлекләребезне, дин вә гыйлем тугрысында булган кимчелекләребезне кешеләр өстенә ташлап утырдыгын ишетмәдем. Русиянең эчендә вә аеруча Сибириядә «ысуле җәдид» илә дәрес укуны ошбу зат башлап җибәрде.

Нигъмәтулла хаҗи үзе яшәргә тиешле булган заманнан беркадәр алдарак килгән адәм иде. Шуның өчен дә гыйлем юлына түккән байлыгына нисбәт илә нәтиҗәсе азрак күрелде.

Шулкадәр кыйммәтле мәсҗид илә газиз әсәрләр җыелган китапханәне бер авылда бина кылуына сәбәп үзенең ватаны, кавем кабиләсен сөюе булса кирәк. Юкса, шул дәрәҗәдә кыйммәтле китапханә шәкерт вә мөгаллимнәр күп җирләрдә булырга тиешле иде.

Зур бәдәнле, ачык йөзле, зур күзле, мөлаем сүзле булып, кеше сүзен дикъкать илә тыңлар, үзе сөйләгәндә җөмләләрне өзеп, бәхәсләрне аерып бик ачык кылып сөйләр, кеше илә җиңешмәс, бер сүзне тәкрар кылмас, икейөзле түгел, ялагайланмый торган, саф вә риясыз бер адәм иде. Бер мәҗлестә бик күп тугрыларда вә бик күп адәмнәрдән зарландылар, сыкрандылар, шуларның һәрберенә Нигъмәтулла хаҗиның: «Ни эшлисең соң, күпчелек!» – дип сүз кушып торуын тәҗрибә кылып утырдым.

Нигъмәтулла хаҗи вафат итсә дә, хәераты сәясендә һаман да хәяттадыр. Иншаллаһ моннан соң да исеме онытылмас. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтендә булсын!

Шура. – 1913. – №17.– Б.513-516; №18. – Б.545-548.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Бөекләрнең туганлыгы

Ринат Нуруллин

(Күренекле композитор Рөстәм Яхин белән Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең туганлыгын раслаучы шәҗәрә турында)

Композитор Рөстәм Яхин

Шәхси һәм архив чыганакларында Яхиннар династиясенә кагылышлы материаллар аз түгел. Ләкин бу чыганаклар күп очракта бер-берсе белән бәйләнешкә кертелмәгән, вакыйгаларның бары тик фрагментларын гына ачалар, аларда шактый төгәлсезлекләр дә очрый.

Яхиннарның шәхси архивында аларның шәҗәрәсенә кагылышлы бер язма саклана. Бу язма машинкада басылган борынгы текстны тәшкил итә, ул гарәп имлясындагы чыганактан алынып кириллицага күчерелгән булган. Шул тарихи язманың башлангыч өлешендә болай дип язылган: *«Байтәвәккәл Байланнары харъясенең олуг байларыннан булып, Байугъланнар харъясе шуңа мәнсүп, шул Байтәвәккәл вакытында өсләренә сыгыш* (сугыш – *Р.Н.*) *килеп, шул вакытт(а) Җәнкилде туган булмак кирәк, валлаһе әгъләм».*

Язманың тарихи кыйммәте шунда ки, ул Татарстан Республикасының Кукмара районындагы Байлангар авылының тарихын ачыкларга ярдәм итә. Бу авылның тарихы Казан ханлыгы чорына тоташа. Аның нигезен язмада искә алынган Байтәвәккәл исемле кеше 1530-1540 елларда сала. Әлеге авыл борынгы чорда «Байугъланнар харъясе» дип аталган, чөнки авылда аның «олуг байларыннан» булган Байтәвәккәлнең уллары яши башлый. Кайбер чыганакларда авыл «деревня Бай Оланнар» дип тә искә алына. Рәсми документларда исә Байлангар авылы 1678 елда теркәлә.



Байтәвәккәл Байланнары Харъясенең олуг байларыннан булып, Байугъланнар Харъясе шуңа мәнсүп, шул Байтәвәккәл вакытында өсләренә сыгыш килеп, шул вакытт Җәнкилде туган булмак кирәк, валлаһе әгъләм.

Тарихы язманың башлангыч өлеше. Яхиннарның шәхси архивыннан

Мәсәлән, XX гасыр башында тарихчы Михаил Худяков үзенең «Очерки по истории Казанского ханства» исемле мәшһүр китабының «Крепостные и рабы» дигән бүлегендә болай дип искәртә: *«Предания говорят, например, что д. Кулларово в Малмыжском уезде получила свое название от рабов («кул»), живших здесь и принадлежавших помещикам, обитавшим в селении Байлянгар («сыновья богача»)».*

Байтәвәккәлнең бер улы сугыш вакытында туа, аңа «Җанкилде» исеме бирәләр. Вакыйгаларның XVI гасырга караганын искә алып, Җанкилденең Казанны Явыз Иван басып алган 1552-1554 еллар тирәсендә туган булуын фаразларга мөмкин.

Яхиннар шәҗәрәсенең башланмасы



Ләкин язманың кыйммәте Байлангар авылы тарихын ачыклауда гына түгел, аның дәвамында хикмәтле мәгълүматлар ята: Байтәвәккәл атлы зат Яхиннар нәселе шәҗәрәсе башында тора. Шәҗәрә чылбырының башлангычын өстәге рәсемнән күрергә була.

Әлеге язма моның белән генә тамамланмый, анда Яхъя хәзрәтнең соңгы көннәре дә языла: *«Яхъя хәзрәт Байугълланнарыдан Керәнле харъясенә килеп, имам булып, угълы Тәмте Нурмөхәммәд хаҗи хәзрәт кунакка алып килгән, шул вакытта Тәмтедә вафат булып, Тәмтедә күмелгән. Әльхале һазиһи өстендә язылмыш таш булып, 99 яшендә язылмыш. Әһлиясе (җәмәгате) Мөхиббә бинте Муса Керәнле зиярәтендә күмелгән».*



Яхъя хәзрәт Байгуьлләннарыдан Керәнле Харьясе-
нә килеп, имам булып, угълы Тәмте Нурмөхәммәд ха-
җи хәзрәт кунакка алып килгән, шул вакытта, Тәмтедә
вафат булып, Тәмтедә күмелгән. Әльхәле һәзиһи әстендә
язылмыш таш булып, 99 яшендә язылмыш. Әһлиясе /җә-
мегате/ Мөхиббә бинте Муса Керәнле зиярәтендә күмелгән

Яхъя хәзрәт турында. Яхиннарның шәхси архивыннан

Монда Татарстан Республикасының Саба районындагы 1678 елда нигезләнгән Керәнле һәм Теләче районындагы Тәмте-Мәтәскә авыллары искә алына. Яхъя хәзрәт 1859 елда 99 яшендә вафат була.

Өстәп әйтергә кирәк, әлеге мәгълүматлар галим Марсель Әхмәтҗановның 2012 елда басылган «Татар шәҗәрәләре» китабында да чагыла: *«Бу шәҗәрәнең асыл нөсхәсе Мөхәммәд Яхинда булып, аны кемдер машинкада басып күчергән. Әлеге күчермәне Казан шәһәрендә яшәүче, шушы нәселдән булган педагог Бәһиҗә ханым, безнең сорау буенча, 1992 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына алып килгән иде, бу текст – шуннан күчермә. Шушы күчермә бүген дә Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондында саклана (99 кол. – 1 тасв. – 225 сакл. бер.)»*.

Яхин фамилиясе Яхъя хәзрәт исеменнән ясала. Яхъя хәзрәт бөтен гомерен дин-исламга багышлаган. Әлбәттә, аның балалары да үзләрен динне үстерүдә, гыйлем таратуда тапканнар. Алар арасыннан имамнар, муллалар һәм остабикәләр чыккан.

Яхъя хәзрәтнең 9 баласы, шул исәптән 7 улы һәм 2 кызы булуы билгеле. Аның балалары турында кыскача шуларны әйтеп китә алабыз:

1. **Яхин Хәбибулла бине Яхъя** (1790-1860) – Күкчәдә имам була (хәзер Күкчә Татарстан Республикасының Теләче районына керә, Тәмте-Мәтәскә авылына күрше авыл булып тора). Әдәби һәм фәнни чыганакларда ул Хәбибулла бине Яхъя Күкчәви исеме белән мәгълүм.

2. **Яхин Габдулла бине Яхъя** – Мәккә-и-Мөкәррәмәдә күп еллар яшәгән, шунда җирләнгән.

3. **Яхин Гыйльман бине Яхъя** (1801-1853) – Сабайда имамлык итә (хәзер Сабай – Татарстан Республикасының Саба районында). Гыйльман абруйлы дин эшлеклесе була. Яхин Гыйльман Сабай авылы зиратында җирләнгән. Аның кабер ташы сакланган.

4. **Яхин Вилдан бине Яхъя** (1833 елда туган) – әтисе Яхъя хәзрәт урынында калып, Керәнледә имам була. Шул авылда җирләнгән. Аның алты баласы (өч улы һәм өч кызы) булганлыгы мәгълүм.

5. **Яхин Мөхәммәтзариф бине Яхъя** (1813 елда туган) – Сеҗе авылында мулла була. Аның улы Бәдретдин дә Сеҗе авылында имамлык итә.

6. **Яхин Нурмөхәммәт бине Яхъя** (1810-як.1895) – Тәмте-Мәтәскәдә имам була. Хаҗга барып хаҗ кылып кайтканлыгы да билгеле.

7. **Яхин Ногман бине Яхъя** (1799-1827) – әлегә шөгыле һәм тарихтагы эзләре ачыкланмады.

8. **Мөһервафа бине Яхъя** – Иске Йортта (хәзер Арча районында) имам әһлиясе була.

9. **Шәмсевафа бине Яхъя** – Чыты авылы (хәзер Питрәч районы җирлегендә) имамы Хөббисолтанга кияүгә чыга, остабикә була.

Яхъя хәзрәтнең балаларының исемнәре шушы схемада күрсәтелгән:

Яхин Гыйльман бине Яхъя (Яхин Гыйльман Яхъя улы) тармагы – күп кенә абруйлы,



Яхъя хәзрәтнең балалары

дан казанган кешеләрне биргән тармак. Яхин Гыйльман Яхъя улы 1801 елда туган. Гыйльман күренекле дин әһеле буларак билгеле, ул Сабайда имамлык кыла. Хәзер Сабай Татарстан Республикасының Саба районына керә. Гыйльман хәзрәт 1853 елда 52 яшендә вафат була, Сабай авылы зиратында җирләнгән. Кабере өстенә таш куелган.

Яхин Гыйльманның ике хатыннан (берсе – Васфиҗамал Хәмит кызы) тугыз баласы, шул исәптән сигез улы һәм бер кызы була:

1. **Яхин Мөхәммәтҗан Гыйльман улы** (1822-...) – Сабайда имам булган, үзен язмаларда «Мөхәммәтҗан бине Гыйльман әс-Сабаи» дип күрсәткән. «Әс-Сабаи» дигән нисбә «Сабайныкы» мәгънәсен белдерә. Мөхәммәтҗан бине Гыйльман Сабайда җирләнгән.

2. **Яхин Әхмәтҗан Гыйльман улы** (1826-...) – Чулпычта имам була һәм кабере дә шул авыл зиратында (хәзерге чорда Чулпыч – Татарстан Республикасының Саба районына кергән торак пункт).

3. **Яхин Шакирҗан Гыйльман улы** (1828-...) – Чулпычта имам була һәм шунда җирләнгән. Аның алты баласы, шул исәптән өч улы һәм өч кызы булуы билгеле.

4. **Яхин Габделгалләм Гыйльман улы** (1832-1910) – Сабайда мөәзинлек итә. 78 яшендә вафат, кабере Сабайда. Габделгалләмнең хатыны Гөлбәширә Габделмән кызы (1834-1890) һәм аларның уллары Габдулла (1862-1918) да Сабай зиратында җирләнгән, кабер ташлары сакланган.

5. **Яхин Габделфәттах Гыйльман улы** (1836-1883) – 1856-1883 елларда Казаклар авылының (хәзерТеләче районына керә) беренче мәхәлләсе имамы була. Кайбер чыганакларда Габделфәттах Гыйльманов буларак искә алына. Яхин Габделфәттах Казаклар авылы зиратында күмелгән.

Яхин Габделфәттахның улы – Яхин Мөхәммәдхаҗи Габделфәттах (Әбделфәттах) улы. Шулай итеп, Яхин Габделфәттах композитор Рөстәм Яхинның бабасы булып чыга.

6. **Бибимәфтүхә Гыйльман кызы** (1833 елда туган) – Мичән Башы авылында мелла Фәйзулла остабикәсе.

7. **Яхин Мөхәммәдхәлил (Хәлиулла) Гыйльман улы** (1839 елда туган) – Мамалайда имам була, шунда җирләнгән. Хәзер Мамалай Татарстан Республикасының Саба районына керә.

8. **Яхин Мөхәммәдгариф Гыйльман улы** – Илдар Яхъяда язылган шәҗәрә тармагыннан алынды. Шул шәҗәрәдә Мөхәммәдгарифның Мөхәммәдсафа исемле улы барлыгы мәгълүм, ә Мөхәммәдсафаның Габделшәфыйк исемле улы булуы күрсәтелә. Габделшәфыйк 1886 елда туган, Сафин фамилиясендә булган (ул 1933 елның 20 мартында кулга алына һәм репрессияләнә). Мөхәммәт Мәһдиевнең әнисе Бибирабиганың фамилиясе дә Сафина булганлыгы билгеле. Моннан Бибирабига белән Габделшәфыйкның бертуганнар икәнлеге күренә.

9. **Яхин Мөхәммәдтаип Гыйльман улы** (1844-1910) – күренекле татар мәгърифәтчесе. Күп кенә әдәби чыганакларда Таиб Яхин дип күрсәтелә. Таиб Яхин Байлангар авылында туган. Казан дарелфөнүнендә һәм Казан татар укытучылар шкуласында (башлангыч материалларда «шкула» дип язылган, КТУШ – Казан татар укытучылар мәктәбе күз алдында тотыла) мөдәррис була.

Гыйльман бине Яхья балаларын бу схемада да күрә алабыз:



Гыйльман хәзрәтнең балалары (туган еллары 1820 нче елдан да ким түгелдер, дип уйларга кирәк)



М.Мәһдиевкә бәйләнешле схема

Шушы мәгълүматларга таянып, күренекле композитор Рөстәм Яхин белән халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең якын туганнар булуын раслаучы схема да төзи алабыз.

Шунысын да әйтергә кирәк, Яхиннар династиясеннән бик күп күренекле шәхесләр чыккан. Тулырак мәгълүмат алырга теләгән кешеләр 2016 елда нәшер ителгән «Яхиннар» китабы белән таныша ала.



Яхиннарның нәсел тамырларын барлау өчен Байлангарга кайту: сулдан уңга – Илдар Яхъя, Рөстәм Яхин, Байлангар мәктәбе директоры Хәтмулла Вәкказов, Ринат Нуруллин, Рөстәм Мәһдиев (Байлангар мәктәбе ишегалдында очрашу. 2015 елның 13 мае, фотограф – Рафис Нуруллин)

Мәгърифәт мәркәзе – Мәчкәрә

Рузалия Шәрәфиева *

Мәчкәрә мәчете

Сүзем Кукмара районының Мәчкәрә авылында урнашкан, Татарстан Республикасының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр исемлегенә кертелгән мәчет бинасы, шулай ук руханилар, милли сәүдәгәрләр, демократик рухтагы зыялылар турында булачак.

Элегрәк Ишмән иле дип йөртелгән, байлары һәм шәкертләре күплеге ягыннан күренекле булган Мәчкәрә авылының XVIII гасыр-XX йөз башындагы үсеше күп яктан татар дөньясында эз калдырып киткән билгеле затлар – **Үтәмешевләр** эшчәнлегенә бәйле.

Үтәмеш Мәчкәрәгә Бөрбаштан күчеп утырган **Ишмән**нең улы була. Үтәмештән – **Габдессәлам**, ә аннан **Мөхәммәдрәхим** һәм **Габдулла**лар туган. Үтәмешевләр – тамырлы нәсел. Аларның безнең як тарихына кереп калган ир туганнарыннан **Әхмәтҗан**, **Гали, Мостафа, Исмәгыйль, Шакир, Абдулла, Муса** һәм **Исхак** исемлеләре бар.

Үтәмешевләрнең инкыйлабка кадәрге берничә буыны тынгысыз һәм тәвәккәл эшкуарлар булган. Татарларны төрлечә кысу, тыю, чикләүләргә карамастан, аларның мәшһүрлеккә ирешүе – хәзерге буын өчен дә үрнәк, хөрмәткә лаек күренеш. Үтәмешевләр атаклы сәүдәгәрләр булып кына түгел, ә халкыбызның мәдәни һәм рухи үсешенә дә өлеш кертүләре белән танылган.

* Рузалия Шәрәфиева – хезмәт ветераны, Россия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы, 1995-2009 елларда Кукмара туган якны өйрәнү музее җитәкчесе һәм фәнни хезмәткәре.

БЕРЕНЧЕ МӘХӘЛЛӘ МӘЧЕТЕ

Ачык һавадагы музейны хәтерләтүче Мәчкәрә авылының кызыклы гына архитектура элементлары да булган иске таш мәчетен 1791 елның азагында беренче гильдия сәүдәгәр **Габдулла Габдессәлам улы Үтәмешев** төзетә. 1793 елда анда беренче намаз укыла. Ул Россиянең башка татар авылларында да берничә дистә мәчет төзетә. Шул исәптән, Казан шәһәренең хәзерге М.Гафури урамындагы, элек «Алтынчы мәчет» дип аталган иске агач мәчет урынындагы ике катлы таш мәчетне дә Габдулла бай салдыра. Ул мәчет һәм пулатлар төзү, озын чокырлар казу һәм башка шундый зур эшләрне башкару өчен Кукмара бакыр заводындагы рус кешеләрен епископ белән куркытып ала торган булган. XIX йөзнең мәшһүр галиме, тарихчы һәм мәгърифәтче Ш.Мәрҗани фикеренчә, Габдулла Үтәмешев *«төбәкнең атаклы эшкуары булган, дәүләтенең зурлыгы, юмартлыгы, гыйлем һәм дингә мәхәббәте, галимнәргә дуслыгы белән шөһрәт казанган»*. Габдулла бай дини мәсьәләләр буенча берничә китап язып, үз чорының укымышлы кешесе дә булган. Шуңа күрә дә аның карамагындагы мәхәллә халык арасында абруй казанып, мәдрәсәсенә ел саен дистәләгән шәкерт җыелган. Бу игелекле кеше йөз яшькә якын яшәп, 1832 елда Мәчкәрә авылында вафат була.

Мәчкәрә мәчетенең беренче имамы – ахун **Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашыти**. Ул – тумышы белән Арча ягындагы Ашыт авылы кешесе. Атасыннан һәм башка укымышлылардан белем алып, үз авылында имам-хатыйп була. Ун ел Дагыстанда гыйлем эстәп кайтканнан соң, остазы **Габделхәмид** Адай авылына күченгәч, Мәчкәрә байларының теләге белән, мелла Мөхәммәдрәхим Мәчкәрәгә имам-хатыйп һәм мөдәррис итеп куела. Шуның өстенә, ул төбәкнең ахуны дәрәҗәсенә дә ирешә.

Мөхәммәдрәхим хәзрәт, мәшһүр остаз һәм мөгаллим буларак, Идел буеның бар төбәгенә таныла. Чибәр, укымышлы егет хатынлыкка авылның бае **Габдессәлам Үтәмешев**нең **Мәхбүбә** һәм **Хәбибә** исемле кызларын бер-бер артлы ала. 1818 елда Мәчкәрәдә вафат була һәм шунда җирләнә.

Мөхәммәдрәхим хәзрәтнең вафатыннан соң, имамлык вазыйфасы Бохарада белем алган **Габдулла бине Яхъя әл-Чиртуши**га йөкләнә. Габдулла Яхъя улы – Чистай төбәгендәге Чиртуш авылы мишәре. Мәчкәрә мәдрәсәсендә Мөхәммәдрәхим ахуннан дәресләр алганнан соң, Бохарада укып кайта. Ахунның **Рабига** исемле кызына өйләнә һәм каенатасына алмашчы имам-хатыйп була. Габдулла хәзрәт тә – үз заманындагы иң мәшһүр мөдәррисләрнең берсе. Озак вакыт шәкертләргә дәрес бирә. 1858 елда бакый дөньяга күчә һәм Мәчкәрә зиратына җирләнә.

Мәчкәрә мәчетенең тагын бер танылган имам-хатыйбы – 1859 елда туган **Әхмәтшәриф Габделбәширов**. Ул 1893 елның 20 декабрендә вафат булган имам **Габдеррахман Сөбханкулов** урынына билгеләнә. Мәчкәрәгә килгәнче, Әхмәтшәриф хәзрәт Оренбург янындагы Сәгыйть бистәсенең (Каргалы авылы) икенче мәчетендә мулла булган.

XIX гасыр ахырында беренче мәхәлләдә яшәүче ир-атлар саны 200дән артык кеше исәпләнгән.

Габдулла Габдессәлам улы Үтәмешев 1791 елда төзеткән ап-ак биналы, яшел калай түбәле мәчетнең манарасы 1940 елда киселә.

ИКЕНЧЕ МӘХӘЛЛӘ МӘЧЕТЕ

Мәчкәрә авылындагы икенче мәхәллә 1800 елда барлыкка килгән. Габдулла Габдессәлам улы Үтәмешевнең хатыны – мелла **Габденнасыйр Курсави**ның бертуган сеңлесе **Мәрхәбә**дән туган егетләрнең берсе **Муса**, Мәчкәрәдә һәм Бохарада бе-

лем алганнан соң, оста сәүдәгәр һәм талантлы дин галиме буларак абруй казана. Ул Г.Курсавиның якын дусты һәм тарафдары була, христиан дине мәсьәләләренә багышланган китаплар яза, берничә тапкыр поплар һәм башка рус укымышлылары белән дә бәхәскә керә. 1800 елда Мәчкәрә авылында булган мәҗүси арларны үз янына чакырып, алтмыштан артыгын ислам диненә кертә. Аларга агачтан мәчет салдырып, икенче мәхәллә ачтыра һәм үз йортын да шул мәхәлләгә күчерә. 1835 елның азагында Мәчкәрәдә вафат була һәм шунда җирләнә. Ул салдырган мәчет 1871 елда янгын чыгу сәбәпле янып бетә.

Агач мәчет урынына хәзерге көндә клуб хезмәтен үтәүче бер катлы таш гыйбадәтханәне Муса Үтәмешевнең улы **Исхак** 1872 елда 700 сум акчага салдыра. Бу мәчетнең проекты бик үк заманча булмый. Исхак шул ук елда вафат була һәм Мәчкәрә зиратына җирләнә.

Икенче мәчеттә эшләгән танылган имам-мелла **Таһир бине Габделхаликъ әт-Түнтәри** 1844 елда вафат булып, васыяте буенча, авыл халкыннан сатып алган җирдә дәфен кылына. Кабере – зираттан ерак, икенче тарафта, кешеләрдән читтә. Аның турында бик изге, тәкъва, диндар һәм яхшы кеше иде, дип сөйлиләр. Таһир имам төрле мәҗлес һәм байгура, түрә-кара җыенынннан читтә торган, барына да канәгать булып гомер иткән, сабыр һәм аз сүзле булган, дөнья мәшәкатьләреннән баш тарткан һәм һәрвакыт гыйбадәт кылып яшәгән.

Мәчетнең имам-хатыйпларыннан 1886 елның маенда билгеләнгән **Мөхәммәднәҗип улы Әбүбәкер Еникеев** исеме дә мәгълүм (1856 елда туган). XIX гасыр ахырында икенче мәхәлләдә ир-ат затыннан 205 кеше исәпләнгән.

МӘДРӘСӘЛӘР – БЕЛЕМ УЧАГЫ

Мәдрәсәләрдә, дини фәннәр белән беррәттән, дөньяви фәннәр – логика, философия, астрономия, физика, химия, география, анатомия, гигиена да укытылган, матур язу, физик тәрбия, җыр, рәсем буенча да күнекмәләр бирелгән. Шәкертләр тәбәнәк өстәл артына тезләнеп түгел, ә бәлки гигиена кагыйдәләренә нигезләнеп ясалган парталарда утырган. Дәресләрдә күргәзмә әсбапларны файдалану кертелгән. Шәкертләр дистәләгән дәреслек, кулланма, сүзлектән файдаланган. Мәдрәсәнең эчке тәртип кагыйдәләре, зур хәрефләр белән язылып, диварга беркетелгән. Аларны бозучылар штрафка дучар ителгән. Мәсәлән, баскычтан йөгереп йөргән укучы – ике тиен, өс киемен кимичә генә урамга чыгучы өч тиен штраф түләгән. Китаплар саны күп булса да, бер генә дә ертылган, буялган, сызгаланган китап булмаган.

Мәчкәрә мәдрәсәсендә Казан, Уфа, Вятка губерналарының булачак руханилары гына түгел, Себер, башкорт, казакъ далаларыннан да килеп укыганнар. Заманының олуг шәхесләреннән мәшһүр акыл иясе **Каюм Насыйриның әтисе Габденнасыйр** һәм **Фатыйх Әмирхан**ның бабасы, тарихчы **Хөсәен Әмирхан** да белемне биредә алган. Татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикер тарихында күренекле галим, философ **Шиһабеддин Мәрҗанинең** бабасы **Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани** (1746-1833) һәм атаклы фикер иясе, дин белгече **Габденнасыйр Курсави** (1771-1812) да Мөхәммәдрәхим ахунда укыган.

Болардан кала, Мөхәммәдрәхим ахунның шәкертләре арасында **мелла Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла әс-Сабавый** (1833 елда үлгән), **Нигъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрлебашый, мелла Габдессаттар бине Сәгыйд әш-Шырдани** (1831 елда вафат булган), **мелла Шаһиәхмәд бине Рәфыйк әс-Симәки** (1785-1835), **мелла Таҗетдин бине Габдеррәшид әл-Иштирәки** (1841 елда дөньядан киткән), **мелла Гали бине Сәйфулла әт-Түнтәри** (1874 елда үлгән), **мелла Таһир бине Сөбхан әл-Мокърый**

Ю.Гагаринны космоска әзерләгән космонавтика һәм медицина техникасы белгече Үтәмешев Рөстәм Исмәгыйль улы туган йорт. Кукмара районының Мәчкәрә авылы

(1774-1864) кебек танылган шәхесләр дә бар. Тумышы белән Мәмәшир авылыннан булган, Мәчкәрә мәдрәсәсендә укыган **Җамалетдин Бикташи** да – галим һәм мәгърифәтче булып танылган кеше.

Даны еракларга барып ирешкән Мәчкәрә мәдрәсәсенең, кызганыч ки, бернәрсәсе дә сакланмаган. Шулай да аның нигезе кайда булганлыгы билгеле. 1999 елның җәендә Кукмара районында беренче мәртәбә үткәрелгән археологик экспедиция үзенең казу-тикшерү эшләрен Мәчкәрә авылында да алып барды. Экспедиция әгъзаларын авылның төньяк өлешендә урнашкан мәдрәсә урыны да кызыксындырды. Мәдрәсәнең нигезе Сәрвәр әбинең бакчасына туры килгәнлектән һәм нык кына җимерелгәнлектән, аның тулысы белән нинди зурлыкта икәнлеген ачыклый алмадылар. Бәлки яңа экспедицияләрдә бу бина нигезе ныклабрак тикшерелер.

Мәчкәрәнең икенче мәдрәсәсе – мулла Нәҗип Еникеевнеке. Анда теләге булган крестьян балалары сабак алган. Бу мәдрәсәдә шәкертләр идәнгә утырып укыган, үзләре чиратлашып ягарга утын күтәреп килгән. Хакимият мөселман мәктәп-мәдрәсәләренә акча бирү турында уйлап та карамаган. Бу Малмыж музеенда сакланган «Журналы Малмыжского уездного земского собрания» (Вятка: Типография и хромолитография Шкляевой, 1907 г.) дигән бер документтан да күренә. Өяз земство җыенына Әхтәм Әхмәтов фамилияле берәү, татар мәктәпләренә утын алу өчен, казнадан 600 сум акча сорап гариза яза. Әмма үтенеч канәгатьләндерелми. Әле ярый мөселман руханилары, эшкуарлар, татар зыялылары, милләтпәрвәр кешеләр иганә акчасын өзмәгән.

Тарихи истәлекләр – борынгылардан калган бәһасез мирас. Аларны киләчәк буынга саклау – безнең өчен олы бурыч. ■

Безнең мирас №8 август 2018

ЯПОНИЯНЕ ачкан татар галиме

(Әбрар Кәримуллин язмаларында япон темасы)

Фәүзия Бәйрәмова

XX гасыр башында ерак япон илен татарлар өчен күренекле дин галиме, милли сәясәтче Габдерәшит Ибраһим ачкан булса, гасыр ахырында бу эшне академик Әбрар Кәримуллин башкарды, ә XXI гасырда яшь галимә Лариса Усманова дәвам итте. Габдерәшит Ибраһим һәм Лариса Усманова бу ил турында Япониядә яшәп язсалар, Әбрар Кәримуллин япон галимнәре белән тыгыз элемтәгә кереп, халыкка аларның хезмәтләре аша бик күп яңа мәгълүмат җиткерде. Һәм халык дөрес мәгълүматка иң мохтаҗ вакытта, илләр арасын аерып торган «тимер пәрдә» ишелеп төшкән заманда, Әбрар ага дөнья татарлары турында матбугатта берсеннән-берсе кызыклырак язмалар бирә башлады. Бу – туксанынчы еллар башы Әбрар Кәримуллинның татарлар турында гомер буе берәмтекләп җыйган, эзләнгән, тапкан материаллары матбугатта басыла башлаган вакытлар иде. Аларның һәрберсен милләт Америка ачкандай кабул итте – Кытай, Корея, Япония татарлары турында, Төркиядә яшәүче мөһаҗир милләттәшләребез, Америка, Финляндия, Канада, Польша татарлары язмышы хакында гаять мәгълүматлы һәм үзәк өзгеч язмалар... Ул вакытта милли газеталарыбыз да бик кыю булган, Әбрар аганың «ут уйнаткан» язмаларын «Шәһри Казан», «Татарстан яшьләре», хәтта «Социалистик Татарстан», «Татарстан хәбәрләре» газеталары да көтеп алып бастырган, «Мирас», «Идел» журналлары аның көрәш мәйданына әйләнгән. Әбрар ага вакытында әйтәсен әйтеп калдырган, аннан ул язмаларын аерым китапларда да бастырып чыгарган. Тарих өчен, безнең өчен кыйммәтле мирас калдырган...

Әбрар Кәримуллин югарыда санап киткән ил-җирләрнең күпчелегендә шәхсән үзе булган, анда фәнни җыеннарда катнашып, чыгышлар ясаган, архивларда, китапханәләрдә эшләгән, милләттәшләребез белән очрашкан. Ә менә аның Япониядә булу-булмавы турында бездә мәгълүмат юк, әйткәнебезчә, ул бу ил белән аның галимнәре аша элемтә тоткан, аларның үзләрен Казанга чакырып китергән. Нәтиҗәдә, Япониядә татарлар турында басылган бик күп тарихи хезмәтләрнең күчермәләрен, шулай ук шактый китапларны ул Татарстанга кайтарта алган. Үзе дә Япониягә татар тарихы, аның бүгенге хәле турында кочак-кочак китап җибәргән, ике арада еллар буе посылка-бандерольләр, хатлар йөреп торган. Ул заманда бездә интернет юк иде бит, бөтен эш, элемтә почта аша бара иде, Әбрар ага шушы хәлдә дә читтә яшәүче татарлар турында дөнья хәтле материал туплый алган, аны үз вакытында халыкка

Әбрар ага шушы хәлдә дә читтә яшәүче татарлар турында дөнья хәтле материал туплый алган, аны үз вакытында халыкка җиткереп барган.

җиткереп барган. Хәзер без аның япон-татар бәйләнешләре турындагы кайбер язмаларына күчәбез. Башта Әбрар Кәримуллинның үзенә сүз бирик, ул Япония темасына ничек кереп киткәнен бәян итәр: *«1989 ел иде. Бер халыкара конгресста Япониянең Токио университеты профессоры* ***Тадаши Сузуки*** *исемле ориенталисты белән танышкан идем. Чит илләрдәге татарлар язмышы белән кызыксына һәм алар турында материаллар туплау белән шөгыльләнә башлаган чагым. Сузуки белән дә шул хакта сөйләштек. Ул Японияга кайткач, ике япон галименең адресын җибәрде, аларның татар халкы тарихы белән кызыксынулары һәм шуңа караган хезмәтләре дә барлыгын хәбәр итте. Аларның берсе –* ***Хисао Комацу****, икенчесе –* ***Ивао Камозава****, һәркайсы шәрык белгече. Тиздән безнең арада хатлар, китаплар йөри башлады. Мин аларга татар халкының мәдәнияте басмаларын җибәрәм, ә алар Япониядә шәрыкне өйрәнүгә караган басмалар юллыйлар...»* (Әбрар Кәримуллин. Япония вә төрки-татарлар // Социалистик Татарстан, 1991, 26 июль; Әбрар Кәримуллин. Язмыш, язмыш... – Казан, 1996, 79 б.)

Әбрар ага менә шушы ике япон галиме белән гомеренең ахырына кадәр аралашып яши, әйткәнемчә, аларны Казанга да китертә ала. Ә иң мөһиме – алар ярдәме белән, ул Япониядән татарлар турында күпме кыйммәтле материал кайтарта! Әбрар ага бигрәк тә Хисао Комацу белән бик тыгыз элемтәдә тора, аны «дустым» дип атый. *«Күптән түгел миңа дустым – япон профессоры Хисао Комацудан бандероль килеп төште,* – дип яза ул. – *Анда ул үзе һәм хатыны Каурый белән бергә татар теленнән япон теленә тәрҗемә иткән Рәшит казый Ибраһимовның әле генә Токиода басылып чыккан «Япония сәяхәте» китабын һәм «Милли байрак» газетасының бер санын җибәргән. Дөресрәге – бу газетаның 1936 елда чыккан (15 январьдә) унберенче санының ксерокопиясе».* (Әбрар Кәримуллин. Язмыш..., 92 б.)

Әбрар аганың икенче бер мәкаләсеннән күренгәнчә, Япониядән бу кадерле бүләк 1992 елның мартында килгән. *«Быел март башында килгән ике бандероль турында җентекләбрәк сөйләп үтәсем килә,* – дип яза ул. – *Аның берсен Япониядән Токай университеты профессоры җибәргән. Ул – атаклы татар милли азатлык өчен көрәш ли-*

Әбрар Кәримуллин



Япон галиме Хисао Комацу Татарстанга тәүге тапкыр Әбрар Кәримуллинның шәхси чакыруы буенча килгән булып чыга.

деры, публицист, философ Рәшит казый Ибраһимның «Япония сәяхәтнамәсе». Бу 412 биттән торган китап 1991 елның ахырында Токиода япон телендә басылган». (Әбрар Кәримуллин. «Татарика» тирәсендә // Шәһри Казан, 1992, 8 апрель.)

Алга таба бу мәкаләсендә ул Габдерәшит Ибраһим турында шактый тулы һәм гадел мәгълүмат биргән, аны: «*...патша куштаннарының татарларга каршы геноцидын ачып салган монографияләр авторы, татар халкының милли азатлыгы өчен ару-талу белмичә көрәшкән каһарман зат*», – дип атый. (Шунда ук.) Автор шулай ук сәяхәтнамәнең тәрҗемәчесе һәм дөньяга чыгаручы Хисао Комацу турында да шактый тулы мәгълүмат биргән: «*Хисао Комацу заманында Төркиягә килеп белемен камилләштергән. Казан университеты профессоры Н.Ф.Катановның Истанбул университетында сакланучы китапханәсендәге татар басмалары белән танышкач, безнең халык тарихы буенча специальләшүгә күчкән. Үзенең бу өлкәдәге белемен үстерү, татар чыганаклары белән танышу өчен 1991 елда ул минем чакыру буенча Казанга килде, китапханәләрдә эшләде*». (Шунда ук.)

Димәк, япон галиме Хисао Комацу Татарстанга тәүге тапкыр Әбрар Кәримуллинның шәхси чакыруы буенча килгән булып чыга. Автор япон галименең Казаннан Япониягә татар китаплары тутырып уннан артык посылка җибәрүен, Милли китапханәдә Габдерәшит Ибраһимның Япония турындагы язмаларын укып чыгуын да хәбәр итә. Укучы шулай ук Хисао Комацуның япон телендә Шиһабеддин Мәрҗани, Риза Фәхреддинов турында мәкаләләр бастырып чыгаруы, Ибн Фадланның сәяхәтнамәсен япон теленә тәрҗемә итүе турында да мәгълүмат ала.

Әбрар аганың башка язмаларыннан күренгәнчә, Хисао Комацу аңа кадәр дә Казанга татар тарихы турында кыйммәтле китаплар җибәргән була. «*Миңа әле генә Токио университеты профессоры Хисао Комацудан бер бандероль килеп төште,* – дип хәбәр итә ул. – *Бандерольдә ике китап. Аның «Татарларның кыскача тарихы» дигәне 1988 елда Кытайда, гарәп шрифты белән татар телендә басылган. Авторы Хәнифә Абдулла бу хезмәтендә Кытайның Цинзянь милли округында яшәүче татарларның тарихын яза. Анда хәзерге вакытта 5000 чамасы милләттәшебез яши икән. Бандерольдәге икенче китап М.Солтангалиев турында. Ул 1990 елда япон телендә чыккан, 383 биттән тора. Монографиянең авторы – Токио университеты профессоры* ***Масаюки Юмачи****. Хезмәтнең исеме – «Солтангалиев хыялы: Ислам галиме һәм Россия революциясе»*. (Әбрар Кәримуллин. Дәүләтләр, кыйтгалар буйлап // Шәһри Казан, 1991, 16 февраль; Әбрар Кәримуллин. Язмыш, язмыш... – Казан, 1996, 77 б.)

Әбрар Кәримуллин бу язмасында Мирсәет Солтангалиев турында япон телендә чыккан китап белән татар укучысын да таныштыра. Хезмәтнең нинди бүлекләрдән торуын, Солтангалиевнең милли азатлык өчен көрәш тарихын яктыртуын хәбәр итә, шулай ук китапта татар тарихы белән бәйле бай материал бирелүен, Казан белән бәйле карталар һәм рәсемнәр дә урнаштырылуын яза. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Әбрар ага үз кулына килеп кергән яңа материалны, кайбер татар галимнәре кебек, өстәл астына яшереп куймый иде, ул аны тизрәк халыкка җиткерергә ашыкты, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрде.

Шунысын да әйтергә кирәк, Солтангалиев турындагы китап авторы белән Әбрар Кәримуллин инде элегрәк тә таныш була. «*1990 елда Казанда Токио университеты профессоры Масаюки Ямаучи булып китте,* – дип яза ул. – *Татар галимнәре, татар тари-*

хы буенча бездә чыккан хезмәтләр белән танышасы, архивларда, китапханәләрдә эшлисе килгән. Ул татарлар тарихы турында күп белә, күп эшли икән. «Солтангалиев хыялы...» дигән зур китап язган булып чыкты. Соңгы елларда япон телендә ике тапкыр басылган – 1986, 1990 елларда. М.Солтангалиев турында 1978 елда ук «Ислам дөньясы һәм 1917 елгы урыс революциясе: Солтангалиевнең социаль революция тәгълиматы» дигән мәкалә язган. Ә 1981 елда «Солтангалиев һәм Оттоман империясе» дигән күләмле мәкаләсе дөнья күргән. Татар милли азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе Вәисов һәм вәисовчылар хәрәкәте турында да язган». (Әбрар Кәримуллин. Япония вә төрки-татарлар // Социалистик Татарстан, 1991, 26 июль; Әбрар Кәримуллин. Язмыш..., 83 б.)

Әбрар ага үз кулына килеп кергән яңа материалны, кайбер татар галимнәре кебек, өстәл астына яшереп куймый иде, ул аны тизрәк халыкка җиткерергә ашыкты, фәнни әйләнешкә кертеп җибәрде.

Чын галимнәргә хас рәвештә, Әбрар Кәримуллин япон каләмдәше турында укучыларга күбрәк мәгълүмат җиткерергә тырыша. Аның мәкаләсеннән күренгәнчә, ***Масаюки Ямаучин***ың Солтангалиевтән кала да татар тарихына кагылышлы фәнни хезмәтләре шактый икән. Ул шулай ук Россиядә һәм СССРда мөселман хәрәкәтенә, суфыйчылыкка, Кавказ халыкларының милли һәм дини азатлык көрәшчесе имам Шамилгә багышланган хезмәтләр дә язып бастыра. Тагы шунысы кызыклы, Әбрар аганың мәкаләсеннән күренгәнчә, *«Ямаучи, Хисао Комацу һәм Коичира Кояма белән бергә, япон теленә Зәки Вәлидинең автобиографиясен тәрҗемә итә һәм ул 1976 елда Токио журналының өч санында бирелә».* (Шунда ук.)

Әбрар ага бу мәкаләсендә Хисао Комацу белән ничек танышып китүләрен, аны Казанга чакыру тарихын да ачкан. Башта япон галиме аңа 1983 елда Токио журналында басылып чыккан «Бохара һәм Казан» дигән мәкаләсен җибәрә. Татар галиме исә Хисао Комацуның фәндә бик әзерлекле кеше булуына, аның төрек, татар, үзбәк, хәтта урыс телен дә белүенә игътибар итә, ул аңа хатларны да латин хәрефләре белән татарча язган. Хисао Комацу алда телгә алган мәкаләсендә XVII-XIX гасырларда Идел

Хисао Комацу. Төркия. Габдерәшит Ибраһимга багышланган халыкара фәнни конференциядә. 2012 ел, 22 май

буе һәм Урта Азия арасындагы дини һәм мәдәни багланышлар турында сөйли, шунда мәдрәсә тәмамлаган татар зыялыларына аерым туктала, Мәрҗанигә зур бәя бирә. Татар халкының акыл ияләре турында күбрәк белү өчен, ул академик Әбрар Кәримуллинга мөрәҗәгать итә.

«Соравын үтәп, аңа М.Гайнуллинның татар әдәбиятына караган китапларын җибәрдем һәм төрле белешмәләр юлладым, – дип яза бу турыда Әбрар ага. – *Хисао Комацу: «Татар тарихыннан мондый китапларны беренче күрүем, алар белән күбрәк танышасым килә, шуңа күрә Казанга килер идем», – дип язды. Аны кунакка чакырдым. Ул минем «Татары: этнос и этноним» дигән хезмәтемә бәяләмә дә бастырган».* (Шунда ук.)

Әбрар Кәримуллинның «Сөенечле күренеш һәм... битарафлык» дип аталган икенче мәкаләсеннән күренгәнчә, Хисао Комацу Казанга 1991 елның августында килгән булырга тиеш, чөнки шул көннәрдә «Шәһри Казан» газетасында аның белән очрашу була. 5 август көнне газета битләрендә япон галиме белән әңгәмә дә басылып чыга. Әбрар аганың язуынча, Хисао Комацу Япония университетларында төрки-татар халыкларының теле, әдәбияты һәм тарихы буенча дәресләр дә бирә икән, ул шулай ук безнең бик күп шәхесләребез турында фәнни хезмәтләр дә язган кеше. Япон галиме, Казаннан тыш, Болгарда да булган, бу турыда Әбрар ага менә ничек яза: *«Татар галимнәре, әдипләре белән очрашты, Болгарга сәяхәткә барып, бабаларыбыз эзләреннән йөрде, борынгы һәйкәлләребез белән танышты. Ибн-Фадланның Болгар илебезгә сәяхәтен эченә алган «Рисалә»сен япон теленә тәрҗемә итүчеләрнең берсе буларак, Болгарга бару аның өчен иң мөкатдәс бурычы, теләге булган. Хисао Комацу Бөтендөнья татар яшьләренең икенче халыкара фестивалендә дә катнашты, Япония һәм андагы татарлар исеменнән котлау сүзләре белән чыкты».* (Әбрар Кәримуллин. Сөенечле күренеш һәм... битарафлык // Шәһри Казан, 1991, 6 ноябрь.)

Шунысын да әйтергә кирәк, 2012 елда миңа да Хисао Комацу әфәнде белән бергә Төркиядә фәнни конференциядә катнашырга туры килде, бу чаралар Габдерәшит Ибраһимга багышланган иде. Без – төрек, татар, япон, алман галимнәре Габдерәшит хәзрәт нигез салган себер татарлары авылы Бөгередәлектә булдык, аның истәлегенә урман утырттык, район үзәге булган Җиһанбәйледә Габдерәшит Ибраһим исемендәге паркны ачтык. Ә инде 22-23 май көннәрендә Кония шәһәренең Сәлчүк университетында «Төрек-япон багланышлары үзәгендә – Габдерәшит Ибраһим» дип аталган халыкара фәнни конференциядә катнаштык. Хисао Комацу төрек телендә Габдерәшит Ибраһим турында төпле доклад ясады, башка япон галимнәре дә төрекчә сөйләде. Мин исә Габдерәшит хәзрәтнең туган каласы Тарадан төшереп алып килгән фотоальбомның презентациясен уздырдым, Габдерәшит Ибраһимның татар милли сәясәтенең үзәгендә торуы, чыгарган газеталары, төзегән оешмалары, динебез һәм милләтебез өчен кылган гамәлләре турында сөйләдем. Соңыннан безнең чыгышлар Кония шәһәрендә аерым җыентык булып та басылып чыкты. (Abdurresit Ibrahim. Uluslararasi Abdurresit Ibrahim ve Turk-Japon iliskieleri bilgi soleni 22-23 mayis 2012? Konya. BILDIRILER. – Konya, 2012.)

Азагы бар ■

Ризаэддин Фәхреддин
гыйбарәләре

- Укытучы тәрбиясеннән күреләчәк файда, фәкать гыйлем булдыгыннан гына булмыйча, бәлки болар белән бәрабәр, аның шәфкатьле һәм мәрхәмәтле булуыннан да күренеп тора.
- Бала тәрбияләү – ананың гаиләдәге генә түгел, ә бөтен җәмгыять алдындагы изге һәм җаваплы бурычы.
- Тәрбия – акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру, димәктер.
- Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да үзгәртә алмас.
- Гыйлем вә тәрбия орлыкларын хәзер ихлас мәхәббәт илә чәчсәгез, киләчәктә файдалы җимешләрне дә үзегез җыярсыз.
- Тәрбиялелеккә өйрәтмәү – тәрбиясезлеккә өйрәтү буладыр.
- Халыкларны да, аерым затларны да бәхет мәйданына алып чыга торган юлларның иң тугрысы – гүзәл холык белән яхшы тәрбиядер.
- Балаларны гүзәл тәрбияләүдә иң мөһим булган шарт – тәрбияләүче ата вә ананың вә яки болар вазыйфасын башкаручыларның (опекуннарның) үзләре тәрбияле булуыдыр.
- Тәрбиянең асыл чоры картлык түгел, бәлки яшьлек заманыдыр.
- Бала тәрбиясе хакында булган хезмәтләрнең иң бөеге – аналар өстендәдер.
- Адәм баласы үзен-үзе тәрбияләргә һәм камилләштерергә тиеш, буй җиткән һәр кеше үзен-үзе тәрбияли ала.
- Бала тәрбияләү кара күңеллелек вә катылык белән түгел, бәлки йомшаклык, сабырлык, шәфкатьлелек, аңлылык белән буладыр.
- Ата вә ана өчен тәрбияле бала дәрәҗәсендә олуг байлык һич булмас.
- Тәрбия итүченең тырышлыгы нәтиҗәсендә балаларда булган көч-куәтләр, табигый булган сәләтләр эш эшләргә хәзерләнер.
- Гыйлем тарату, халыкка ярдәм бирү өчен тырышу – иң гүзәл гайрәттер.
- Дөнья байлыгы туплауда олуг бер көч куеп тырышырга кирәк булганы кебек, гыйлем өйрәнүдә яки өйрәтү гамәлендә исә тагын да артыграк тырышырга кирәктер.
- Укытучы булган кешенең һәр мөгамәләсендә игътибарлы булуы тиеш булган кебек, гыйлем тарату һәм мәгърифәт үзләштерү мәсьәләсендә гадәттән тыш игътибарлы булуы – иң гүзәл бер вазыйфадыр.
- Укытучы – гыйлем өйрәтүче һәм балаларның җанын тәрбияләүче.
- Тырышлык – акыл вә фикергә, шулай ук тән һәм әгъзаларга зарар китермәс рәвештә тырышу.
- Әгәр гакыл базарларда алтын бәрабәренә сатылса иде, адәм угыллары соңгы нәрсәләрен сатып, гакыл алу өчен йөгерешерләр иде.
- Бәрәкәтле адәм шул булыр: сүзенә караганда, эше күп вә тышына караганда, эче яхшы булыр.
- Уку – олы бәхет һәм укып белгәннәр белән гамәл итү – зур бәхет һәм фазыйләт ул.

***Диләрә Гыймранова** әзерләде.* ■

2018 ЕЛНЫҢ 1 АВГУСТЫНДА БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЫ РИНАТ ЗАКИРОВКА 70 ЯШЬ ТУЛА.

РЕСПУБЛИКАБЫЗГА ҺӘМ ТАТАР ХАЛКЫНА ФИДАКАРЬ ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ

Хөрмәтле Ринат Зиннур улы!

Сезнең 70 яшьлек юбилеегыз – Татарстан һәм татар халкы тормышында мөһим вакыйга. Хезмәт сөючән авыл гаиләсендә чыныгып үсеп, инженер-химик һөнәрен алганнан соң, Сез бөтен гомерегезне идарә итү, мәдәният һәм кеше тәрбияләүгә багышладыгыз. Үзегез сайлаган барлык юнәлешләрдә дә иң югары үрләргә күтәрелдегез.

Сезнең яшь буынны тәрбияләүдә, педагогика буенча кандидатлык диссертациясен яклауда, иҗат берлекләре, мәдәният, сәнгать хезмәткәрләре, эшкуарлар белән эшләүдә, яңа оешмалар үстерүдә тупланган тәҗрибәгез «Казан» милли-мәдәни үзәген

оештыру, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетын җитәкләү елларында тулысынча ачылды. Сез, татар халкы тарихы буенча докторлык диссертациясе яклап, милли җәмгыятьләрнең эшен куәтләдегез, Бөтендөнья татар конгрессы каршында авыл эшкуарларын, татар яшьләрен, туган якны өйрәнүчеләрне, татар хатын-кызларын берләштерүче җәмгыятьләр эшчәнлегенә көч бирдегез, дин әһелләре белән милли җәмәгатьчелекнең хезмәттәшлеген җайга салдыгыз, эстрада, музыка, хореография коллективларын үстердегез. Бу гамәлләрдә Сез үзегезнең милләт юлында фидакарьлек һәм дәрт белән эшли алуыгызны исбатладыгыз һәм исбатлап киләсез.

Үзегезнең 70 яшьлек юбилей көннәрегездә Сез Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә яшәүче татар җәмгыятьләренә ярдәм итүегез һәм аларны туплавыгыз белән горурлана аласыз. Россия Федерациясенең дистәләрчә төбәкләрендә һәм чит илләрдә Татарстан Республикасы һәм Татар конгрессы ярдәмендә мәдәниятне, мәгърифәтне үстерү, кадрлар әзерләү, яшь буынның милли үзаңын, милләттәшләрнең хакимият һәм икътисад вәкилләре арасында багланышларын ныгыту кебек мәсьәләләрне хәл иттегез.

Катлаулы һәм җаваплы урыннарда озак еллар эшләп, Сез һәрвакыт максатчан хәрәкәт иттегез, халкыбызга ярдәм итү өчен барлык көчегезне һәм тәҗрибәгезне кулландыгыз.

Хөрмәтле Ринат Зиннур улы!

Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы коллективы һәм шәхсән үземнең исемнән Сезне 70 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм! Корычтай нык саулык-сәламәтлек һәм шәхси тормышыгызда бәхет телим!

Васил Шәйхразиев,
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары,
Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы рәисе

Ркаил Зәйдулла

Ышаныч

Ринат Закировка

Томалаган кара болыт...
Сиздерми һәм бик сак кына
Кояш үтеп керә барыбер
Туган җирнең туфрагына.

Элекке бабайлар сыман
Җиргә куеп колагыңны,
Ишетәсеңме, җылы иснәп,
Бөҗәкләрнең елаганын?

Анда гел кысыр хәрәкәт, –
Шулмы күңелне җилкетә?
Ә өстән энә карагы,
Кигәвеннәр очып үтә.

Таралыр ул кара болыт!
Кояш чыгар һәм челтерәп
Ләйсән явар сөенеч булып, –
Фәкать ышанырга кирәк.

Гөл ачылыр, су яктырыр,
Гел яңача балкыр төсләр.
Яфрак астына күченер
Мең күзле бу үрмәкүчләр.

Ләкин бүген хәлләр хәтәр,
Күренми бер тәрәге дә...
Таянасы калды бары
Һәркемгә үз йөрәгенә.

18.07.2018 ■

Кукмара муниципаль районы башлыгы
СЕРГЕЙ ДИМИТРИЕВ:
«Кукмараның төп байлыгы – аның халкы»

Кукмара районы оешуга 2020 елда 90 ел була, ә археологик казылмалар буенча аңа 700 елдан артык диган мәгълүмат бар. Район республиканың 4 районы, Киров өлкәсе һәм Удмуртия Республикасы белән чиктәш. Күршеләребез белән тел-лөгать алмашып, мәгариф, мәдәни, икътисади өлкәләрдә хезмәттәшлек итеп яшибез.

Район – күпмилләтле. 123 авылның 81е – саф татар авыллары. Зур Сәрдек авылында – 1 меңнән артык, Зур Кукмара авылында 2 мең кеше яши. Алар – Россиянең иң зур татар авыллары исемлегендә. Районда 51 меңнән артык санлы 29 милләт вәкиле яши. Татарлар – 78%, удмуртлар – 14%, руслар – 6%, марилар – 1,2% һәм башка милләтләр. Авыл балалар бакчаларында, мәктәпләрдә тәрбия һәм белем бирү ана телендә алып барыла. Кукмара шәһәренең 10 балалар бакчасының берсе тәрбия эшен бары тик татар телендә алып бара, шулай ук 1 нче татар гимназиясе дә эшләп килә.

Кукмара – авыл хуҗалыгы районы. Авыл хуҗалыгы җитештерүендә төп юнәлешләр – терлекчелек һәм игенчелек. Җитештерүгә инновацияле технологияләр кертү (3000 башка исәпләнгән терлекчелек комплекслары бар, аларның саны артачак), терлекләрне азык үзәкләреннән балансль, югары сыйфатлы азык белән тәэмин итү нәтиҗәсендә, тәүлеклек сөт җитештерү күләмен 250 тоннага җиткерә алдык. Бу – Россиянең муниципаль районнары арасында иң югары күрсәткеч. Шәхси хуҗалыкларны үстерүгә дә зур игътибар бирәбез. Аларга дәүләт кысаларында грантларга катнашырга булышабыз. Нәтиҗәдә, бүген Зур Сәрдек авылы җирлегендә 1 шәхси хуҗалыкка исәпләгәндә 621 мең сумлык авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерелә. Россиянең итек басучылары белән дан тоткан иң зур татар авыллары Шыгырдан, Гали, Әләзән белән рәттән торган Туенбаш авыл җирлегендә –587 мең сум.

Гомумән, авылларыбызны саклауга һәм үстерүгә зур игътибар бирәбез. Бүген Татарстанда тормышка ашырылучы федераль һәм республика программаларының күбесе авыл җирлекләрендә гамәлгә керә. Алар авыл кешеләре, беренче чиратта балалар һәм яшьләр өчен тиешле шартлар булдыруга юнәлтелгән. Программа проектларын формалаштырганда һәр җирлектә нинди дә булса объект төзүне күздә тотабыз. Кечкенә авыллар өчен башлангыч мәктәп, балалар бакчасы, клубы булган объектлар төзү юнәлешендә эш бара. Тел, гореф-гадәт, мәдәниятне саклау һәм үстерүнең урыны да авылларыбыз бит. Һәр милләтнең төп бәйрәмнәрен зурлап уздыруны максат итеп куйдык.

Федераль дәрәҗәдәге бәйрәмнәр дә кукмаралылар катнашында уза. Курган өлкәсенең Әлмән авылында узган IX Бөтенроссия авыл Сабан туе. 2018 ел, 14 июль

Фото http://president.tatar.ru сайтыннан алынды

Производствога яңа технологияләр керү сәбәпле, предприятиеләрдә эш урыннары кыскара. Әлбәттә, без районыбызда сакланып калган 150 елдан артык тарихы булган киез-киез итек комбинаты, товарлары чит илдә дә сатылучы металл савыт-сабалар заводы, балалар һәм өлкәннәр өчен сезонлы кием җитештергән тегү фабрикасы белән горурланабыз. Аларның товарлары белән күргәзмәдә таныша аласыз. Яңа производстволар ачу юнәлешендә дә эшлибез. Районда эшләп килүче өч сәнәгать мәйданчыгында гына да узган ел ярты миллиард сумнан артык күләмдә товар җитештерелде. Яңа төзелгән сәнәгать паркында ике дистәгә якын резидент булыр дип көтәбез. Район халкы үзенең тырышлыгы, булдыклылыгы, һөнәрле булуы белән дан тота. Бүген гомуми товар җитештерү күләмендә эшмәкәрлекнең өлеше – 38%. Ул елдан-ел арта бара.

Әлбәттә, Кукмараның төп байлыгы – аның халкы. Аларга яшәү, эшләү, дәүләт тарафыннан гарантияләнгән хезмәтләрдән файдалану өчен тиешле шартлар тудырылган. Сәламәтлек саклау буенча да район үзәк хастаханәсе гомуми рейтингта беренче өчлектән төшкәне юк. Социаль яклау учреждениеләрендә барлык төр хезмәтләр күрсәтелә. Хезмәт күрсәтү оешмаларында сәламәтлекләре чикләнгән гражданнарга яраклаштырылган шартлар тудыру юнәлешендә дә эш алып барабыз. Яшьләргә патриотик тәрбия бирү, физик һәм рухи сәламәт балалар тәрбияләү – төп бурычыбыз. Спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар, аның нәтиҗәләре дә бар. Милли көрәш, республика авыл яшьләре уеннары буенча, район узган ел беренче урынга чыкты. Дин, әхлак тәрбиясенә дә зур игътибар бирәбез: 72 мәчет, 1 мәдрәсә эшли.

Үзебезнең күренекле шәхесләребез, каһарманнарыбыз белән горурланабыз. Кукмара – илгә 6 Советлар Союзы Герое биргән төбәк. Дөньякүләм танылган Чыңгыз Айтматовның әнисе ягыннан тамырлары Кукмарага килеп тоташа. 28 райондашыбыз Кукмара муниципаль районының мактаулы гражданнары исемен йөртә, 77 кеше исә, «Кукмара муниципаль районы алдындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләнде. Алар арасында мәгариф идарәсе җитәкчесе Роберт Мияссарович Мансуров, мәктәп директорлары һәм укытучылар да бар.

Районыбыз халкына хәзерге заман таләпләре кысаларында телебезне, гореф-гадәтләрне, милли йолаларыбызны саклау һәм үстерүгә багышланган хезмәтегездә уңышлар, исәнлек, иминлек телим! ■

ҮЗ ЗАМАНЫН УЗЫП ЯШӘДЕ УЛ...

Газинур Морат

Безләргә адәм баласының хак-бәясен фәкать Вакыт бизмәненә салып кына үлчәп карау мөмкинлеге бирелгән. Бу бизмән һичкайчан ялгышмый да, хәрәмләшми дә. Халкыбызның «Кеше китә – җыры кала» дигән канатлы гыйбарәсе дә, асылда, Вакыт сынавын узып яши алган игелекле затларга карата әйтелә булыр. Бабаларыбыз инсаннарның фанилыкта кылып калдырган күркәм гамәлләрен дә җырга тиңләгән. Җыр исә – тормыш-яшәешне иплe, көйле итеп алып барыр өчен күктән иңдерелгән аһәң-гармониянең үзедер инде ул. Халыкның озын-озак гасырлар дәвамында канунлашып килгән әдәп-әхлак кагыйдәләре нәкъ менә шушы аһәң-гармонияне бозмыйча, имгәтмичә, табигый хәлендә саклап яшәтер өчен көйләнгән дә. Һәм әлеге кагыйдәләрнең нигезенә, субай итеп, «төзү-кору» дигән фәлсәфә ташы салып калдырылган.

...Белмим, Камил абый үз гомерендә бу ташны, учына алып, яшәү мәгънәсе турында фәлсәфәләргә бирелеп утыргандырмы, юктырмы, әмма ул бар булмышы белән мотлак төзүче иде. Төзүченең дә нindие әле – халыкның ихлас ихтирамын казанып, дәүләт тарафыннан да югары дәрәҗәдә бәяләнеп, легендар шәхескә әверелгәне!

Чыннан да, заманында Камил Шакировның исеме татарча сабак алган һәр мәктәп баласына да таныш иде. Башлангыч сыйныфлар өчен тәгаенләнгән «Туган тел» китабыннан «Камил батыр» дигән парчаны берничә буын укып үсте. Балалар өчен үрнәк булырдай шәхесләрне дәреслек кадәр дәреслеккә ул чакта да бик сайлап кына керткәннәрдер, билгеле. Ә Камил Фаяз улының тәрҗемәи хәле дә, кылган эш-гамәлләре дә илкөн күзенә горурланып күрсәтерлек иде шул. 35 яшендә «Социалистик Хезмәт Каһарманы» дигән иң югары шәрәфле исемгә лаек булган күмәк хуҗалык рәисе, СССР Югары Советы депутаты; өстәвенә, утлар-сулар кичкән полк улы да...

Ул районның иң артта сөйрәлеп йөргән Иосиф Сталин исемендәге хуҗалыгын 28 яшьләрендә кабул итеп ала һәм 5-6 ел эчендә аны «Коммунизмга» дип аталган миллионер колхозлар рәтенә чыгаруга ирешә. Авыллар күзгә күренеп тернәкләнә башлый, халык, күмәк хуҗалыкта гына түгел, үз хуҗалыгында да ныклап төзү-сипләү эшләренә керешә...

Хәтердә әле: 1968 елның җәендә, урак өстендә, безнең Зур Сәрдек авылына Чехословакиядән бер төркем студентлар килеп төште. Алар ындыр табагында авыл апалары белән иңгә-иң торып эшләп тә йөрде. Барысы да джинсы чалбар кигән, эре сөякле, мөлаем егетләр-кызлар иде. (Без бала-чаганың иң кызыкканы да шул зәңгәр киндер ыштан иде инде ул вакытта. Минем үземә аны бик соңынтын гына кияргә туры килде һәм ул да турыдан-туры Камил абый белән бәйле булып чыкты.) Ләкин көяз Аурупаның үзеннән үк килгән кунаклар бездә озак юана алмады, биштәрләрен тиз-тиз генә җыйнаштырып, китеп тә барды. Соңыннан аңлашылганча, аларның үз хәле хәл

К.Шакиров җыелыш вакытында

булган икән шул, – Прага урамнарына совет танклары бәреп кергән дә халыкка каршы ата башлаган икән. Юкса, чехлар гаскәр белән үк бастырырлык әллә ни зур «гөнаһ» та кылмаган үзе, фәкать «адәм чырайлы социализм» төзергә генә ниятләгән...

Хәзер инде чит ил ватандашларының авыл-салаларыбызга килеп чыгуы беркемне дә гаҗәпләндерми. Бер яктан, Җир шарын кыл урталай бүлеп торган «тимер пәрдә» юкка чыкса, икенче яктан, авылларыбыз үзләре дә цивиль дөнья күзенә күрсәтердәй хәлгә килде. Бу очракта, төзеклек җәһәтеннән, дип тә өстәргә кирәктер инде. Чыннан да, халкыбыз төзү-сипләү эшенә шулкадәр остарып җитте ки, хәтта еш кына аның, тормыш мәшәкатьләре белән мавыгып, күккә күтәрелеп карарга да вакыты калмыйдыр кебек тоела башлый...

Кыскасы, Камил Шакиров җитәкчелек иткән күмәк хуҗалык авыллары инде 60 нчы еллар ахырында ук чит ил кешеләрен совет хакимиятләренең дә йөзе кызармаслык дәрәҗәдә кабул итәргә әзер булган. Һәрхәлдә, ул чакта чех студентларын Камил абый һич кенә дә үз белдеге белән чакырып китермәгәндер, аларны кая юллау мәсьәләсе обком кебек югары даирәләрдә хәл кылынгандыр, дип уйларга кирәк.

Ул елларда безнең авылда могҗизага тиң хәлләр тагын булды әле. Әйтик, язгы көннәрнең берендә Озак тау башына пар канатлы «кукурузник» төшеп кунаклады. Хуҗалык басуларына ашлама сиптерергә килгәннәр икән. Безгә, очкычларны кинодан гына күреп үскән авыл малайларына, шулай итеп, «тимер кош»ны үз кулы белән тотып-капшап карарга да җай чыкты. Бу мәлләрдә күпләребезнең күңеле дә канат җилпегәндер, үскәч, очучы буласы килү теләге дә борынлап алгандыр, бәлки. Әнә, Гарәфетдин Вәлиев атлы бер сабакташыбыз, еллар узгач, чыннан да, очучылыкка укып, башта «АН-2» очкычында күкне иңләде, тора-бара иң заманча һава лайнерларында дөнья гизде.

Хәер, адәм баласы үзе дә җәяүле кошлар затыннан санала ич. Кошлар катына алгысынган күңел барыбер дә күккә берегеп кала бугай ул...

Без, 3-4 нче сыйныфларда укып йөргән малай-шалай җирдә «тере» очкыч күреп кинәнү бәхетенә ирешсәк, язгы кыр эшләрендә булышу өчен самолёт кадәр самолёт яллап китерердәй хәлле хуҗалыклар «нык үскән социализм» заманнары башланганчы да, башлангач та берән-сәрән генә булгандыр.

1967 елда безнең авылда янә бер могҗиза калыкты – 7 ноябрь көнне 450 тамаша-

чы сыйдырышлы мәһабәт мәдәният йорты ачылды. Моңарчы элекке мәчет бинасын клуб итеп файдаланган халык, ниһаять, җиңел сулап куйды. Дөресен әйткәндә, андый архитектура корылмасын минем әле дә күргәнем юк. Ник дигәндә, ул бер генә рәсми оешмада да расланмаган, кабул ителмәгән сызым буенча төзелгән. Архитекторы да үзебезнең авылныкы – Кукмара төбәгенең мәшһүр затларыннан берсе, алтын куллы балта остасы Гаян абый Әхмәтшин. Утлар-сулар кичкән, һәм немец, һәм совет концлагерьлары мәхшәрен үз башыннан кичергән, гомере буе мәктәп балаларын чүкеч-балта тотарга өйрәткән, ил-көнгә игелек кылудан тәм табып яшәгән ил агасы иде ул. Камил абыйның башбирмәс тәвәккәллеге, зур абруе, Гаян абыйның югары сәнгати осталыгы һәм авыл осталарының уртак тырышлыгы нәтиҗәсендә бездә әнә шундый уникаль мәдәният-сәнгать мәркәзе үсеп чыкты. Менә ярты гасырдан артык инде ул халыкка хезмәт итә. Аның сәхнәсендә татарның иң күренекле артистлары, театр труппалары чыгыш ясады, үзешчән сәнгать түгәрәкләре гөрләп эшли башлады; фойеда исә бала-чага, яшь-җилкенчәк бильярд, шахмат-шашка, өстәл теннисы уйнарга, гер, штанга күтәрергә өйрәнде. Тимер-томыр күтәрергә өйрәтүчесе дә кем диген – гер спорты буенча күп мәртәбәләр РСФСР һәм Татарстан чемпионы булган авылдашыбыз Фаил Гобәйдуллин үзе иде.

Ул чакта мәдәният йортында безне авыл өчен бөтенләй дә ят саналган тагын бер һөнәргә – музыкант һөнәренә дә өйрәтә башладылар әле. Дөресрәге, биредә беркадәр музыкаль ишетү сәләте булган 30-35 мәктәп баласыннан тынлы оркестр оештырылды да без, тиз арада нота әлифбасын өйрәнеп, үз партиябезне оркестрга кушылып башкара алырлык дәрәҗәдә өлгерергә тиеш идек. Шөкер, сынатмадык шикелле. Остазыбыз, танылган музыкант һәм композитор Мәсгут Латыйпов, бар түземлеген җыеп, безне азмы-күпме нота таныырга да, саксофон, бас, тромбон, альт, валторна, кларнет, корнет, флейта кебек шактый ук четерекле уен коралларында көй чыгарырга да өйрәтте.

Бер уйласаң, колхоз рәисе, әгәр бик теләсә, әлеге кыйммәтле инструментларны сатып алмас өчен мең төрле сәбәп тә таба алыр иде, билгеле. Авыл җирендә чыгымнар болай да хәттин ашкан ич. Икътисади мәнфәгатьләрне генә кайгыртып, рухият өлкәсен бөтенләй дә санга сукмыйча яшәргә күнеккән җитәкчеләр, гадәттә, нәкъ шул рәвешле эш йөртә дә. Һәм алар, кагыйдә буларак, илдә-көндә зур күпчелекне тәшкил итә. Бу урында, әйдәгез, классик язучыбыз Мирсәй Әмирне тыңлап карыйк. Партия съездында ул Камил Шакиров белән якыннан танышкан һәм үз күзәтүләрен 1971 елда дөнья күргән «Үзебез турында» дигән китабында теркәп калдырган. *«Безнең арада... атаклы иген үстерүчеләр, терлекчелек батырлары да бар,* – дип яза әдип. – *Әнә Кукмара районының «Коммунизмга» колхозы председателе Камил Шакиров. Әле күптән түгел бик нык артта калып килгән колхоз, аның оста җитәкчелеге нәтиҗәсендә, республика күләмендә иң алдынгылар сафына чыкты. Ниндирәк соң ул хәзерге көндәге алдынгы колхоз председателе? Мин үзем авылда туып үскән кеше, авыл кешеләрен элек-электән якын күрәм, аларны аеруча үз итәм, алар белән бик тиз уртак тел табам. Әле кайчан гына мондый хәл иде: колхоз җитәкчеләрен мин бик яхшы аңлыйм һәм алар да мине шулай ук яхшы аңласыннар өчен, әдәбият турында, сәнгать турында сөйләгәндә телемне юри гадиләштеребрәк сөйләшергә тырыша идем. Шакиров белән сөйләшкәндә моның кирәге юк. Әдәбият турында да, сәнгать турында да, политика турында да язучы телен, гомумән, теләсә кайсы өлкәдәге интеллигент телен ул бик яхшы аңлый. Ә менә миңа аның, колхоз председателенең телен аңлау хәзер бераз читенләшә төшкән икән. Авыл кешесенең эше турында, бүгенге колхоз производствосы турында ул фән теле, экономист теле, агроном теле белән сөйли... Һәм мин аңардан кайбер сүзләрен шәрехләп бирүен сорарга мәҗбүр булам...»*

1966 елда аксакал язучыбызның 35 яшьлек колхоз рәисе Камил Шакировка биргән бәяләмәсе бу. Әйе, әдип дөрес искәртә: халыкның тормыш-көнкүрешен бөтен, бәрәкәтле итү өчен һәрдаим җан атып яшәүче уйлы-гамьле җитәкче икътисадтан да, мәдәният-сәнгатьтән дә, мәгърифәт-мәгариф эшләреннән дә яхшы хәбәрдар булырга һәм аларны бердәй кайгыртырга бурычлы. Матди алгарышны фәкать югары эчке культурага ия кешеләр генә тәэмин итә алуына цивиль дөнья әллә кайчан төшенгән инде. Бу кадәресен Камил абый да шактый ук яхшы чамалаган булса кирәк. Моны аның эш-гамәлләре үк бик ачык күрсәтеп тора иде.

1973 елда Зур Сәрдектә 640 укучыга исәпләнгән өч катлы мәктәп ачылды. Төзелеш эшләре исә тулаем «Коммунизмга» хуҗалыгы хисабына алып барылды. Ул чакта әле андый мәһабәт мәктәп биналары күп кенә район үзәкләрендә дә юк иде шикелле. Әлеге гыйлем-тәрбия мәркәзе дә менә 45 ел инде үзенең мөкатдәс вазыйфасын югары кимәлдә башкарып килә. Иң мөһиме – ул гомер-гомергә саф татар мәктәбе булып яшәде, барлык фәннәрдән дә татарча белем бирде. Шөкер, бүген дә, БДИ дигәннәреннән бүки ясамыйча гына, гимназия үз асылына тугры калырга тырыша. Аңа карап, БДИ күрсәткечләре һич кенә дә ким-хур булырлык түгел. Гәрчә, ул күрсәткечләр артында милли дискриминация кәсәфәте тач ярылып ятса да. Югыйсә, мәктәптә татар телен 10 ел буена ипи-тозлык та өйрәнә алмаган балалар аркасында бериш ата-аналар әнә нинди буза куптарды ич, – ярты дөньяны шовинизм сөреме белән агулап бетерде...

Берничә ел инде Зур Сәрдек гимназиясе хаклы рәвештә Камил Шакиров исемен йөртә. Җирле җитәкчеләр бик тә мәгънәле карар кабул иткән: яшь буыннар да Камил абыйның якты рухын һәрвакыт яд итеп яшәргә бурычлы, чөнки ул халыкка игелекле хезмәт итүнең иң күркәм үрнәген күрсәтеп калдырды.

...1979 елны Камил абый, безгә мәгълүм булмаган ниндидер сәбәпләр аркасында, һич көтмәгәндә рәислектән китеп барды. Шулай да халык арасында, колхозчыларга тиешледән артык печән өләшкәне өчен эшеннән алганнар икән, дигән сүзләр йөрде йөрүен. Минем әлеге фараз-юрауга бик тә ышанасым килә, чөнки Камил абый үзе дә бар табигате, бар вөҗүде белән нәкъ шундый инсан иде.

Шулай итеп, колхозны 20 ел буена ат урынына җигелеп тарткан рәисебез кинәт эшсез торып калды. Ләкин ул, 48 яшьтә генә булуына карамастан, җылы кәнәфиләр, җылы кабинетлар эзләп, бәрелеп-сугылып йөрмәде, авыл яшьләреннән, безнең ише, җәйге каникулга кайткан «кефир малайлары»ннан ташчылар бригадасы оештырды да Шәмәрдән бистәсенә ияртеп алып китте. Без килешкә анда инде барысы да алдан хәл итеп куелган иде: эш фронты да, торак урыны да, туклану мәсьәләсе дә... Безгә исә кинәнә-кинәнә эшләргә генә калды. Камил абый үзе дә кимен куймады: әгәр ул кирпеч өяргә тотынса, измә китереп тору өчен аның берүзенә 3-4 ярдәмче кирәк булыр, алары да көч-хәл белән генә ташып өлгертер иде. Ни әйтсәң дә, оста барыбер оста шул инде! Байтак кына еллар кулына мастерок тотып эшләргә туры килмәсә дә, «бугор»ыбызның югары дәрәҗәдәге осталыгы һәр хәрәкәтеннән күренеп тора иде.

Әйтергә кирәк, бу шабашканың әҗере дә шактый мулдан булды. Ул акча миңа ел буе иркенләп гыйлем ташын кимереп йөрергә дә, 150 сум (!) түләп, теге зәңгәр киндер ыштанны алып киярге дә җитеп ашты.

Төзелеш эшләре тәмамлангач, тик торуны белмәс, тынгысыз җанлы Камил абый берара мәктәптә тарих фәненнән дә укытып алды әле. Аның дәресләре дә, һичшиксез, кызыклы-мавыктыргыч, гыйбрәтле булгандыр, дип уйлыйм мин, чөнки ул, асылда, үзе дә тарихи каһарманга әверелгән олпат шәхес иде. ■

ДАНЛЫ ТӨБӘК – КУКМАРА

Мәшһүр әдип Чыңгыз Айтматовның тууына 90 ел тулу уңаеннан Кукмара шәһәрендә Туган якны өйрәнү музее директоры ***Ләбүдә Дәүләтшина,*** *Олыяз мәктәбе каршындагы туган якны өйрәнү музее җитәкчесе* ***Зөлхәбирә Якупова****, хезмәт ветераны* ***Рафаэль Ярмиев****, Киров өлкәсендәге Нократ Аланы районының Иске Пенәгәр авылы имам-хатыйбы* ***Зыятдин хәзрәт Нәҗметдинов****, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире* ***Ләбиб Лерон*** *һәм хезмәткәре* ***Ленар Гобәйдуллин****, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире* ***Рөстәм Галиуллин*** *һәм төбәкне өйрәнүчеләр катнашында «түгәрәк өстәл» оештырдык. Биредә төбәкне өйрәнү эше шактый алга киткән: соңгы елларда гына да Кукмара, Купка, Олыяз, Кәчимер, Аш-Буҗи, Байлангар, Өскебаш, Лубян, Манзараз авыллары тарихы, кабер ташлары, итек фабрикасы, бакыр заводы турында саллы гына китаплар чыгарга өлгергән. «Түгәрәк өстәл»дә яңгыраган кайбер фикерләрне сезнең игътибарга да тәкъдим итәбез.*

Ләбүдә Дәүләтшина:
«Кан туганым булмасаң да, бу җирдә иң якын кардәшем...»

– Музей оешкан вакытта Казан шәһәрендә узган бер җыелышта, Кукмара төбәгендә зур казу эшләре мәңге оешмас инде, бездә Арчадагы кебек зур шәхесләр дә юк, дип, башкалардан ак көнләшү хисләре кичереп утырам. Әлхәмдүлилләһ, барысы да булды. Баксаң, үзебезнең шәхесләребез дә шактый икән. Язучыларыбыз да, шагыйрьләребез дә башка төбәктән ким түгел... Фәкать әлегә кадәр аларны күтәрүче, танытучы кеше генә булмаган. Төбәкне өйрәнү эшенә бер тотынсаң, ул үзенә суырып ала. Бу эшне аңлаучылар гына сирәк.

Сәүдә тармагында эшләгән вакытта Мәчкәрәгә йомырка, йон җыярга җибәрәләр иде. Минем андагы борынгы биналарны күреп исем китте. Халык: «Байларныкы!» – дип әйтү белән генә чикләнде. Музейга килеп эшли башлагач, 327 экспонат бар иде. Башта безне кабул итүче, эшне аңлаучы да булмады. Шуннан Мәчкәрә мәктәбе музее җитәкчесе Радик Дәүләтшин янына кердек. Музей белән танышканнан соң, мин аңа: «Бер дә кеше күрмәгән әйбереңне күрсәт», – дип үтендем. Берзаман ул ватман кәгазе алып чыкты да: «Бу – Ишмән шәҗәрәсе!» – диде. Гарәп гриафикасында язылган, кызганыч, укый белмибез... Шулай итеп, аның күчерелмәсен ясатып калдык, ә төп нөсхәсе, тиешле саклау булмау сәбәпле, вакыт узу белән юкка да чыккан. 432 кеше исеме түгәрәккә алынган. Кемнәр икәнен бик тә беләсе килә...

1997 елда кабер ташларын өйрәнүне дә үзебезнең эш планына керттек. Әмма гарәби язуны танымавыбыз аркасында, эш әллә ни алга китмәде. Шөкер, арабызда Зыятдин хәзрәт Мөхәррәм улы булып, ул безгә ярдәм итте. Аннары галимнәр, якташыбыз Ирек Һадиев һәм Раиф Мәрданов әлеге ташларны укып, аерым җыентык итеп бастырып та чыгарды. Шул ук галимнәр 2001 елның май аенда Җәлил хәзрәт белән Балтачтагы Бөрбаш авылы зиратына барып, андагы кабер ташының Ишмән бабайга бәйле икәнен ачыклады. Ул – Мәчкәрәнең данлыклы Үтәмешевләр нәселенең борынгы бабасы Ишмәннең атасына – Көчек улы Туктаргалигә 1675 елда куелган кабер ташы. Галимнәр

язуынча, бу ташъязма да хаттат Килмөхәммәд Ишмән улы тарафыннан уелган.

Ходайның рәхмәте илә, Сәрдек авылында Бөре елгасы буе авыллары конференциясе узды. Шушы шәҗәрә белән үзебез дә анда экспозиция ясадык, Җәлил хәзрәт Фазлыев та катнашты. Ул исә Бөрбаш авылы зиратындагы борынгы кабергә җирләнгән шәхеснең һәм шәҗәрәнең үзе нәселенә бәйле икәнен әйтте. Аңа шәҗәрәнең күчерелмәсен бүләк иттек.

Берзаман район мәдәният йортында читтән килгән берничә кеше Чыңгыз Айтматовка бәйле почмакны эзләп йөри. Кеше шуның кадәр зур шәҗәрәгә кергән икән, димәк, ул – затлы, тарихта тирән эз калдырырлык гамәлләр кылып калдырган шәхес. Кунаклар Әскәр Айтматовның яшьлек дусты булып чыкты. Ул Чаллыга эшкә кайткан икән, ә шәҗәрә турында Җәлил хәзрәтнең телевидениедәге чыгышыннан ишетеп белгән. Ул: «Мин сезне Чыңгыз Айтматов белән очраштырам», – диде һәм сүзендә торды да. «Мираж» кунакханәсендә мин бөек әдипнең каршына шәҗәрәне җәеп салдым. Ул, шаккатып, өнсез калды һәм: «Монда синең тармагың кайда?» – дип сорады. Моңарга: «Мин Сезнең агачның җимеше түгел», – дим. Ул исә үзенең Хәмзә бабасы белән кызыксынды һәм: «Син миңа кан туганым булмасаң да, бу җирдә иң якын кардәшем!» – дигән юлларны язып, автографлы китабын бүләк итте. Мәчкәрә авылы белән бәйле Ишмән

шәҗәрәсен дөньяга танытуга шактый көчемне куйдым. Хәзер мине, киресенчә, Чыңгыз Айтматов исеме йөртә. Күптән түгел Истанбул шәһәрендә үткәрелгән «Мәдәниятләр диалогы – Чыңгыз Айтматовның мирасы» дигән «түгәрәк өстәл» утырышында катнашу да насыйп булды. Без шушы нәселдән, дип элемтәгә керүчеләр әле дә бар. Мәскәү, Петропавловск шәһәрләреннән шалтыратулар булды.

Мәчкәрәдә шактый кеше репрессиягә дучар ителгән. Өчәр яшьлек балалар да эти-әниләре белән кулга алына. Төптән эзләсәң, анда шәхесләр саны бик күп. Соңрак Үтәмешевләрнең бар икәнен белдек. Шунда ук Хәмзә бай кибете, аның артында «Сандугач» чишмәсе дә бар. Чыңгыз Айтматовның бабасы су эчеп яшәгән бу чишмәне, махсус грант алып, заманча төзекләндердек. Казан мэры Илсур Метшин ярдәме белән, Мәчкәрәдәге 35 борынгы кабер ташы янына аңлатма такталар куелды, зиратның киртәсе тотылды, мәчет төзекләнеп килә.

Хәзер Мәчкәрә авылын туристлык маршрут планына кертү хыялы бар. Шөкер, районыбызда этномәдәни тирәлек бай: удмурт, татар, керәшен, мари, урыс бергә дустанә яши. Бу халыклар яшәгән һәр авылда мәдәният һәм педагогик хезмәт коллективлары уңышлы гына эшләп килә. Аграр колледж базасында – авыл хуҗалыгы, ә Лубян урман хуҗалыгы техникумы нигезендә экология юнәлешендә туристлык маршруты, аерым лагерьлар оештырырга мөмкин.

Зыятдин хәзрәт Нәҗметдинов:
«Метрикалар – халкыбызның зур мирасы»

– 30-35 ел элек менә шушы бүлмәдә (без – Туган якны өйрәнү музеенда. – *Ред.*) Кукмараның китап кибете иде. Шул елларда биредән бик кызыксынып гарәп-рус сүзлеген дә сатып алганым хәтердә. Ул вакытта ук гарәби язулы мирас белән кызыксына башлаган идем. Ничә еллар узса да бу бүлмәнең хикмәте шул ук: ул вакыттагы кебек, хәзер дә кешеләргә аң-белем тарата.

Мин соңгы бер-ике елда Кукмара метрикалары белән шөгыльләндем. 1830 еллардан ук инде авылыбыз имамнары туган кешеләрне, бакый дөньяга күчкәннәрне, никах һәм аерылышуларны язып барган. Бер авылның гына метрикасын өйрәнү әллә ни нәтиҗә бирми, әмма берничәне бергәләшеп өйрәнгәндә, мәгълүматны анализлап карасаң, исең китәрлек. Югары Казакларның бер метрикасы Купка авылына килеп кергән. «Ни өчен килеп кергән соң?» – дисезме?! Чөнки имам Югары Казакларның бөтен язу эшләрен дә алып барган һәм метриканы Купка белән берләштергән. Купка имамы кайсы да булса чит авылга барып никах укыса, аны үзенең мәхәллә метрикасына теркәп куйган.

Метрикалар яшьли үлемнәрнең күплеге турында сөйли. XIX гасыр-XX йөз башында сабыйларның үлеме еш теркәлгән. Иске Пенәгәр авылы мисалында гына да 38 ел эчендә ун яшькә кадәрге 592 бала үлеме туры килгәнен күрәбез. Кеше 50 яшьтән артып вафат булган икән, сәбәбе – картлыктан, дип язылган. Мәрхүмнәр турындагы графада вафат булган хатын-кызның этисе кайсы авылдан икәнен теркәп куярга мөмкиннәр. Шуннан аның теге яки бу авылдан килен булып төшкәне беленә. 1848 елда исә халыкны ваба чире – холера кырган. 1892 елда ачлыктан һәлак булучылар бик күп теркәлгән. Авырулар арасында иң күбе – ютәл чире, тамакка салкын тидерү хастасы.

25-30 яшьләрдә тол калучылар күп булган. Бер хатын, 25 яшендә тол калып, иренең энесенә кияүгә чыга. Ике елдан ул хатынның өченче никахы... Бу бит хәзерге күзлектән чыгып караганда, шактый зур фаҗига. «Баладан үлде», дигән сәбәп ел саен очрап тора. Әгәр дә авылда бер елда ике-өч шундый үлем теркәлгән икән, бу – хәзерге заманнан



Ишмән шәҗәрәсе

караганда шактый зур сан. Ә ятим балалар кемдә тәрбияләнә? Икенче тапкыр кияүгә чыкса, хатын балаларын бик сирәк очракта гына үзе белән алган. Бала әбидә яки берәр туганында тәрбияләнгән. Никахның мәһәре турындагы бүлектә, кайчак мәһәр буларак, ир-ат хатын белән бергә киләчәк балаларны тәрбия кылам, дип вәгъдә бирә. Дөрес, бу – бик сирәк очрак. Никах язмаларында һәр гаилә тормышы бөтен нечкәлекләре белән күз алдына килә.

Гадәттә, вәли вәкил булып этиләр утырырга тиеш. Никах вакытында ике яктан этиләр утыра икән, кыз белән кияүнең булуы мәҗбүри шарт түгел. Кызганыч, метрикаларда вәли вәкил булып эти утырганы аз очракта гына теркәлгән. Яртысында – агасы яки энесе. Бу инде гаиләдә егет яки кызның этисез үсүе турында сөйли. Мәһәрнең бәясе тәңкә, көмеш яки бакыр белән билгеләнә. Шуннан 25-50 тиен хөкүмәткә салым буларак түләнгән. Көмеш, бакыр, тәңкә бер-берсе белән нинди чагыштырмада йөрделәр икән? Бер язмада – 25 сум көмеш, икенчесендә – йөз тәңкә, өченчесендә – 25 сум бакыр. «Мәһәргә – акыл» нәрсә? Бу да шактый авылларда очрый. Белемле муллалардан да сорап карадым, алар да берни белми... Бер кешенең икенче яки өченче никахы булса, этиләр утырмый, ир-ат яки хатын-кыз үзенә-үзе «вәли вәкил» вазыйфасын ала.

Метрикаларда хатын-кызларның үзләренә генә хас тамгалары бар авылда да бертөсле. Бер төрле булуның хикмәте нидә? Ирләрнең исә төрле-төрле нәсел тамгалары булган. Ә бу тамгалар – шактый борынгы һәм гаять кызыклы тарихи чыганак.

Социаль катламнар да кызыклы. Мәчкәрдә «тархан» да, «купец» та, «мещан»нар да бар. Башка авылларда «зирагатьче»ләр генә, ә боларда – төрле. Җитмәсә, мулла бер кешенең тархан икәнен күрсәтеп, аның дәрәҗәсен бер язмада берничә мәртәбә искә алган. «Сукыр», «аппар», «тупай», «күрше», «тегүче» дигән кушамат һәм атамалар да бар. Мулла күршесенең кем булганын без хәзер берничек тә белә алмыйбыз... Бала-ата исемендә охшату киң таралган: Биккенә – Биктә, Бикташ – Бикбау, Мортаза – Мостафа. Вафат булган баланың исемен туганына кушу очрагы да еш күренеш. Авыллар арасындагы исемнәрнең дә аермасы бик сизелә.

Соңгы вакытта авыллардан халыкның күчешенә дә игътибар итә башладым. Олы Казаклар авылыннан 8 кеше Оренбургтагы Каргалы авылына күчеп китә. Авылда бертөрле исемнәр күп икән, мулла йә кушамат куйган яисә, күп очракта, кешенең

дүрт буынга кадәр ата-бабаларын санап чыккан. Шулай итеп, метрикалар нигезендә һәрберебезгә дә 10-12 буынны өйрәнү мөмкинлеге бар, әмма моның өчен зур тырышлык һәм көч сорала. Безгә метрикаларны бергәләшеп өйрәнергә кирәк. Бу – авылның, гомумән, халкыбызның зур мирасы. Хәзергә барлык метрикаларның күчерелмәсен үзебездә булдырып, төбәктәге нәсел-шәҗәрәләрен өйрәнү белән шөгыльләнәбез.

Зөлхәбирә Якупова:
«Яшьтән музейга йөргән кешенең эче буш булмый»

– 1997 елда Олыяз авылы мәктәбендә төбәкне өйрәнү музеен оештырып җибәрдек. Беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев бер чыгышында: «Әгәр дә без тарихны үзебез язмасак, ул чын тарих булмый», – дип сөйләде. Мин шуннан эшкә тотындым да инде. Мәктәп музейларының бернинди акчасы да, штаты да юк, шулай да, шәхси башлангычыбыз белән йорттан-йортка кереп, хәтта кайберләүләргә берничә мәртәбә барып, «Хәтер китаплары» булдырдык. Ятимнәр, тол хатыннар, шәфкать туташларының, кибетчеләрнең, башка һөнәр ияләренең һәрберсенә махсус альбом булдырдык. Яшьтән үк музейга йөргән кешенең эче буш булмый. Ул чын мәгънәсендә туган ягы шәхесләре үрнәгендә тәрбияләнә. Аннан яхшы ана, игелекле ата, гыйлемле укытучы яки табиб чыга. Балаларның күңелендә хәтер очкынын кабызырга кирәк.

Тарихчы-журналист М.В.Черепанов, музеебызга килгәч: «Мондый Хәтер китаплары беркайда да юк, фәкать сездә генә бар!» – диде. Бу эшләрне һәр авылда да эшләргә була. Дөрес, хәтер түрендә уелып калырдай шәхесләребезнең саны елдан-ел кими бара. Олыяз авылыннан гына да 167 кеше сугышта һәлак булган. Алардан калган 78 тол хатынның хәзер инде берсе дә исән түгел. 210 ятим баланың 32се генә исән. Музейда 17 яшьлек егетләрнең фотолары тора, кызганыч, күбесенең сөякләре дә кайда ятканы билгесез. Алар авылны чыкканда тау башына менгәч: «Безгә бу зиратларда урын булмас инде...» – дип әйткәннәр. Әмма шушы кешеләр туган-үскән, яшәгән гаиләләр бар. Аларга керсәк, нинди дә булса мәгълүмат алырга була, фоторәсемнәре дә табыла. Кичәге хәл – бүгенге тарих. Хәзер Югары Казаклар авылы тарихын туплау белән шөгыльләнәм. 1941 ел башында бу авылда 72 хуҗалык булган, хәзер исә нибары – 39. Менә шундагы һәр йортның барчасында да булып чыгарга исәп.

Рафаэль Ярмиев:
«Әлегә халык авыл тарихларын әдәби китап кына итеп кабул итә»

– Байлангар төбәге – тарих төпкеленә кереп калган иң борынгы авылларның берсе. Кукмара районында Казан ханлыгы чорында нигез салынган 7-8 авыл бар. Байлангарга 1530-1540 елларда Байтәвәккәл дигән кеше нигез салган. Бу авыл борынгы чорда «Байугъланнар харъясе» дип аталган, чөнки авылда «олуг байларыннан» булган Байтәвәккәлнең уллары яши башлый. Кайбер чыганакларда авыл «деревня Бай Оланнар» дип тә искә алына. Рәсми документларда исә Байлангар авылы 1678 елда теркәлә. Байтәвәккәл исемле зат Яхиннар нәселе шәҗәрәсенең башында тора. Яхъя хәзрәт 1760-1859 елларда яшәгән. Аннан туган тугыз бала, ягъни Яхиннар нәселе Казан арты районнарында мәшһүр шәхесләрне биргән. Мәрьям Рахманкулова, Рөстәм Яхин, Мөхәммәт Мәһдиевләр – шул нәселдән. 1848 елда Мөхәммәдтаип Гыйльман улы Яхин туган. Мәрҗани үз эшен

Кукмара төбәген өйрәнүчеләр

Мөхәммәдтаипка тапшырып калдыра. Атаклы язучы, 1970-1981 елларда ТАССР прокуратурасында хезмәт куйган Мәгъсум Насыйбуллин да – шул нәселдән. Таипнең дүрт баласы – Хәбибулла, Насыйбулла, Нәҗибулла, ә аның улы – Мәгъсүм. Мәгъсүмнең энесе Мәксүт 1960 нчы елларда Төньяк Флотта Юрий Гагарин белән хезмәт иткән. Сабаны данлаган шәхес Тәлгать Нәҗмиев тә – Байлангардан. Безнең авылдан чыккан менә бу шәхесләрнең хезмәтләре әлегә кадәр тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән.

Кызганыч, җәмгыятебездә тарихи кыйммәтләргә ихтыяҗ аз. Безгә менә шушы тарихи мирасыбызга ихтыяҗ тудыру өстендә эшләргә кирәк. Музейлар һәм төбәк тарихына бәйле китаплар авылның эшкуарларын, авыл җанлы кешеләрне тәрбияләргә, аларны берләштерергә тиеш. Әлегә халык авыл тарихларын әдәби китап кына итеп кабул итә. Укый да ул аны читкә куя. Ә авыл тарихлары өстәл китабы булырга тиеш. Анда күпме кеше турында язылган, хатирәләр барланган. Бернәрсәне дә, бер генә кешенең дә исемен ялгыш язарга ярамый. Бу – зур җаваплылык. Кешеләрнең күңел төпкелендәге һәр хәтер-хатирә чыганак булып хезмәт итәргә тиеш. Ә китапның авторы яки төзүчесе өстеннән берникадәр җаваплылык төшсен өчен, китерелгән чыганак астына информантның исемен дә кую шарт.

Байлангар авылы тарихын язуны, әдип буларак, Тәлгать абый Нәҗмиевкә йөкләргә теләгән идек. Әмма ул: «Авыл тарихын шунда яшәгән кеше язарга тиеш, аны язу сезгә кала инде», – дип әйтте. Шулай да безгә китап нигезенә ятарлык бик күп материал биреп калдырды ул. Байлангар тарихын язар өчен, авыл советы белән киңәшеп, 15-16 кешелек төркем тупладык. Шулар белән эшләп, авыл архивы, ветераннарны җәлеп итеп, ике елда Байлангар авылы тарихы турындагы китапны бастырып чыгардык. Әлеге китапта, Байлангар белән бергә, Сазтамак, Нормабаш, Каенсар авылларының барлыкка килүе, халкының төрле чорлардагы көнкүреш-яшәеше, гореф-гадәтләре, шөгыле, һөнәрләре турында бай мәгълүмат бирелә. Авыл кешеләренең буыннан-буынга күчеп, сакланып килгән рухи һәм матди мирасы тасвирлана. Олпат шәхесләрнең гыйбрәтле язмышлары, башкарган хезмәтләре, аларның дәвамчыларының бүгенге көндәге тормышлары турында сөйләнә. Хәзер шушы китапта бәян ителгән материалларны архив чыганаклары белән ныгытып, тирәнәйтеп эшләү турында сүз алып барабыз. ■

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН ҮРНӘКЛӘР

ЧУАШНЫҢ МӘШҺҮР УЛЫ

Сәхифәне Ләбиб Лерон алып бара

Чуаш шагыйре, прозаик, тәрҗемәче, 1974 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы **Михаил Сениэль (Михаил Павлович Егоров)** 1940 елның 30 декабрендә Татарстанның Аксубай районындагы Урмандеево авылында дөньяга килә.

1959 елда Чистайда медицина училищесын, аннары 1967 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын, 1989 елда исә А.М.Горький исемендәге Әдәбият институтының югары курсларын уңышлы тәмамлый.

Заманында Аксубай авылларында фельдшер булып, Чирмешән район газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли.

1979 елдан һөнәри язучы.

2014 елның 27 гыйнварында вафат була.

Михаил Сениэль шигыре

ТӨНГЕ УРАМДА

Төн.
Җил зарлана –
Риза түгел төннән:
Бәргәләнеп йөри урамнарда.
Бер-бер нәрсә югалтканмы? Нигә
Шыңшый әле, елый: «У-а!.. У-а!..»

Күлләвекләр йоклый...
Ике гашыйк
Бер тупылга сыенган да, әнә,
Тора басып. Дәшми алар. Сүзсез.
Ни тапканнар? Белсәң иде
әгәр...

О-о!..
Еллар буе шулар кебек
Торсаң иде сыенып тупылга...
Язгы салкын төн бу. Мин –
ялгызмын.
Җил дә ялгыз... йөри уфылдап.

Моңсу гына җилфердәтә, әнә,
Яз байрагын – кызның
чәчкәйләрен...
...Басып тора икәү. Һәм аларга
Сыенган төн, тупыл – яз һәйкәле.

***Л.Лерон** тәрҗемәсе* ■

ЧУАШЛАР

Зариф Бәшири

ИКЪТИСАД, НАМУС ВӘ МИЛЛИЛЕКЛӘРЕ

Чуашларның иң мактанырлык бер нәрсәләре булса, ул да икътисадта ныклык вә осталыклары, намус вә миллиятләренә игътибарлыкларыдыр. Аларның һичбер «җәмгыяте хәйрия», «дарелгаҗизин»нәре[1] юк. Хәлбуки, аларда теләнчелек вә карак-

Йон эрләүче чуаш хатыннары. М.Крылов фотосы. 1895 ел

*Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

[1] Дарелгаҗизин – картлар һәм инвалидлар йорты. – *Ред.*

лык кеби начар нәрсәләрнең әсәре дә юктыр. Бу исә икътисадта осталык, намуслык, миллияткә игътибарлыкларыннандыр. Алар караклык вә теләнчелекне милләтебезнең яман исемен сату, намуссызлык вә кулда булган куәттән файдаланмаучылык, диләр. Бер чуаш ач булсын, шул вакытта кеше ишегенә барып, теләнчелек итеп, намусын сатмый. Ул намусын шәхсияте өчен түгел, миллияте өчен саклый. Бу исә аларның милләтчелекләрен исбат итсә кирәк.

Алар үзләрендә фәкыйрьлекне, теләнчелек вә караклык кеби яман һөнәрләрне башка милләткә күрсәтүдән соң дәрәҗәдә сакла领 ки, күп вакытта шуның белән мактаналар. Әмма кешегә хезмәт итүне, никадәр бай булса булсын, һич хурлыктан санамыйлар. Бәлки дә: «Татарларның бар белгәне теләнчелек, урлау, кешегә хезмәт итүдән хурланып ертык кием, ач тамак илә йөрү», – дип көлеп, үзләренең эшләүләре илә мактаналар. Аларда бер сәгать вакытны эшсез үткәрү – чып-чын начарлыктыр. Эшне һич ашыкмый, түкми-чәчми тырышып эшлиләр.

Чуаш авылларының һичберсендә атсыз, сыерсыз, йортсыз бер чуашны күрү мөмкин түгелдер. Бу исә икътисадта ныклыкларыннандыр. Бер тиен акчаны урынсыз әрәм итми, тәкәллефле[2] киемнәр кими, йорт әсбапларын кирәгеннән артык алмый, тәмле нәрсәләр ашамый, киләчәген бу көнге кеби кайгырта. Кыскасы, алар икътисад тугрысында гаҗәеб дәрәҗәдә сәләтле бер халыктыр.

Аларның бар эшләре иген сачү, урман кисү, кирпеч сугу кеби кара хезмәтләрдер. Игенне шулкадәр оста эшлиләр ки, күрше мөселман карьяләре ярты кыштан ач булу дәрәҗәсенә җиткән хәлдә, аларның ындыр тулы кибәннәре, келәт тулы ашлыклары ята.

Җирләрен яхшы саклыйлар, тиресне әрәм итми, кыш буе җир өсләренә түгәләр, иген өлгергән вакытында бер көн соңга калдырмый урып бетерәләр. Урган вакытта бер башакны җиргә төшерми, төптән кырып пөхтә итеп уралар. Ашлыкны сатып киенү, тәкәллефләнүне кайгыртмыйлар, бәлки әүвәл киләчәк мәгыйшәтьләрен тәэмин кылып куялар. Мөселман карьяләрендә ачлык булган елда да аларның игенне оста тәрбияләүләре аркасында, ындыр тулы кибәннәре була.

1908 елда 27 губернада ачлык булды. Ул вакыт Казан губернасындагы мөселманнар илә чуашларда да ачлык иде. Шул елны мөселман карьяләре ач булу дәрәҗәсенә җитеп, төркем-төркем теләнергә чыктылар, вәхшәт дәрәҗәсендә караклык һөнәренә ябыштылар. Ләкин чуашлар, әүвәлдәге хәзерлекләре аркасында, һичбер мохтаҗлык күрми, кыш чыктылар, бәлки дә күп мөселман карьяләрен ашаттылар. Шул елны «Кызыл хач» тарафыннан һәр авылда өйрә ашатылды. Мөселман карьяләреннән Чүти илә, чуаш карьяләреннән Тарыбирде карьяләре зурлыкта бер дәрәҗәдә булып, Чүтидә – 600 адәм, Тарыбирдедә 25 адәм ашады. Бу чуашларның икътисад җәһәтләре ни дәрәҗәдә икәннәрен ачык белдерә.

Чуашларның ашаган гади азыклары: икмәк, бәрәңге, тозлы кыяр илә кәбестә суы, борчак ашы кеби нәрсәләрдер. Хәтта бәйрәмнәрендә дә шундый нәрсәләрдән сырлы-мырлы пешереп уздыралар. Җәй көннәрендә бәрәңге яфрагы, балтырган, кузгалак кеби нәрсәләрне борчак камыры илә бергә суда пешереп икмәк илә ашыйлар.

Сыер асрасалар да аның фәкать сыек сөте, катыкларын гына ашыйлар. Майларын җыеп, базарга чыгарып саталар. Ат итеннән башка өй хайваннары вә куян итен ашау аларда дөрес. Хайванны суйганда, гадәт буенча, «Бисмилла» дип әйтәләр.

Чәйне бик сирәк эчәләр. Аның урынына баераклары – куәс, өй сырасы, ярлыраклары су вә әйрән эчә.

[2] Тәкәллефле – артык купшы.

МӘГАРИФ ВӘ ЯШЬЛӘРЕ ҺӘМ МАТБУГАТЛАРЫ

Чуашлар моңа кадәр мәгариф җәһәтеннән соң дәрәҗәдә артта булган бер кавемнән санала иделәр. Җәһаләт вә караңгылык чыптасы аларны шулкадәрле чорнамыш иде ки, алма эчендәге корт кеби үзләреннән башка милләтнең дөньяда барлыгыннан вә гомум мәдәниятеннән, сәясәт дөньясыннан бигрәк тә бихәбәр иделәр. Хәзердә дә күп булса, араларында 3-4 процент чуаш гыйлем вә мәгарифкә бер дәрәҗә әшнә булып, башкалары агач мисалында надан, һичбер шәйдән хәбәрсез вә һичбер төрле язуны укый вә яза белмиләр. Ләкин алардагы бу көнге инкыйлабка, мәҗбүри рәвештә булса да терәлгән сәбәпләр наданлыклары хакындагы язулардан каләмемне туктатып, киләчәктәге өмидләргә йөз тотарга мәҗбүр итәдер.

Чуашлар христиан диненә керү мөнәсәбәте илә, хөкүмәт тарафыннан авыл саен ышкулалар салынып, укытыла башладылар. Фәкать 20-30 еллардан соң күрәбез ки: үзләренең һәр урында тырышлыклары сәбәпле гаҗәеб дәрәҗәдә тәрәккый итәрләр. Аларның әһле мәгарифне сөюләре, бераз гына булсын аңга килгәннәренең дә бу көнгә кадәр наданлыкта калуларына үкенеп, гыйлемгә сусадыкларын танулары вә укуга тәмам иҗтиһадлары тиз көндә татарларны үтеп мәдәни бер милләт булачакларын ачык күргәзәдер.

Араларында аз гына мәгълүматлы бер кеше булса, аны кадерлиләр вә зурлыйлар, аз гына дәрәҗәдә исләре китеп торалар. Шунлыктан, балаларын авыл ышкулларында (ибтидаи мәктәпләрдә) генә укытып калдыруга канәгатьләнми, Учительски ышкула, семинария кеби мәктәпләргә төркем-төркем ташый башладылар. Бәгъзеләре исә хәзерге гыйлем вә мәдәниятнең шәрәфен аңлап җиттекләреннән түгел, бәлки дә гыйззәте нәфес[3]вә бер-беренә көнчелек кеби гадәтләрнең өстенлекләренә ияреп кенә булса да тырышалар. Чөнки чуашларда гыйззәте нәфес, бер-беренә көнчелек кеби гадәтләре шулкадәр зур роль казанмыштыр ки, кирәк нинди генә урында булсын, үзләренең эшләрен алда тотарга вә сүзләрен бирмәскә маллар, куәт вә көчләрен сарыф итмәктәдерләр. Менә шушы гадәтләре гомумән караганда начар гына булса да, гыйлем вә мәгарифләренең тәрәккыятенә бөек ярдәм итмәктәдер. Башка урынга бер тиен акча әрәм итмәгән бер чуаш: «Минем углым учитель, писер яхуд поп булачак», – кеби татлы өмидләр өчен уку юлына йөзәр, меңәр сум акчаны һич кызганмый түкмәктәдер.

Хәзерендә урта мәктәпләрдән генә булса да укып чыккан зыялы чуаш ара-сыра күренгәли. Ләкин алар безнең татар яшьләре кеби үз милләтен сүгү вә аның милли гадәтләрен таптау вә ташлау илә түгел, бәлки надан халыкның арасына кереп, һәр шәйдә уртача мәсләк илә милләткә хезмәт итәләр. Кыскасы, җиң сызганып хезмәт итәләр, озын вә тирән булган йокыдан уянмак заманы идекен аңлаталар. Тынычлык, билгесезлек вә хәрәкәтсезлекне изәргә вакыт идекен төшендерәләр.

Карт чуашларда миллият тәгассыбы соң дәрәҗәдә куәтле булып, яшьләрендә дә шулай уктыр. Алар шуның өчен картларны үзләренең сүзләренә тыңлата вә кызыксындыра алалар. Фәкать ни чара ки, бу көндә алар бармак илә санарлык дәрәҗәдә аздырлар.

Матбугатлары җәһәтенә килсәк, чуашлар матбугатның ни идекен дә белмиләр, чөнки аларның үз телләрендә вә үзләренә махсус язылмыш ни дини вә ни әдәби-фәнни бер данә китап вә рисаләләре юктыр. Фәкать рус хәрефе вә татар лисаны илә дини ибтидаи мәктәпләр[4] өчен язылмыш бер данә дәрес китаплары бардыр. Бу көндә дә ибтидаи мәктәпләрендә шушы китап файдаланыла. Мин бу китапны берничә мәртәбәләр күздән

---

[3] Гыйззәте нәфес – үз-үзен сөю.

[4] Ибтидаи мәктәпләр – башлангыч мәктәпләр.

кичерсәм дә, ни сәбәптәндер ки, исеменә вә мөхәрриренә дикъкать кылмадыгымнан вә карамаганлыгымнан үз-үземә гаҗәпләнәм.

17 үктәбер манифестыннан соңра Чабаксар шәһәрендә бер зыялы чуаш тарафыннан «Хыпар» исемендә чуаш телендә вә чуашларга махсус бер гәзит нәшер итеља башлаган иде, ләкин озакка бармады, тукталды. Ишетүемә күрә, тукталуы да мөхәрриренең социалист партиясенә мөнәсәбәтлектә гаепләнүеннән, имеш.

ТОРМЫШЛАРЫ ВӘ БӘЙРӘМНӘРЕ

Гыйлем вә мәгарифтән ераклашмыш халыкның тормышы әшәке вә пычрак булуы табигый бер хәлдер. Бәдәви вә вәхши кавемнең бет вә үләксә ашамак, бугаз канын эчмәк кеби гадәтләре – һәммәсе дә гыйлем вә мәгарифсезлектән килгәне һәркемгә мәгълүм булса кирәк.

Чуашларның да мондый гадәтләренең күбесен кылуларыннан сасы вә пычрак өйләрдә торулары, пычрак вә эт ялаган савытлардан ашаулары, тузан вә тупраклы чүплекләрдә аунаулары һәм мәдәнияттән, гыйлем вә мәгарифтән ерак булганлыктан идеке мәгълүм булса кирәк. Араларында әдәбият, пакьлек вә сәламәтлек хакында бер рисалә булмасын да шул милләт пакьлек, арулыкны кайдан ала белсен?!

Чуашларның тора торган җирләре (өйләре) күп вакытта кара ызба буладыр. Кара ызбаның миче морҗасыз булып, чыккан төтене өй эченә туладыр. Төтен чыгар өчен мичнең ике ягындагы стеналарында кечкенә генә ике төндек[5] тишеге була һәм ишекләре ике кат булып, бер катының өсте ачык була. Ишекнең икенче катын ачкач, өсте ачык ягыннан төтен чыгып торадыр.

Мич янында кирпечтән өеп ясалган бер чокырлы нәрсә булып, шунда ут ягалар да өстенә казан асып аш пешерәләр. Кирәк мич якынында вә кирәк аш пешергәндә булсын, өйләренең эче күз ача алмаслык төтен буладыр. Тәрәзәләре аз, кечкенә булып, пыяла вә карындыктан ясалып, корым вә тузан илә буялганлыктан, яктылыкны аз җибәрәләр. Шушы сәбәпләргә өйләренең эчке як стеналары кап-кара корымлы, гаять сасы вә начар һавалы, яман исле һәм дә караңгы буладыр. Кыскасы, өйләре илә мунчаларының аермалары бик аз булып, хәтта өйләре күбрәк ягылганлыктан, мунчадан да әшәкерәк диярлектер. Шуңа күрә дә чуашларның күзләре яшьләнеп торган авырулы, сулышлары тыгыз була.

Йорт әсбаплары искедән калган вә иске ысулдагы нәрсәләр генә булып, аш өчен булган савыт-сабалары агач вә кызыл балчыктан – авылларда ясалган чүлмәк, кувшин, таштабак кеби нәрсәләр буладыр. Аларны да яхшылап җумыйча катырып бетерәләр.

Күлмәк, сөлге, салфитка кеби нәрсәләрне салыр өчен сандык урынына кабык вә каен тузыннан ясалган әрҗә, шанчыклары (буямыйча табигый көенчә агачтан ясалган сандык рәвешендә бернәрсә) була. Йоклар өчен мендәр вә ястыклары – күбесенчә калын киндер капчыкка тутырылган салам вә печән. Кайберләрендә тавык вә каз җоннарыннан ясалган булса да, үзләренең тәрбиясезлекләреннән, тышы катып, җоннары сасып беткән буладыр. Чуашлар күп вакытта пычрак идәнгә, терлек арасына ятып йоклыйлар.

Йорт каралтылары иске ысулда булып, гүзәллектән ерак. Кыскасы, чуашларның тормышлары түбән вә пычрак илә чолганган булып, үзләреннән башка кавемнәргә нәфрәт барлыкка китерер дәрәҗәдәдер. Фәкать шуны да тәкърар итеп китмәк тиештер ки: чуашларның борыннарына мәгариф исе яхшы ук керде. Чуаш яшьләре гыйлемнәрне таратырга вә үзләренә иш арттырырга чынлап керештеләр. Шул сәбәпле, мондый иске

---

[5] Төндек – төнлек.

тормышлары да акрын-акрын гына булса да аяктан егылып, аның урынына заманыбызга муафыйк яңа тормыш урнашачагы өметледер.

Чуашларның үзләренә махсус бәйрәмнәре әүвәлдә күп булган. Атнада бәйрәмнәрен җомга көнне иткәннәр. Хәзерендә исә якшәмбе көн итеп, русларның башка бәйрәмнәрен дә үзләренеке кеби итәләр. Моның сәбәбе исә, христиан диненә кергән тараф күп булып, аларга иярүдән тормышка зарар килүнең нәтиҗәседер. Чөнки хәзерендә чукынмаган чуаш авыл саен бары 3-4 йорт булып, үз башларына бәйрәм вә үз башларына сәүдә итүдә зарардан башка, аларга бер файда юктыр. Шунлыктан, күп тарафка иярәләр дә бергә эшлиләр, бергә сәүдә итәләр, бергә бәйрәм ясыйлар. Димәк, болар да тормышка ияреп, бүген руслашу тарафына авышалар.

Хәзерендә дә мөселманнар күбрәк җирләрдә бәйрәмнәрен җомга көн итүче чуаш авыллары күренгәли. Бәйрәм көннәрендә эш эшләмиләр, мунча кереп үзләренчә пакь аталган күлмәк-ыштаннар кияләр. Ирләре каравыл өенә җыелалар да төрле хикәя вә урам хәбәрләре сөйләп көн уздыралар. Хатыннары да шулай ук капка төбенә җыелып утырып көн үткәрәләр. Җәй көне булса, кызлары вә егетләре ындыр артларына, су буйларына китеп, җырлап вә биешеп, караңгыга кадәр йөреп кайталар. Күп вакытта күрше авылларга барып, урам уртасына түгәрәкләнеп басалар да кайсы авылның егет вә кызларын мактап, кайсы авылныкын яманлап бәетләр әйтеп китәләр. Җырларыннан бер данәсен бу урында язсам, шаид зарарсыз булыр, дип уйлыйм: *«Эчәбез дә исерәбез, чөнки бу көн яхшы көн – Тәберде авылы кызларының авызлары бер карыш»*[6].

Бәйрәм азыкларының иң могтәбәрләре бәрәңге пирогы илә өй сырасыдыр.

ДОГАЛАРЫ ВӘ ТЕЛӘКЛӘРЕ

Чуашларның үзләренә махсус догалары бардыр. Болар иске заманнан бирле һич үзгәртелми, агыздан өйрәнелеп хәзергә кадәрле килгәннәр. Хәтта бу заманда христиан диненә кергәннәре дә шушы иске догаларын мөкаддәс вә Алла каршында мәкъбул итеп игътикад кылалар һәм балаларына да яшьтән үк өйрәтеп куялар.

Догаларында бөтенләй диярлек дөньяви файдалар гына соралган мәгънәләр вә теләкләр буладыр. Мәсәлән, икътисадта киңлек, сәламәтлек, бәла вә казадан иминлекне сорау кебиләр. Кай арада тугрылык, яманнан саклык, шайтан вә усалдан ераклык, гөнаһтан гафу үтенү кебиләр булгалый. Ләкин ахирәви мәнфәгатьләрне бик аз сагыналар.

Аларда күк капусы ачылу чын игътикад белән көтелә. Ышануларынча, күк капусы ачылганда нинди генә теләк теләсәләр дә Алла аны кабул итә, диләр. Шуның өчен дә шулвакытта мөмкин кадәр яхшы теләкләр теләп калырга бар көчләре илә тырышалар. Кайбер төннәрдә йолдыз атылу кеби кинәттән берәр яктылык пәйда булса: *«Ындыр тулы кибән, кесә тулы акча»*, – дип кычкырып калалар.

Догалары гаять иске вә авыр сүзләрдән булып, җөмләсе кыска вә күп мәгънәләрне, гали теләкләрне белдерә. Һәр дога бер булган Аллага хөрмәт вә түбәнчелек белән эндәшеп башлана.

Кич ятканда, иртә торганда, кешедән яхшылык күргәндә укый торган догалары һәммәсе үзенә махсус тәртип исә кылынмыштыр. Иртә торгач укый торган догалары ошбудыр: *«Әй, күктәгез атабыз!*[7] *Синең исемең бөек вә гафурдыр. Синең падишаһлыгың иркен вә теләвең гали. Без яшәгән һаваны да иркен вә саф ит. Сиңа борчуыбыз булса,*

---

[6] Текстта мисаллар чуаш телендә дә китерелә. Без исә, журналда күп урын алмасын өчен, аларның автор тәрҗемә иткән вариантларын (алар курсив белән бирелде) гына калдырабыз.

[7] Чуашларның «ата» сүзе бездә мәшһүр булган мәгънәсе илә түгел, бәлки һәр шәйнең асылы вә мөдире мәгънәсе илә булыр. – *«Шура»*.

Чуаш рухание Василий Ефремов һәм аның гаиләсе. Казан губернасының Цивильск өязе. 1910 ел

син аны кичер. Безгә бу көнге көннәребезне үткәрерлек икмәк бир, гөнаһыбызны күрмә, усалдан вә шайтаннан безне ерак кыл!»

Кич белән укый торганнары: «*Әй, безнең югарыдагы яхшы атабыз! Мин хәзер югарыга ятамын. Иртәнге ашны ашарга, тагын да сәламәтлек белән йөрергә насыйп ит. Әгәр үлсәм, дыньяда минем яман исемемне калдырма*», – димәктер.

Яңгыр яуганда тели торган теләкләре: «*Әй, падишаһлыгың гали булган Алла! Яңгырны күп вә зарарсыз яудыр, игенне яхшы үстер! Яхшы кеше (мосафирдан) миндә кунак булса, икмәк-тозсыз җибәрергә язма! Син, ни кылырга теләсәң, шуны кыла аласың. Миңа эшләргә сәламәтлек бир!*» – димәктер.

Догаларның моннан башкалары күңелемдә булса да, авыр сүзләренә тешем батып җитмәгәнлектән, каләмемне туктатырга ирекле-ирексез мәҗбүр булдым.

Шура. – 1909. – №14. – Б.430-432; №15. – Б.459-460; №16. – Б.498-500; №18. – Б.557-558.

Ахыры бар

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №8 август 2018

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ[1]

Габдерәшит Ибраһимов

Хойморск (Хандагатайск) дацаны. Бурятия, Тункинск районы, Ашан пос. 1996 ел. (Н.Л.Жуковскийның шәхси архивыннан)

БУДДИСТЛАР ГЫЙБАДӘТЛӘРЕН ЯШЕРЕН КЫЛАЛАР

Мин бераздан, сөйләшүнең темасын үзгәртеп, болай дидем:

– Гыйбадәтханәләрегезне карап йөрдем, бик канәгать калдым. Буддистларның рухани йолалары күрсәтелми икән. Гаять нәфис сәнгать әсәрләре, сәнгать ягыннан гаять югары дәрәҗәдә ясалган потлар бар. Тик тәрҗемәчем миңа кайбер кечерәк гыйбадәтханәләрне күрсәтмәде. «Ачкычы юк, фәлән-төгән», – диде. Мин Сездән сорыйм: кабат һәммәсен күрергә мөмкин булырмы икән?

– Динебезнең таләбе ул. Будда динендә булмаган кешеләргә күрсәтеп булмый торган бер бүлем бар, дигән идем бит, менә шул инде.

– Ихтимал, дошманнарыгызга күрсә-

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

[1] Кечкенә гыйбадәтханәләргә савмаа диләр. Безнең үгет-нәсыйхәт китапларында «заһитләрнең савмаасы» дигән сүз белән бер бәйләнеше юкмы икән? (Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе).

тергә тиеш түгелсездер. Тик минем Будда диненә бернинди дошманлыгым юк. Ул гына да түгел, ихтирам белән карыйм...

– Гомумән, чит милләтләргә күрсәтә алмыйбыз, чөнки безнең рухани йолабызны кимсетәләр, хурлыйлар...

– Ышаныгыз: мин һичбервакыт берәүнең дә динен хур күрү фикерендә түгел һәм хур күрмәм дә. Күңелемә хуш килмәгән очракта, гадәттә, сүзсез торам.

– Кичерегез, күрсәтә алмаячакмын.

– Әгәр динегез шуны таләп итә икән, берни дияр хәлем юк. Ләкин уйлап чыгарылган нәрсә булса, рөхсәтегезне сорыйм. Христианлыкта тәслис, ягъни өчләштерү мәсьәләсе бар: бер үк вакытта Аллаһ өч тә була, бер дә була. «Бердер, өчтер», – диләр. «Бер ничек өч була, өч ничек бер була, мөмкин хәлме бу?» – дисәң: «Бу – илаһи сер, христианлыкны кабул итмәгән кешегә аңлашылмый», – диләр. Ләкин аңлашылмаган нәрсәне кабул итү дә мөмкин түгеллеген уйлый алмыйлар. Әгәр сездә дә хәл шуңа охшаш булса, ярар, күрсәтмәгез, әгәр сәбәп башкада исә, күрергә теләр идем.

– Ярар, теләсәгез, карарсыз, ләкин хур күрмәвегезне үтенәм.

– Ышандырып әйтә алам: Ислам дине һичбервакыт андый нәрсәне рөхсәт итмәгән. Без менә мондый юлдан барабыз: «Ләкум диникум вәлийәдин» (Кяфирун: 6), ягъни «Безнең динебез – безгә, сезнең динегез – сезгә...».

НУХ ТУФАНЫ

Тора-бара, мәсьәләне Нух туфанына китереп бәйләдем. Хамба Лама шунда гаҗәеп бер фикер әйтте:

– Нух туфанын нигезеннән инкарь итү – Аллаһыга каршылык исбат итү дигән сүз, ә бу тыела. Тик каршылыкны исбат итү тыелган кебек үк, золымны исбат итү дә тыелган. Мисыр җирендә газапка дучар ителгән кыбтиләр белән кытайлар арасында бәйләнеш була алмас, туфан да әгәр булган булса, шул җирләрдә булгандыр.

– Бу – дөрес фикер, туфанның булмаганлыгына караган тагын бер дәлилегез бармы?

– Моның кебек вакыйгалар өчен тарихтан да зур дәлил була алмас. Безнең Кытай һәм Монгол тарихларында туфан турында бер генә сүз дә юк. Югыйсә 4000 ел элек, 6000 ел элек теркәлгән тарихларыбыз бар. Шундый зур вакыйга булып та, теркәлми калуы мөмкинме?

ХАМБА ЛАМАНЫҢ ШӘХСИ ТӘГЪЛИМАТЫ

Бераздан Хамба Лама:

– Хәзер мин Сезгә үз фикеремне һәм үз тәгълиматымны аңлатып китәргә телим. Моны исә мин бер монгол кешесе, бер бурят кешесе буларак сөйләячәкмен, ягъни Хамба Лама буларак түгел, – диде һәм түбәндәгеләрне сөйләде: – Минем үземнең дә бер тәгълиматым бар. Мин шуңа инанам: бу галәмдә бөтен нәрсәне тәртипкә салучы көчнең, бар итүче җитәкченең булуы акылга сыя торган хәл. Сез ул көчкә теләгәнегезчә исем бирә аласыз, теләсәгез, «табигать», диегез, теләсәгез, «Хода», теләсәгез, «Аллаһ», диегез, барыбер Ул – берәү. Моның барлыгын исбат итәр өчен сәламәт акыл җитә. Сәламәт табигать исә инкарь итә алмас, дип уйлыйм. Моннан тыш, кешелек табигатенең, һичшиксез, бер тәңрегә ихтыяҗы бар. Безнең агач кисәкләреннән, чүпрәк кисәкләреннән үзебезгә илаһлар ясарга тырышуыбыз әлеге шул табигый этәргеч буенча эшләнә. Ләкин кавемнәрнең нинди дер бер илчегә, пәйгамбәргә ихтыяҗ тоюы яки тоячагы мәсьәләсе миндә икеләнү тудыра. Әйтик, табигый ихтыяҗ да булсын ди, тик бу ихтыяҗ җир шарының бер тарафында булып та, икенче тарафында ник юк? Безнең Монголиядә һәм Кытайда бер пәйгамбәр дә барлыкка килмәгән. Тарихыбызда да *пәйгамбәр* атамасын хәтерләтерлек бер генә сүз дә юк.

Аның бу сүзләренә мин болай дидем:

– Ә Буддаларның пәйгамбәр булу ихтималы юкмы икән? Безнең Коръәндә: «Без, бер пәйгамбәр җибәрелгәнгә кадәр, бер генә өммәтне дә газапка дучар итмәбез...» (Исраа: 15), диелгән. Бу бөек сүзләргә караганда, пәйгамбәр һичшиксез килгән булырга тиеш.

– Буддаларның пәйгамбәр булу ихтималы бик юк. Инҗилнең (Евангелиянең), Тәүрат һәм Коръәннең өйрәтү ысуллары Будда китаплары ысулыннан бөтенләй аерылып тора. Коръәндә булган кайбер хикәяләр Тәуратта да, Инҗилдә дә бар: Адәм кыйссасы, Нух кыйссасы һәм тагын күп кенә кыйссалар, берсендә булганча, башкаларында да бар, тик безнең Будда китапларында боларның берсе дә юк.

– Мәгънәсе үзгәргән, дәверләр үтү белән бу хәлгә килгән булуы да мөмкин. Будда китабында Мөхәммәтнең пакь исеме очравы турында әйткән идегез. «Менә бу да бер бәйләнеш», – диясем килә.

– Кытайлар һәм монголлар – бик борынгы халыклар, боларның тарихларында бөек пәйгамбәрләр турында бер сүз дә булмау бик сәер. Буддаларның исемнәрендә дә пәйгамбәрлеккә бәйле берни дә юк. Алдарак дүрт Будданың исемен телгә алып үткән идем. Иң соңгы булып киләчәк Будданың исеме исә Мойбе.

АУРУПАДАГЫ БУДДИСТЛАР

Хамба Лама белән диннәр турында бу кадәр сөйләшкәннән соң, ул, үзенең Аурупага сәяхәте турында сүз башлап, болай диде:

– Мин Франциядә булдым. Французлар арасында Будда динен кабул иткән шактый кеше күрдем. Тик шунысы сәерсендерде: берсе дә буддизм турында берни белми. «Ни өчен Будда динен сайладыгыз?» – дип сорадым, алар: «Безнең Франциядә буддизм юк, аны биредә без булдырдык», – дип җавап бирделәр. Моңа: «Мода тинтәклеге дингә дә тәэсир иткән», – дип кенә әйтә алам. Шулай да беркөнне җәмгыятьләренә бардым, буддизмга караган бер гыйбадәт йоласын бергәләп үтәдек, бик ошаттылар, әлбәттә, мин дә канәгатьлек белдердем.

МИССИОНЕРЛАРНЫҢ БУДДАГА ҺӨҖҮМНӘРЕ

Хамба Лама сүзләрен болай дәвам итте:

– Аннары Гамбургтан Һиндстан юлы белән әйләнеп кайттым. Сиамга да тукталдым. Кайда гына булсам да, һәр милләтнең алдынгы кешеләре һәм дин әһелләре белән күрешеп сөйләштем. Сәяхәт вакытында тупланган мәгълүматларга таянып, шуны әйтә алам: миссионерлар һәр җирдә буддистларга көчле һөҗүмнәр ясыйлар.

– Японнар буддизмны яклауны кирәк күрмәсләрме икән?

– Мин японнар белән таныш түгел. Мәдәниләшүне сайлаган милләтләрнең дин белән бәйләнешләре бары тик сәяси яктан гына кирәкле булып күренергә мөмкин. Инде мин Сезнең мөмкинлекләрегездән файдаланырга телим: насыйп булып, сау-сәламәт барып җитсәгез, миңа бу турыда Япониядән мәгълүмат җибәрсәгез, Сезгә чиксез рәхмәтле булыр идем.

– Иншә Аллаһ, хат язышырбыз. Ләкин мин Сездән тагын бик күп нәрсә сорашып белергә, гыйлемегездән файдаланырга телим. Хәзер, Сезнең рөхсәтегез белән, бераз ял итик, иртән тагын әңгәмә корырбыз.

– Теләсәгез, биредә дә кунып кала аласыз. Мин ялгызым яшим.

– Мин кунакханәгә китим инде. Башкарырга кирәкле вазыйфаларым да бар.

Кунакханәгә кайткач, вазыйфаларымны башкардым. Иртән иртүк тагын хезмәтче лама килде һәм Хамба Ламаның

[2] Пекинга баргач, мин бу турыда һинд кешесе Мөхәммәт Хәниф әфәндедән сорадым. Ул болай диде: «Дөрес, тик кечкенә генә бер төзәтү кертергә кирәк. Мадраста мәҗүсиләр, гадәттә, фәкыйрь кешеләрен җиргә күммиләр. Безнең мөселманнар ул мәҗүсине үз диннәренә туры китереп яндыралар» (Габдерәшит Ибраһимов).

Безнең мирас №8 август 2018

Хамба Лама

мине көтүен әйтте. Чәемне тиз генә эчеп, Хамба Лама янына киттем.

Бу юлы Хамба Лама болай диде:

– Төнлә уйланып ятканда хәтеремә килде: Һиндстанда Мадрас шәһәрендә мөселманнарның мәетне ут төртеп яндыруларын күргән идем. Ислам динендә дә мәетне яндыру бармы икәнни? Мин моны үзем күрдем, мөселманнар, җыелышып, бер мәетне яндырдылар.

– Монда, һичшиксез, бер хата бардыр, мөселманнарда һич кенә дә мәетне яндыру була алмас.

– Мин дә бик аптырадым. Була алмаслыгын беләм, Исламият рөхсәт итмәс, ләкин үз күзләрем белән күрдем, шуңа күрә соравым. Мин Ислам диненә караган кайбер әсәрләр укыдым, Ислам нигезләрен дә беләм. Исламда үлеләрне яндыруның тыелган булуы хәтеремә килде, ләкин, ничектер, шул күренешне ачыклый алмый калдым.

Дәвамы бар

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ «ЯРА» РОМАНЫНДА МИЛЛИ ҺӘМ ДИНИ МОТИВЛАР

Рәҗәп Шукрү Гүнгөр



Аяз Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. 1930 елда атасы бүгенге Зәй районына – керәшен татарлары яшәгән Югары Баграж авылына укытучы итеп җибәрелә. Әдипнең балалык һәм мәктәп еллары шул авылда үтә. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң, атасы Урта Баграж керәшен татарлары авылы мәктәбендә эшли башлый. Аяз Гыйләҗев урта мәктәпне 1945 елда тәмамлый, аннары Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Әдәби иҗат дөньясына ул шигырь белән килеп керә, тик 1945 елда кинәт борылыш ясап, шигырьдән ераклаша, хикәяләр яза башлый, тора-бара язучылык сәнгатенең башка өлкәләрен дә ача. Беркөн килеп, А.Гыйләҗев университетта укуын

ярты юлда калдыра да авылына кайтып китә. Берара колхозда эшләгәннән соң, районга китеп бара, Зәй районы комсомол комитетында бүлек мөдире булып эшли. 1948 елда кабат Казанга кайтып, Аяз Гыйләҗев Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә керә, яхшы укый, бүлекнең әдәбият түгәрәге эшенә дә бик теләп катнаша. Түгәрәк утырышларында ул да иптәшләрен үзенең хикәяләре белән таныштыра, уй-теләкләрен тыңлый, әдәбият белән бәйле бәхәсләрдә, фикер алышуларда бик актив катнаша.

1950 елның март аенда «Совет системасына каршы котырту һәм милләтчелек эшләре алып бару»да гаепләнеп, кулга алына. 1950 елның декабрендә җиде елга төрмәгә утыртыла. Төрмәдә милли үзаң, миллият тойгысы турында бик тирән уйланган әдипнең тормышка карашы бөтенләй үзгәрә. Сталинның үлеменнән соң, Аяз Гыйләҗев иреккә чыгарыла, аңа Казан университетында укуын туктаган җиреннән дәвам итәргә рөхсәт бирелә. Төрмәдән азат ителгәннән соң, ул бөтен күңелен биреп әдәбият эшенә тотына. 1950-1960 еллар арасында әдип каләменнән тамган иҗат энҗеләре – озын хикәяләре (повестьлары) белән киң танылa. Бу елларда ул роман һәм хикәя жанрларында аеруча уңышлы иҗат итә. Аяз Гыйләҗев, университетны тәмамлаганнан соң, 1957-1961 еллар арасында газета-журнал редакцияләрендә эшли. Мәскәүдә Совет Язучылары берлеге оештыра торган ике еллык Югары әдәби курсларда да укыганнан соң, 1963 елдан башлап, ул профессиональ язучылык эшенә күчә. Әдип үзенең әсәрләрендә иҗтимагый, әхлакый, мәдәни темаларны яктырта, яшәешләреннән гыйбрәт-дәрес алырга кирәкле каһарманнарны һәм аларның капма-каршысы булган кеше образларын драматик вакыйгалар чолганышында бар итә.

«Дүрт кеше» (1961), «Өч аршын җир» (1962), «Зәй энҗеләре» (1963), «Бер кеше» (1959), «Урталыкта» (1969), «Яз кәрваннары» (1972), «Мәхәббәт һәм нәфрәт хикәясе» (1973), «Мең чакрым юл» (1977/1978), Җомга көн кич белән (1979), «Әтәч менгән киртәгә» (1979/1980), «Яра» (1988/1989), «Урамнар артында яшел болын» (1969), «Балта кем кулында» (1988/1989), «Ягез бер дога» (1991/1993) кебек әсәрләре белән танылган Аяз Гыйләҗев Татарстандагы күп кенә премияләр лауреаты да. Язучының иҗатында драма әсәрләре дә шактый зур урын били. Ул – комедия һәм трагедия төрләрендә кырыкка якын сәхнә әсәре биргән шәхес. Боларның бик күбесе өлкә һәм шәһәр театрларында сәхнәгә куелган. Кайберләре башка телләргә дә аударылып, башкорт, авар, чуаш, рус театрларында уйналган. «Өч аршын җир» әсәре соңгы елларда кабат сәхнәгә куела. Шул ук әсәр хакас теленә тәрҗемә ителде һәм Абакан шәһәрендә Хакас милли драма театры тарафыннан 2015 елның ноябрь аенда «Кичер мине ватан туфрагы» исеме белән сәхнәгә куелды.

Аяз Гыйләҗевнең әдәби хатлары, тәнкыйть мәкаләләре, очерклары, истәлекләре хатыны Нәкыя Гыйләҗеваның һәм фән кандидаты Миләүшә Хәбетдинованың тырышлыклары белән, һәркайсы якынча 700 битлек алты томнан торачак дип уйланылган әсәрләренең инде дүрт томы Казанда басылып чыкты.

Татарлар әле дә аякта басып торалар, әле дә яшиләр икән, моның төп сәбәбе – халык хәтеренең яшәвен бөтен җанлылыгы белән дәвам иттерүдә. Татар җәмгыяте иң авыр чорларда да үз йолаларын, гореф-гадәтләрен саклап калган. Бу мәдәни мирасны саклап калу һәм яшәтүдә сәнгать әһелләренең роле аеруча зур.

Танылган язучы, әдип Аяз Гыйләҗев 2002 елның 13 мартында Казанда вафат була һәм Казандагы Яңа бистә мөселман зиратында җир куенына иңдерелә («Әдипләребез», 2009 ел, б.433-435).

Аяз Гыйләҗев – татар халкының милли үзаңы үсүгә һәм милли тойгының көчәюенә зур өлеш керткән шәхес. М.Хәбетдинова 60 нчы елларда әдәбият дөньясында мөһим урын биләгән язучыларны меньшевиклар һәм большевиклар дип ике төркемгә бүлеп бәя биргән бер мәкаләсендә, совет яшәү рәвешен кире кагучы меньшевик язучылар арасында Аяз Гыйләҗевне дә күрсәтеп үтә. Гыйләҗев әдәби иҗатының башлангыч чорында рус идеологиясенә каршы чыккан һәм шуның нәтиҗәсендә сөргенгә дә сөрелгән. (Хәбетдинова, 2013 ел, 193 б.).

Совет системасында әдәбият һәм сәнгать марксизм идеологиясе йогынтысы астында яшәде. Әдәбият дәүләт идарәчеләре кул астында булды һәм сәнгатькәрләр үзенчәлекле, ирекле әсәр иҗат итүдән мәхрүм иде. 60 нчы еллардан соң, кайбер язучылар бу басымнардан котылырга тырышып, система идеологиясенә туры килмәгән әсәрләр яза башлыйлар. Бу чор әдипләре үз әсәрләрендә кешене алгы планга чыгаралар һәм сәнгатьне системаның хезмәтчесе булудан коткарырга тырышалар. А.Гыйләҗев тә – шул чор, шул буын язучыларының берсе. (Чоноглу, 2013 ел, 83 б.).

Руслар Урта Азияне тәмам яулап алганнан соң, бөтен төрки дөньяда язучылар да, халыклар да тарих, гореф-гадәтләр, дастаннар, риваятьләр белән тагын да ныграк кызыксына башлый. Татарлар әле дә аякта басып торалар, әле дә яшиләр икән, моның төп сәбәбе – халык хәтеренең яшәвен бөтен җанлылыгы белән дәвам иттерүдә. Татар җәмгыяте иң авыр чорларда да үз йолаларын, гореф-гадәтләрен саклап калган. Бу мәдәни мирасны саклап калу һәм яшәтүдә сәнгать әһелләренең роле аеруча зур. Татар халкының нинди авыр шартларда да мәдәни мирас ярдәме белән яңадан үз милли дөньясын торгыза башлавында халыкның рухи байлыгын әсәрләрендә чагылдырган әдипләрнең ролен танымый мөмкин түгел. Иҗаты милли рух белән сугарылган язучыларның берсе нәкъ менә Аяз Гыйләҗев иде. Әсәрләренең күпчелек өлешен совет идеологиясенең иң көчле чорында иҗат иткән бу бөек язучы, система хезмәтчесе булуны кире кагып, үз милли әдәбиятына хезмәт итүне максат иткән һәм гомерен шуңа багышлаган (Чоноглу, 2013 ел, 84 б.).

Чоноглуның фикеренә күрә, «Гыйләҗевнең роман һәм хикәяләрендә халыкның рухи байлыгы белән бәйле элементлар шактый күп һәм алар мөһим урын биләп торалар. Әсәрләренең татар халкының милли рухы белән сугарылган булуы, совет чорында килеп туган милли мәсьәләләрнең алгы планда урын алуы үткәнгә караган әдәби байлыкның җәмгыятьтәге яшәү шартларында юкка чыгып китмәс өчен тарихлыкны саклавын уйласак, җәмгыятьнең бу әсәрләргә тотынып, алар ярдәме белән үткәненә ялгануында һәм бүгенгенең мәгънә казануында язучының өлеше зур икәнлеген бик ачык күрербез» (Чоноглу, 2013 ел, 86 б.).

Татар халкының бөек язучысы Аяз Гыйләҗевнең «Яра» романы Советлар берлеге чорында иҗат ителгән әһәмиятле әсәрләрнең берсе булып санала. Романда Икенче Бөтендөнья сугышы һәм сугыш арты еллары, бу сугышның фәлсәфи үлчәмнәре, татар тормышына ясаган йогынтысы мәсьәләләре чагылыш таба.

Мәгълүм булганча, татар әдәбиятында, хәтта Советлар чорының бөтен яшәешендә, совет идеологиясе тарихи чынбарлыктан алгарак планга чыгарылган. Совет идеологиясен яхшы аңлаган Аяз Гыйләҗев романнарында чынбарлыкны идеология өйрәткәнчә түгел, үзе күреп белгәнчә чагылдыра. Бу романда да гореф-гадәтләр һәм йолалар кушканча яшәү рәвешенә караган бик бай мәгълүмат туплап бирелгән. Халык иҗатының

сүз җәүһәрләре булып саналган әкиятләр, җырлар, ышанулар, мәкальләр, әйтемнәр, болардан тыш әле тагын хайваннар дөньясы, ризык әзерләү, ашау белән бәйле һ.б.ш. бик күп гореф-гадәтләр, йолалар романның бай җирлеген барлыкка китергән.

Язучының бу бай рухи хәзинәне җәмгыятьтә барган катлаулы вакыйгалар чорында телгә алуы аерым зур мәгънәгә ия. Язучы каләменнән төшеп ак кәгазьгә теркәлгән, чын милли рух белән сугарылган әсәр, әдәбиятның милли-мәдәни дөньяны яңадан төзүдә, очраган каршылыкларны җиңүдә никадәр мөһим роль уйнавын ачык күрсәтә. Алда язучының татар халкының милли горурлыгын тергезү һәм яшәтү өчен куйган тырышлыгы, мәдәниятнең авторитар дәүләткә каршылык күрсәтү өчен көрәш кыры барлыкка китереп, һәртөрле хокуктан мәхрүм калган очракта да кабат көч туплауда ни рәвешле ярдәм итәчәген күзалларга мөмкинлек бирә. Романда татар җәмгыятенең дини тормышы һәм мәдәнияте турында да киң мәгълүмат бар. Биредә татарларның Ислам диненә тугрылыклы калулары турында сүз алып барыла.

«Яра» романында милләткә үрнәк булырлык, милли кыйммәтләргә нык бәйле идеаль каһарманнар һәм тормышта гыйбрәт-сабак алырлык вакыйгалар сурәтләнгән. Монда очраклы хәлләр, вакыйгалар юк. Биредә язучы рус дәүләтенең басымын тәнкыйть итә, милләтнең яраклашып көн күрергә мәҗбүр булуын тасвирлый.

А.Гыйләҗев саф, шома, матур тел белән язылган бу романда татар халкының матди һәм рухи кыйммәтләрен алгы планга куярга тырышкан. Әсәрдә тел, дин, тарих, йола кебек элементлар һәм болардан оешкан яшәү рәвеше милли образлар аша ачылган.

«Яра» романы, милли һәм дини элементлар ягыннан чыгып караганда, шактый бай материал туплаган әсәр булып тора. Бу романны укып, татар халкы һәм башка төрки халыклар да билгеле бер чорда кичерелгән золымнарның шаһиты булганнар, нәфрәтләнгәннәр, кайгырганнар, сөйгәннәр, сөенгәннәр һәм үз киләчәкләрен бар итү өчен ныклы нигез корырга тырышканнар.

Роман, үзенең эчтәлегендәге вакыйгалар аша, укучыга аерым төр кеше тибын һәм яшәү рәвешен тәкъдим итә; төркилек һәм ислам аң-фикере белән дөнья көтү, әсирлеккә, золымга, хаинлеккә каршы баш күтәреп, үз милләтеңә тугрылыклы калып яшәү фикерен алга сөрә.

«Яра» романына исламчылык һәм миллиятчелек идеологиясе күз алдында тотылып бәя бирелергә тиеш, чөнки моны әсәрнең язылу вакыты, анда сүз алып барылган вакыйгаларның чоры һәм шартлары таләп итә. Язучы романда төркичелек яки исламчылык фикерен ачыктан-ачык калку итеп күрсәтмәсә дә, бу ике фикердән дә файдаланган һәм аларны әсәренә вакыйгалар агышын бозмаслык итеп кушып үргән.

Файдаланылган әдәбият:

1. Әдипләребез. 2 том. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009.
2. Habutdinova, Milevşe. (2013). Cuma Günü, Akşam..., çev. Fatih Kutlu, Bengü Yayınları, Ankara.2013 (Хәбетдинова Миләүшә. Җомга көн кич белән. Фатих Кутлу тәрҗемәсе. Анкара: Бәнгү нәшрияты, 2013).
3. Ayaz Gıylecev. Yara. Çeviri: Fatih Kutlu. Palto Yayınları 2018 İstanbul. (Аяз Гыйләҗев. Яра. Тәрҗемәче: Фатих Кутлу. Истанбул: Палто нәшрияты, 2018).
4. Çonoğlu, Salim. (2013). Hayatın Anlamını Millete Hizmette Gören Yazar: Ayaz Gıylacev ve «Cuma Günü Akşam» Romanı Üzerine Bir Değerlendirme, Kardeş Kalemler Dergisi, S. 84, s.83-87, Ankara. (Чоноглу Сәлим. Яшәүнең мәгънәсен милләткә хезмәттә күргән язучы Аяз Гыйләҗев һәм аның «Җомга көн кич белән» романы турында// Кардәш каләмнәр. Анкара, 2013, №84. – 83-87 битләр).

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Әсәрләрендә – милли көрәш рухы

(Әдип иҗатына караш)



Равил Фәйзуллин

Үзем турында үзем

Ун яшьләремдә шигырь язу, шагыйрь булу теләге уянган иде. Балачакта китапларны күп укыдым. Зур кеше буласы килә иде. Зур кеше, хыял җитмәслек кеше минем өчен язучы иде. Чөнки хыялны алар тудырган китаплар үстерде бит! Студент елларында ике китабым чыкты. (Ул чакта китап чыгару үзенчә авыр, әмма бик тә дәрәҗәле иде!) Беренче китап – нәниләр өчен шигырьләр – «Рәсем ясыйм» (1965), икенчесе – зурлар өчен шигырьләр – «Аҗаган» (1966). Шул «Аҗаган» дигәне заманында шактый шау-шу кузгатты. Әдәби даирәдә ныклап таныла башлауга шул бәләкәй күләмле китап сәбәпче булды бугай. Шигърияттә үз урыныңны даулау-яулауда, һичшиксез, 1976 елда басылып чыкккан, 1978 елда (21 ел элек) Тукай премиясенә лаек булган «Шигырьләр һәм поэмалар» исемлесе – шактый ук күләмле китапның роле зур булды дип исәплим.

Иң күп язылганы әлегә – шигырь. Шулай ук публицистика, гыйльми характердагы мәкаләләр, эссе-уйланулар, новелла-парчалар, кыскасы, чәчмә формалар да миңа ят түгел. Шигъриятемдә үзем өчен иң кадерлеләре, мөгаен, кыска шигырьләрдер (бу әле озын шигырьләрем ошамый дигән сүз түгел!). Татар шигырендә бу форманы җанландыруда, үстерүдә, бәлки, беркадәр өлешем, хезмәтем бардыр.

Китапларны күп чыгардым. Җәмгысы – 40ка якын. Иҗатны балалар язучысы булып башлаган идем һәм байтак еллар дәвам да иттем (балалар өчен чыккан китаплар: «Рәсем ясыйм» (1965); «Күмәч пешерүчеләр җыры» (1977); «Паласны кем кагар?» (1980); «Якты моң» (1983), «Сәгыйть белән сәгать» (1989) һәм... хәзер дә балалар шагыйре дә булырга хыялланып яшим... Чөнки балалар язучысы булу – сабыйлыкка, сафлыкка кайту дигән сүз! Ә кемнең болганчык, шактый ук пычранган сулык-күлләрне күргәннән соң чиста-пакь чишмәгә йөз куясы килмәс икән!

Балачакта ук кеше, күңел теләгенә һәм табигый сәләтенә карап, үзенең кем булачагын күзаллый алса, ул – бәхетле кеше. Үземне шундыйлардан исәплим. Шигърият гомерем буе тугры юлдашым, таянычым, яшәү мәгънәм булды.

1999

Әдип турында кайбер каләмдәшләренең фикерләре

Равил Фәйзуллин... СССР Язучылар Союзына член итеп алганда аңа 23 яшь иде. Язучыларның Бөтенсоюз күләмендә узган съездларының берсендә иң яшь делегат ул иде. Үз буыным шагыйрьләреннән башлап шушы көнгә хәтле күзәтеп килəм, безнең поэзиягә болай иртә керүчеләр бик аз. Яшьтән, иртә хәзерлек белән керүчеләр аз. Иртә килде, шау-шу белән килде. Хәзер инде «Аҗаган», «Мәрмәр», «Гадиләргә гимн», «Наз» кебек алты-җиде шигырь җыентыгының авторы.

Бары бер җыр кирәк миңа
бу тормышта,
бары бер җыр...



Күренекле әдипләр Әлмәт язучылар оешмасының яшь җитәкчесенә, уңышлар теләп, фатиха бирәләр. Сулдан уңга: Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов. 1968 ел

Яшәргә, көрәшергә өнди торган җыр. Равил Фәйзуллин рус телендә киң дөньяга, күпмилләтле совет поэзиясенең кайнап торган олы мәйданына чыга. Мин шуңа шат: ул өлкән буынның йөзенә кызыллык китермәячәк.

Сибгат Хәким.
1973

***

Хәзерге татар шигыре күләме буенча кыскара, җыйнаклана, тыгызлана бара. Бу өлкәдә Равил Фәйзуллин эзләнүләре аеруча нәтиҗәле булды. Ул кыска шигъри алымның абруен бермә-бер күтәрде. Татар һәм башка халыклар поэзиясенең ачышларына таянып, шагыйрь тыгыз калыпка тормыш фәлсәфәсен, халәти һәм фикри киеренкелекне алып керде.

Тәлгат Галиуллин.
1996

«Татарстан яшьләре» газетасы каршындагы әдәби берләшмә утырышы. Сулдан уңга: Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Шамил Рәкыйпов. 1965 ел

Разил Вәлиев белән

***

Әле дә хәтердә: 1966 елның май ае иде. ВЛКСМ Үзәк Комитеты үткәргән яшь шагыйрьләр фестивалендә җиңүчеләр Мәскәүдән Бөтенсоюз телевидениесе буенча чыгыш ясый. Инде үз республикаларында танылып, бөтен илгә аваз салырга җыенган төрле милләт шагыйрьләре. Менә озынча йөзле, киң маңгайлы егет телевизор экраннарыннан миллионнарча тамашачылар өчен татарча шигырьләр укый:

Чын җырларны җилфердәргә
биеккәрәк, биеккәрәк эләргә иде!

Яңача, заманча шигырьләр, кешеләрне уйландыру белән бергә, шагыйрьнең олы ниятен, төп лозунгын ачып сала торган шигырьләр иде алар. Поэзия сөючеләр бу көнне күпмилләтле совет поэзиясенә яңа шагыйрь килүен күрделәр. 23 яшьлек студент шагыйрь Равил Фәйзуллин шул көнне имтихан тотты һәм җиңеп чыкты....

Күренекле шагыйрь Мостай Кәрим әйтмешли, «Р.Фәйзуллин шигърияте – бүгенге татар поэзиясенә генә түгел, ә гомумән әдәби хәрәкәттә үзе бер вакыйга ул».

Разил Вәлиев
1978

Редакциядән:

Күренекле каләмдәшебез, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Равил Габдрахман улы ФӘЙЗУЛЛИНга 4 нче августта 75 яшь тула. Аны гомер бәйрәме белән котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез! ■

Безнең мирас №8 август 2018

Дуслыгыбыз гомерлек булды

Камил Саттаров

Татарстан халык театрларында 40 елдан артык сәнгать җитәкчесе, режиссёры булып эшләү чорында миңа халкыбызның атаклы, йөзек кашы булган язучылары, шагыйрьләре, драматурглары, артистлары, композиторлары белән иҗади дуслыкта, тыгыз элемтәдә булырга туры килде. Алар арасында Нәкый Исәнбәт, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Хәй Вахит, Шәриф Хөсәенов, Туфан Миңнуллин, Фоат Садриев, Мәхмүт Хөсәен, Мөдәррис Әгъләмов, Гөлшат Зәйнашева, Касыйм Шамил, Шәүкәт Биктимеров, Габдулла Шамуков, Дәллүс Ильясов, Рәфкать Бикчәнтәев, Заһит Хәбибуллин, Зиннур Гыйбадуллин һәм башка олуг шәхесләребезне атап китеп булыр иде.

Халкыбызның олпат шәхесләре арасында иҗат тормышымда аерым бер истәлек булып калган шәхесне ассызыклап, башкалардан аерып атап әйтәсем килә. Ул – Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мирсәй Әмир. Аның белән танышу, дуслашу бик истәлекле булды. Казан шәһәренең М.С.Урицкий исемендәге мәдәният сараенда татар халык театрының сәнгать җитәкчесе һәм куючы режиссёр булып эшләгән вакытым, үзем теләгәндә һәм вакыт калганда спектакльләрдә артист буларак та катнашам.

1975 елда халкыбыз Бөек Ватан сугышында җиңүнең 30 еллык юбилеен бәйрәм итәргә җыена. Бу бәйрәмгә багышлап, сугыш темасына һәм ул чорны чагылдырган әсәр эзли башладым, ләкин һаман күңелгә ятканы табылмый да табылмый. Шул вакытта җырчыбыз һәм халык театры артисткасы Розалия Харисова: «Камил абый, Сез Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» пьесасын укып карагыз әле, бәлки ул ошар», – диде. Миңа аны укып торасы да юк, бу пьеса буенча куелган спектакльне укучы малай вакытымда Галиәскар Камал исемендәге театр куелышында карадым. Фатыйманы – яраткан ар-

Мирсәй Әмир (уңда), Фәүзия Әмирова һәм Камил Саттаров. 1974 ел

тисткам Фатыйма Ильская, Каюмны – моңлы җырлары белән халык күңеленә үтеп кергән Зифа Басыйрова, төп герой Басыйрны остазым һәм дустым Дэллүс Ильясов уйнаганнары хәтеремдә калган.

Шулай итеп, әсәр табылды, «Тормыш җыры»н алырга булдык. Пьесаны укып чыкканнан соң, аны киң күләмле итеп куярга карар кылдым. Моңа Мәдәният сараенда бөтен мөмкинлекләр дә бар иде: Халык театрында 30-35ләп артист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Михаил Яковлевич Шульман җитәкчелегендәге 18-40 кешедән торган халык уен кораллары оркестры, татар җыр һәм бию ансамбльләре, югары белемле рәссам, Ленинград шәһәренең Репин исемендәге сәнгать академиясен тәмамлаган Татьяна Ивановна Гаммова, театрның музыка җитәкчесе, татарның беренче профессиональ баянчысы Габдулла абый Халитов, гримёр эшләрен алып баручы, «Сәйяр» труппасын оештыручыларның берсе, Татарстанның халык артисты Касыйм ага Шамил.

Шундый зур көчләр катнашында киң күләмле спектакль куярга җыенуымны директорыбыз – хөрмәтле Лидия Николаевна Белявцевага әйттем, эшне башларга рөхсәт сорадым һәм чыгымнарның шактый зур булу мөмкинлеге турында да кисәттем. «Чыгымнардан тормабыз, эшегезне башлагыз. С богом, Камиль!» – диде ул.

Рольләр бүлү башланды, артистлар күп булу сәбәпле, берсен дә эшсез калдырасым килмәде, кыскасы, һәр рольдә 2-3 состав иде.

Февраль аенда «прогон репетицияләр»не башлап җибәрдем. Бу шактый кыен эш булып чыкты. Театр артистларыннан башка коллективлар спектакль кую өстендә эшләүнең нәрсә икәнен бик сай аңлыйлар иде.

Катнашучылар күләме – 55-60 кеше, шуңа күрә мин, башта коллективлар белән аерым эшләргә кирәк, дигән фикергә килдем һәм шулай эшли дә башладым. Март башында коллективларны яңадан кушып, репетицияләр үткәрергә керештем. Шулай эшли торгач, хәзерге заман теле белән әйткәндә, нык оешкан, спектакльне югары дәрәҗәдә чыгарырга омтылган команда барлыкка килде.

Репетицияләр бик җиңел бармады, катнашучыларның барысы да дип әйтерлек Казан мотор төзү һәм Горбунов исемендәге авиация заводлары эшчеләре, инженертехник һәм башка һөнәр ияләре. Эшләре ике сменалы булганга күрә, аларның барсын да берьюлы җыярга бик авыр була торган иде.

Күп кенә кыенлыкларга карамастан, репетицияләр бик күтәренке рухта һәм уңышлы үтте. Киләчәк спектакльнең темп-ритмы да яхшырды, образларның сурәте дә барлыкка килә башлады, декорацияләрне рәссамыбыз профессиональ дәрәҗәдә әзерләде, ул чорга яраклашкан костюмнар да өлгерде.

Премьераны 1974 елның 23 мартына билгеләдек, коллектив белән киңәшкәннән соң, авторның үзен – Мирсәй Әмирне дә чакырырга булдык. Бу эш режиссерга йөкләнде. Язучылар берлегеннән Мирсәй абыйларның адресын алдым да алар торган Маяковский урамындагы 23 нче йортка юнәлдем. Бераз гына каушый-каушый, фатир ишегенең кыңгыравына бастым. Озак көтәргә туры килмәде, ишекне бик пөхтә киенгән тыйнак кына апа ачты һәм кем икәнемне сорады. Мин Мирсәй абый янына килүемне әйттем. Ул икенче бүлмәдән Мирсәй абыйны чакырып чыгарды. Тиз генә үземнең Урицкий исемендәге мәдәният сараеның халык театры режиссеры икәнемне һәм аның «Тормыш җыры» пьесасын сәхнәләштерүемне җиткердем. Мирсәй абыйның йөзе яктырып китте һәм ул: «Нигә бу пьеса беркайда да куелмый, әсәрдә күтәрелгән темаларның актуальлеге беттеме икән, дип күптәннән бирле уйлап йөри идем. Ул сезнең үзешчән театрмы?» – диде. Мин: «Әйе», – дип җавап бирдем. Премьерага чакырырга килүемне һәм транспорт кирәк булса, машина җибәрә алуыбызны белдердем. Моңа каршы: «Пре-

мьера алдыннан Сезнең мәшәкатегез болай да күп була, Фәүзия апагыз белән без үзебез төшәрбез», – дигән җавап ишеттем.

Мәдәният сараенда аларны каршы алдым, Мирсәй абыйларның монда булганнары юк икән, кызыксынып, безнең бик матур мәдәният учагыбыз белән танышып йөрделәр.

Спектакль беткәч, Мирсәй абыйны сәхнәгә чакырдык, ул зал тутырып килгән өчен иң элек тамашачыларга, аннары артистларга һәм режиссерга үзенең бик зур рәхмәтен җиткерде.

Мирсәй абый фикер алышу вакытында спектакльдән бик канәгать булуын белдерде. Аңа спектакльдә оркестрның уены, халкыбызның күп кеше катнашындагы күмәк уеннары ошаган икән. Шулай ук ул артистларыбызның башкару осталыклары турында да уңай фикерен җиткерде.

Китәргә җыенганда Мирсәй абый миңа: «Камил, бу спектакльне Галиәскар Камал театрында куярга кирәк. Әгәр сиңа театрны бирмәсәләр, үзем сөйләшермен», – диде.

Мин Камал театры директоры Рәшидә Җиһаншина янына ашыктым. Ул, театрның планын карап: «Сезгә 15 апрельдә театрны бирә алам, ләкин бик әйбәт әзерләнегез, моңарчы безнең театр сәхнәсендә үзешчәннәрнең чыгыш ясаганнары юк иде диярлек», – дип җавап бирде.

Камал театры сәхнәсендә уйналачак спектакльгә бик ныклап әзерләнә башладык. Репетицияләр көн саен диярлек бара. Аерым артистлар да, коллективлар да зур җаваплылык тоеп иҗат итәләр.

«Тормыш җыры» спектакленә билетлар сатылып беткән булып чыкты. Моңа яхшы оештырылган реклама һәм Мирсәй абыйның халык арасындагы зур авторитеты да ярдәм иткәндер.

15 апрельдә 19 сәгатьтә Урицкий исемендәге мәдәният сараеның халык театры залны шыгрым тутырган тамашачыларга Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» спектаклен күрсәтергә әзер иде. Менә өченче кыңгырау, оркестр увертюраны уйный, ыспай буйлы, сөйкемле һәм чибәр Басыйр моңлы тавышы белән җырлый башлый.

Басыйр җырлап та бетерми, сәхнә артына, минем янга Рәшидә апа атылып килеп керә һәм бер генә сорау бирә:

– Камил, каян алдың син бу оркестрны?

Мин аңарга:

– Мәдәният сараебызда төрле җанрларда иҗат иткән коллективлар эшли, шулар арасында бу оркестр да бар, – дим.

– Халык театры оркестр белән уйный, ә без – Академия театры сәхнә артында Рәис

Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» спектакленнән бер күренеш. 1974 ел

Мирсәй Әмир спектакльдән соң Камил Саттаровны һәм артистларны котлый. 1974 ел

Сафиуллинның баянда уйнавына спектакльне куярга мәҗбүрбез. Барам иртәгә үк Обкомга, Вәлиевкә (КПСС Өлкә комитетының идеология буенча секретаре. – *К.С.*) барам.

Һәм барган да. Шуннан соң инде бераз вакыт үткәч, Галиәскар Камал исемендәге академия театрында Фуат Әбүбәкеров җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры барлыкка килде һәм хәзерге көнгә кадәр бик уңышлы эшләп килә. Шулай итеп безнең халык театры Академия театрында оркестр эшли башлауга үз өлешен кертте. Мин моңа бик шат. Мирсәй абыйның көндәлегеннән бер язма тәкъдим итәсем килә:

«16.IX-74. Санаторий «Десна».

Кичә – 15.IX-74 – Казан белән сөйләштек. Ләйлә, Гөлшат (Ләйлә белән Гөлшат – Мирсәй Әмирнең кызлары. – *К.С.) яңа гына «Тормыш җыры» спектакленнән кайтканнар иде. Әлеге – Урицкий культура сарае каршындагы халык театры Академтеатр сәхнәсендә уйнаган. Халык тулы иде, спектакль матур булды, тамашачы бик яхшы каршы алды, диделәр».* «Тормыш җыры» спектакле телевидение аша тапшырылды. Ул, Казан шәһәре һәм районнары мәдәният йортларында куелып, тамашачы тарафыннан һәрвакыт җылы каршы алынды, алкышларга күмелде. Безнең халык театры бу спектакль белән Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышланган Бөтенсоюз фестивалендә катнашып, лауреат исеменә лаек булды.

Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры» пьесасына 1984 елда тагын әйләнеп кайттым. Бу юлы колхоз рәисе Кәрам Гарипович Гарипов үтенече буенча, Актаныш районыннан «Богады» авылы театр коллективы белән, бераз яңартып, Җиңүнең 40 еллыгына багышлап куйдым. Спектакль Актаныш районының театр коллективлары арасында үткәрелә торган конкурста беренче урынны алды һәм Казан тамашачысына да күрсәтергә лаеклы дип табылды. 1984 елның июль аенда актанышлылар аны В.И.Ленин исемендәге мәдәният сараенда күрсәттеләр, татар радиосына яздырдылар һәм «Тормыш җыры» спектакле радионың «алтын фонды»на керде, күп тапкырлар тапшырылды.

Искитмәле тыйнак, кешелекле, талантлы Мирсәй абый Әмир белән «Тормыш җыры»н сәхнәләштергәндә башланып киткән дуслыгыбыз гомер буена дәвам итте. Быел гыйнвар аенда Мирсәй абыйның тууына 111 ел тулды. Аның белән аралашкан һәм иҗат иткән гомер мизгелләре истә, һаман да истә! ■

Безнең мирас №8 август 2018

МУСА ҖӘЛИЛ
(1906-1944)

Муса Җәлил.
1930 нчы еллар

Бөек Ватан сугышы башлангач ук, 1941 елның июлендә шагыйрь Муса Җәлилне гаскәри хезмәткә алалар. Башта ул Казан гарнизонында хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге хәрби сәясәтчеләр әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә алманнар якынлашкач, курслар Татарстанның Минзәлә шәһәренә күчерелә. Укуны

Муса Җәлил.
1941 ел

Каһарман-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл

1941 елның декабрендә тәмамлап, 1942 елның февралендә өлкән политрук Муса Җәлил Мәскәү аша фронтка озатыла. Ул Төньяк-Көнбатыш фронтта урыс телендә чыга торган «Отвага» («Батырлык») исемле газетаның алгы сызыктагы хәрби мөхбире итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә, Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, хезмәттәшләре белән бергә чолганышта калып, Муса Җәлил каты яраланган хәлендә фашистлар кулына эләгә.

Лагерьда шагыйрь «Идел-Урал легионы»на языла. Бераздан шуның эчендә яшерен оешма төзелеп, фашизмга каршы көрәш башлана. Ләкин 1943 елның августында яшерен оешманың эше ачылып, аның әгъзалары кулга алына. 1944 елның февраль аенда Җәлилгә һәм башка көрәшчеләргә (барысы да татарлар) Дрезден шәһәрендә хөкем оештырыла. Хәрби мәхкәмә аларны, «дәүләткә каршы җимерү эше алып бару»да гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә Муса Җәлилнең һәм аның ун көрәштәшенең гомере өзелә.

Тоткынлык шартларында күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен Муса Җәлилгә, вафатыннан соң, 1956 елда «Советлар Союзы Герое» дигән исем бирелә, ә әсирлектә тудырган шигъри иҗаты – бөтен дөньяга мәгълүм «Моабит дәфтәрләре» СССРның ул вакыттагы иң зур бүләгенә – Ленин премиясенә лаек була.

«Моабит дәфтәрләре» – Җәлил шигъриятенең иң югары ноктасы. Моабит шигырьләрендә шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйланулары аша кеше рухының бөеклеге, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына тирән ышанычы, туган халкына чиксез мәхәббәте гаҗәеп тәэсирле, хисле көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә.

Рузәл Мөхәммәтша *әзерләде* ■

1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 том/ төзүчеләре Рәис Даутов, Равил Рахмани. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. – Б.512-513.

Безнең мирас №8 август 2018

Батыр йөрәкле Зәйнәп

Ильяс Салихҗан

Заманалар... Һәрчак ирләр ярдәменә мохтаҗ булган йомшак табигатьле ханымнарыбыз да таң калдыра хәзер. Бигрәк тә эшмәкәрлек дөньясы мавыктырып харап итә үзләрен. Морадына җитәчәгенә тәмам мөкиббән китеп, хатын-кыз икәнлекләрен дә онытып җибәрәләр кебек. Тавышы кырысланган, үзе әмер бирергә гадәтләнгән һәм ирләрчә чалбар киеп киң адымнар белән җилдерүче гүзәл затларны күргәч, барыбер шик-шөбһә тумый калмый: бу авыр тормышны ялгызы гына күтәрә алырмы икән соң алар?!.

Көлемсерәвебез юкка, җәмәгать! Үткәнебезгә күз салсак, ышанмау тарлыгын ертучы мисалларны күп очратырбыз. Кыю хатыннарыбыз тирән эз калдырган тарихыбызда. Хәзер Яшел Үзән районына кергән Олы Шырдан авылында туып үскән Зәйнәп язмышын гына алыйк. Сүзем Социалистик Хезмәт Герое, ике тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнгән Зәйнәп Садыйк кызы Садыйкова турында.

Аның эштә күренә башлавына инде алтмыш елдан артык вакыт үтеп китсә дә, халык яхшы хәтерли. Телдә әле ул һаман атаклы «Зәйнәп». Риваять итеп сөйлиләр аның кылган гамәлләрен Идел-Зөя буенда гомер сөрүчеләр. Менә шул истәлекләрдән торган хикәятемне «Безнең мирас» журналының хөрмәтле укучыларына тәкъдим итәм.

НӘФРӘТ ҺӘМ КӨРӘШ

1

Олы Шырдан авылында ил карты дип олылап йөртәләр Садыйк абзыйны. Дин белемен укытып кына яуламаган ул мир абруен, аның акыллы-зирәк киңәшче булуын да истә тота халык. Табигать тазалыкны да мул биргән үзенә. Гаярь иргә күп кенә Сабан туе мәйданнарындагы хәлиткеч көрәшләрдә тиңнәр табылмаган.

Һәм менә көтмәгәндә бәла: Садыйк абзыйны паралич зәхмәте, яшен суккандай, ике аяксыз итә. Әмма бирешми мәгърур карт. Утырып-ятып кына тора алган гарипкә әйләнсә дә, рухы сынмый аның. Укытуын, киңәш-белем бирүен дәвам итә ул. Хак Тәгалә сүзләре аеруча тансыкка әйләнә барган утызынчы еллар бит бу.

Садыйк абый картлыгын шулай урынга береккән хәлендә каршылый. Тормышта аңа җәмәгате һәм кызлары ышанычлы таяныч була. Кызларыннан уңалар Садыйковлар.

Кечесе – Зәйнәбе бар яктан да әтисенә охшап үсә, диләр. Унбер яшьтән колхоз эшендә ныгый башлый ул. Кыюлыгы белән әтисенә тарткан бусы уку-язу һәм гыйлем өйрәнүдә дә үрнәккә куярдай тырыш була. Зирәк кыз инде уналты яшендә авыл Советы сәркатибе эшен күтәрә. Менә шушы җитди вазыйфа яшьли җаваплылыкка өйрәткәндер дә аны.

Сугыш башлангач, Зәйнәпне колхоз рәисе итеп сайлап куялар. Районнан килгән вәкил, үзегез кемне тәкъдим итәсез, дип сорагач, күбесе хатын-кыздан торган җыен:

– Зәйнәпне! – дип тавыш бирә.

Кызый тәвәккәл холкы белән дә танылып өлгерә авылда. Тыйнаклык пәрдәсенә төренеп каршы килми үзе дә. Шулай да, эшкә керешкәнче, атасы һәм анасының фатихасын ала әле. Өйдәгеләр уңай фикер әйткәч, җиң сызганып эшкә керешә.

Ай-һай авыр елларга туры килә аның чыныгулары! Егерме яшь тулып кына килә бит әле рәискә бу чакта.

2

Зәйнәп менә шулай көчле ихтыярлы ирләр генә күтәрә ала торган хезмәт кырына аяк баса. Игенчелек эшен оештыруның никадәр катлаулы икәнлеген үзе җир сөреп тир түкмәгән кеше күз алдына китерә алмастыр, мөгаен. Гомумән, егерме яшьлек кызның уй-хыялларымы инде бу, дип сәерсенүчеләр дә табылыр әле.

Узган гасырның кырыгынчы еллары күпкә аерылып тора шул безнең чордан. Ул заман кешеләрен аңларга теләп уйланганда, нигәдер, бер документаль фильм искә төшә.

Утызынчы елларда Мәскәүдә узган физкультурачылар парады күрсәтелә анда. Рәтрәт булып тезелеп атлаучы егетләр-кызлар Кызыл мәйданны тутырып килә. Озын буйлы, үзләре трусик-майка гына кигән яшьләр, билгеле, гәүдәгә сокланырлык тазаматурлар. Ә менә йөзләрен катырып куйган җитди кыяфәт гаҗәпләндерми калмый: бу сылу гәүдәле япь-яшь кешеләргә таш-корыч кырыслыгы каян килә соң?!

Җавабы исә – шул фильмны төшерү максатында, ахры. Без – дошман чолганышында, Ватанны сакларга әзер бул, янәсе. Заманында өстенлек иткән рәсми тәрбия җимешләре бит инде алар.

...Зәйнәп рәислеккә җиң сызганып керешә, әмма нибары бер көз генә җитәкчелек итеп ала күмәк хуҗалык белән. Язмышы һич көтелмәгән якка борылыш ясый.

Япь-яшь кызның баш булуын кемнәрдер ошатмый, күрәсең. Кемнәрнедер әрләндерә Зәйнәпнең эшчәнлеге. Шикаять язып, аны кулга алдырталар. Басуда иген урганнан соң коелган башакны җыю – мәҗбүри эш тәртибе. Менә шуны оештырмады, дип, районга язып җибәрә көнчеләре. Аз да түгел, күп тә түгел: илне икмәксез калдырырга теләгән дошман булып чыга Зәйнәп.

Каты кагыйдәләр хөкем сөргән еллар. Суд оешып, җәһәт кенә карарын да чыгарып өлгерә. Илгә зыян салган өчен – 10 ел төрмә! Кырда башак калдырганмы-юкмы – анысы билгесез. Кешене ирегеннән мәхрүм итәргә дигәндә, хөкемдарга яшертен язылган әләк тә җиткән.

Бәла ялгыз йөрми, диюләре хак икән – Зәйнәпнең газиз ире яу кырында ятып кала. Яшьләр өйләнешеп бер ай торуга ук сугышка алган булалар аны. Менә шул кайгылы хәбәрне – кара кәгазьне дә суд карары белән бергә тоттыралар. Җәзалый белгәннәр кешене диктатура җәлладлары!

Ничек кенә күтәрә алгандыр ул кинәт ишелгән кайгыны? Яшь йөрәккә шулай хәсрәт өстенә хәсрәт өсти мәрхәмәтсез язмыш!

Бөтенләй көтмәгәндә китереп суккан мәкер камчысы шулай да Зәйнәпне аяктан ега алмый. Зиндан усаллыгы берәүләрне сытып-сындыргандыр да, ә Шырдан кызына ул чираттагы сынау кебек. «Безне дошман чолгаган – авыр көрәшкә әзер булыгыз!» – дип тәрбияләнгән бит ул!

...Зәйнәпне кәнсә эшләрен белүе һәм матур язуы коткара. Хәтта төрмәдән чыгарга да ярдәм итә шул осталыгы.

Иртән тоткыннарны эшкә куган чагында:

– Садыйкова, алга чык! – дип, аерып алып кала торган булалар аны.

Сыек шулпа белән генә көн күргән тоткыннарны хезмәтнең иң авырына тыкканнар, билгеле. Шуңа күрә төрмә кәнсәсендә кәгазь кыштырдатучы Зәйнәпнең хәле җир белән күк арасыдай аермада җиңелләшә.

Төрмә башлыгы язу-сызуны яратмый, исәп-хисапны һәм чут салуны аңламый торган хәрби була. Зәйнәпнең бәхетенә, кырыс холыклы бу адәм исәп-хисап дөньясында яхшы йөзгән кешегә аерым бер хөрмәт белән карый. Тора-бара ул аннан апелляция бирү хәйләләрен дә өйрәнә.

Зәйнәп, хөкемнең яла ягуга корылуын аңлатып, тиешле оешмаларга гаризалар яза. Кулында кәгазь-каләм булгач, үзенекенә ирешә үҗәт кыз. Ышануы да кыен: 1941нче елда 10 елга хөкем ителгән Садыйкова эше кабат тикшерелә! Кара көз булуына карамастан, тикшерүче, авылга килеп, басуда башаклар да эзләп карый хәтта. Колхозчылардан сорау алына. Менә шулай җентекләп исбат ителә җинаять кылынмавы.

3

Күп тә үтми, Зәйнәпне ирек кояшы кабат кочагына ала. Нинди зур бәхет икән ул кысан төрмәдән соң иксез-чиксез зәңгәр күкне күрүләре!

Әйтергә кирәк, камера ишеген ачып: «Садыйкова, җыен!» – дигән күңелле хәбәрне зарыгып көтүе апасына язылган хатларында күп очрый. Әйе, Плэтән төрмәсендә утырганда апасы белән хәбәрләшүе аның хәлен күпкә җиңеләйтә. Яшь кеше күңеленә таш зиндан кысанлыгы бигрәк тә ят нәрсә. Моң-зарлары, туганнарын, туган йортын сагыну һәм әләк белән йөргән дошманнарына карата нәфрәт хисләре белән тулган битләрне көнаралаш җибәреп тора ул. Кайберләрендә шигъри юллар язылуы әлеге хисләренең көчлелеген дәлилли:

Явыз дошман, кара, гел хаксызга
Илтеп тыктың мине зиндан кочагына!

Нахакка яла ягучыларны күралмавы аны көрәшкә әйди. Үч алу теләге Садыйк кызын хокук саклаучылар рәтенә бастыра. Төрмәдән чыгуга ул, гаделсезлеккә каршы сугышам, дип, милиция мәктәбенә укырга китә. Максатына ирешү нияте аны шулхәтле дәртләндерә ки, Зәйнәп хәтта туган йортына да сугылмый, туры Алабугага китә. Туганнары берара үзен югалтып та торалар әле.

Милиция курсанты формасын кигәч кенә кайтып төшә авылга Зәйнәп. Шырдан халкы таң кала: төрмәгә утыртылган Садыйк кызы – үзе милиционер!..

Өйгә кайтуына бер сөенсәләр, формасына тагын бер куана якыннары. Әнисе Нәфисә абыстай гына өнәми бу яңалыкны. Чалбар киеп, билне каеш белән буып, мылтык асып йөрү – кыз-хатын фигыле мени, янәсе.

Әтисе тиз бирә ризалыгын. Тәвәккәл кызның үз сүзендә торачагын яхшы аңлый карт. Әнисе каршылыгын исә замана үзе җиңә, дисәң дә ярый. Сугыш еллары бит. Хәрби кием кигән хатын-кызлар авылда да күренгәли башлый. Нәфисә абыстай, ниһаять, кызының милиционер булу теләге белән килешергә мәҗбүр була.

Дошманнары аптыраштта кала. Ун елга хөкем ителгән кешенең төрмәдән шулай тиз кайтуы мөмкин хәлмени?! Әле бит мескен тоткын бишмәтендә дә түгел, кызыл погонлы өр-яңа формада үзе! Үзләренә нәрсә янавын чамалый алмыйлар әле алар.

...Тиздән, район идарәсендә эшли башлагач, үчен ала Зәйнәп.

Әләк белән йөрүчеләрнең берсе Шырданда салым агенты булып хезмәт итә. Туган авылындагы хәлләрне яхшы белгән Садыйк кызы моның районга җибәргән исәп-хисаплары белән танышып тора. Ялганнарын җитәрлек туплагач, ниһаять, Шырданга килә.

Авыл советына халык җыелган чагында, тегене дә чакырталар. Зәйнәп аны, килеп керүгә, сугып ега.

– Кабахәт! Кеше талап баеп ятасың, җир бит! – дип, азган хатынның алтын балдакларын, йөзекләрен, колаксаларын йолкып ала.

Бу мәйханәгә шаккаткан халык егылганны яклап бер сүз дә эндәшми. Салым белән заем авыл халкы өчен иң зур золым булган еллар бит бу. Җитмәсә, үз файдасын да кайгырткан икән комсыз агент. Малыңны күбрәк язам, дип, кеше куркытып баеган хатынны документлар белән фаш итә Зәйнәп. Үзе өстеннән йөрүчеләрнең берсен ул менә шулай, авылдашлары каршында хурлыкка калдырып, кулга ала.

4

Милиционер Зәйнәп Садыйкованың эш башы икеләтә кырыслык кыскан чорга туры килә. 1942 нче ел – сугыш һәм диктатура еллары. Укуын тәмамлагач, Норлат районына (хәзер бу зур авыл Яшел Үзән районына керә) оперуполномоченный (оператив хезмәткәр) итеп билгеләнә ул. Ничек тота алган икән соң егерме бер яшьлек хатын андагы тәртипне? Мондый хезмәткә каты холыклы инсан гына чыдый алыр кебек бит.

Ипи чиратын гына алыйк. Башкаларны кешегә санамыйча кибет ишегенә чиратсыз ыргылганнарны тыярга, ай-яй, нинди көч-куәт кирәк! Менә шул чакта:

– Зәйнәп килә! – дигән сүз комсызлар әрсезлеген сүрелдерә алган.

Халык арасында абруйлы кешегә әйләнеп, бик тиз таныла ул. Гаделсезлеккә каршы чын-чынлап көрәшүен беренче көннәреннән үк чамалый норлатлылар. Карточкага тәтегән икмәк кисәге белән көн күргән каты-коты еллар бит. Ачлык кискенләштергән кешене. Үз өлешен алып калыйм, дип, кибет янына җыелганнар арасында кемнәр генә юк. Кешене таларга да күп сорап тормаганнар анда, пычакка-пычак килеп кызып китүләре дә мәгълүм.

Кан коюны булдырмас өчен, кибет янына, гадәттә, милиционер җибәрелә. Әмма формалы егетләр дә баса алмый кайвакыт андагы киеренкелекне. Ә менә Зәйнәп килсә, халык иркен сулыш ала торган була. Кемнең кем икәнлеген тиз аера белгән шул милиционер хатын. Ызгыш-талаш яратканнарны буйсындырырга ихтыяр көче җиткән аның.

Кыю һәм белеп эш итә Зәйнәп кануннар сагында. Ул бит гади участковый милиционер гына түгел – оперуполномоченный! Норлат идарәсендә хезмәт итеп, капитан дәрәҗәсенә күтәрелә. Дәүләт бүләкләре дә тынгысыз тәртип саклаучыны батырлыкларга дәртләндергәндер, мөгаен. «Кыюлык өчен» медаленә лаек булган эшен Норлатта әле дә хәтерлиләр.

5

...Сугыш елларында хатын-кызларны урман кисәргә, торф чыгарырга читкә җибәрә торган булганнар. Бу як авылларыннан да күп җыялар кыз-хатынны ул авыр эшләргә. Эш түгел лә – җәза ул! Их, ят җирләрдә интегүләр!.. Чучка мае белән пешерелгән кәбестә шулпасын капмаганнар алар. Ачлыкка, авыр эшкә чыдый алмыйча качып та кайткалаганнар мескенкәйләр.

Бермәлне менә шундый качкыннарның Зөя буенда җыелып ятуы ишетелә. Төркем булып оешып йөриләр дигән хәбәр дә килеп җитә район идарәсенә. Качкыннарны тоту бурычы Садыйковага йөкләнелә.

Ходаем, якыннарын да сәламләргә куркып, елга буенда ышык тапкан ул бичараларны җинаятьче дип әйтергә тел дә әйләнми! Ләкин оперуполномоченный өчен алар – канун бозучылар. Һәм ул үзенең бурычын: «Афәрин, Зәйнәп!» – дип әйтерлек итеп, җиренә җиткереп үти.

Тегеләрнең эзенә ул тиз төшә. Күбәйгәч, куркуларын онытып, өерләре белән авыл буйлап йөри башлаган була алар. Зөя буендагы таллык-урманнар арасына сыенган авыллар качкыннарга бигрәк тә уңайлы, билгеле.

Зәйнәп аларның кичен кайсы өйдә җыелачакларын белеп ала да, хәйлә кора. Иң мөһиме – шушы төркемне оештыручы кызны – елга буендагыларның атаманын эләктерү. Моның өчен ул ирләр киемен киярге уйлый. Һәм менә ул – күз явын алырдай чибәр яшь солдат! Кичкә таба «солдат» авылга юнәлә.

Кызлар ул көнне аулак өй ясый. Авылга кунакка килгән солдат егетне уенга керт-миме соң инде яшь-кыркын! Шул кичәдә аңа ирләрнекенә охшаш калын тавышлы бер кыз күз сала. Бүтәннәренең дә күзләрендә ымсыну ялтырый ялтыравын, әмма тегене узарга кыймыйлар. Әмер бирергә яратуын да чамалап, Зәйнәп аның нәкъ менә эзләнгән башлык булуын сизенә.

Атаман кыз «егет»тән калмый. Биегәндә дә Зәйнәпкә генә баса. Парлап бөтерелгәндә исә, яшеренми-тартынмый елыша. Ниһаять, берсендә, шыпырт кына мунчага дәшә...

Караңгы мунчага керүгә, кыз «солдат»ны котырынып коча, назлый башлый. Кинәт кенә аерылып, үзенең өс киемнәрен салып ташлый. Ир назына сусаган җитлеккән кыз «солдат»ның бил каешына үрелә. Ашыга-кабалана аны ычкындыргач, гимнастерка сәдәфләренә тотына һәм... мәлҗерәп төшә.

Зәйнәп тә артист түгел – яшьтәшенең ашкынулы-тупас кочуларыннан, үбүләреннән баш-акылын югалтмыйча көчкә тыелып кала. Әгәр шунда тегесе гимнастеркасын салдыра алса, ничек бетәр иде операция?! Ә бит кызның кайнар сулышы «егет»не дә сыгылып төшәрдәй итеп йомшата. Атаманның хискә бирелеп януы гына коткара хәлне.

Милиционер хатын яшерелгән пистолетын көч-хәл белән тартып чыгара да атып җибәрә. Бу – сигнал! Мунчага солдатлар бәреп керә һәм чишенә башлаган хатыннарны эләктереп, олауга чыгарып бәйли. Кемнең кем булуы идарәгә кайткач кына ачыклана. Аулак өйгә җыелган бүтән качаклар да НКВД ятьмәсенә эләгә.

6

Хәтәррәк вакыйгаларда да югалып калмый Зәйнәп. Берсендә, коралланган дезертирны кулга алырга туры килә аңа. Шул ук Зөя буендагы авылларның берсендә сугыштан качып кайткан бер адәмнең яшеренеп ятуы беленә. Пистолет белән масаюы да кисәтелә донесениедә...

Ничек тотарга аны? Оперуполномоченный Садыйкова башкарырга тиеш була бусын да. Форма киеп турыдан-туры барып керүдә мәгънә аз – качакны куркытуың бар. Зәйнәп, уйлый торгач, үзенең хатын-кыз киемнәрен кияргә була. Теге авылга иртән иртүк киләләр. Шунда җитәрәк, иптәшләрен таллык арасында калдыра. Батыр хатын авылга үзе генә юнәлә.

Сак булырга кирәк, әлбәттә. Чиккә җиткәч, дезертирның коралга тотынуы бик ихтимал.

Эләксә, үзенә нәрсә янавын яхшы белә бит ул. Шуңа күрә погонлы формасын гади күлмәккә алыштыра да инде Зәйнәп. Чит кеше булса да, хатын-кыз шик тудырмас әле. Һәрхәлдә, беренче күрүгә сагайтмас кебек.

Хәйләсе барып чыга. Хәвеф-хәтәрсез таба донесениедә күрсәтелгән йортны. Тик, өйгә керим, дип, ишекне тартса, ул эчтән бикле. Тапкыр милиционер:

– Ашка җыясыбыз бар иде, зинһар, таба биреп торыгыз әле! – дип кага ишекне.

Кытлык хөкем сөргән заман. Савыт-саба сорап күрше-тирәгә йөрү гадәти хәл. Йорт хуҗабикәсе кем шакуын да белешеп тормый – ишекне ача. Зәйнәп аны-моны әйтмичә генә эчкә уза. Әмма качкын уяу икән: почмакта посып яткан җиреннән сикереп торып чормага ыргыла. Зәйнәп аның артыннан ташлана. Түбәгә менеп аягүрә басуы була, теге явыз атып та җибәрә. Пуля ике боты арасыннан үтә. Кайнар табигатьле Зәйнәпне инде бернәрсә дә туктата алмый: икенче тапкыр атканчы килеп җитеп, тегенең башына пистолеты белән ора. Качкын егыла. Кыю хатын аны култык астына кыстырып төшә.

Сугышка бармыйча өендә посып яткан егет кисәге менә шулай мәсхәрәгә кала. Канун бозучыны тоткан чагында күрсәткән тапкырлыгы һәм кыюлыгы өчен капитан Садыйкова медаль белән бүләкләнә. Медаль белән бергә ул пуля тишкән шул күлмәген дә ядкарь итеп саклый.

Зәйнәп Садыйкованың Норлат район (элек район үзәге булган бу зур авыл хәзер Яшел Үзән районына керә) милиция бүлегенең оператив хезмәткәре булып эшләгән чагы. 1942 ел

7

Сугыш бетүгә, хокук саклаучыларның эше җиңеләйде, дип әйтеп булмый әле. Кыюлык таләп иткән хәтәр хәлләр чыгып кына тора. Шырданлылар шундый бер вакыйганы яхшы хәтерли.

Кече Шырданда (рус авылы) берәүнең авылдашларын җәберләве районга да ишетелә. Кеше белән гел исәпләшми икән кабахәт. Теләсә кемне кыерсыта, кыйный. Кайберәүләрне хәтта җәзалап интектерә... Сугыштан соң авылда явызга каршы торырдай ипле ирләр аз кала шул. Үзенә тиңнәр булмагач, тәмам аза бу.

Шырдан халкы, зар елап, милиция идарәсенә мөрәҗәгать итә. Килә Зәйнәп. Районга дәшүләрен тәртип бозучы үзе дә ишетеп өлгерә, күрәсең. Урамда күзгә-күз очраша болар. Формалы Зәйнәпне күргәч, теге ирәя генә. Милиционер – хатын-кыз, үзе – ялгыз... бирешәме инде ул аңа?!

– Әллә мине кулга алырга килдең? Син?! Ха-ха!.. – дип, әрсез адәм уйнаклый-кылана башлый һәм: – Мә тот! – дип, якын килә.

Менә шул таркаулыгыннан файдаланып, тәвәккәл хатын аны бер тибүдә аяктан ега. Һәм тыны кысылып сыгылып төшкән мактанчыкның ике кулына богавын да салып куя. Ялгыз хатынның шулай курыкмавына аптырап та өлгерә алмый кала җиңелгән бәндә.

Милиционердан бер башка калкурак әзмәвердәй ирне арбага салганда аңа авыл хатыннары да булыша. Бөтен Кече Шырдан гарык булган хәшәрәткә нык эләгә дә инде шулчакны...

Юлга чыккач, теге ялына башлый:

– Кул авырта, богавыңны бераз бушат әле, якташ!..

Зәйнәп йомшамый һәм дөрес итә. Инде Норлатка җиткәч, ысылдый әзмәвер:

– Ну, кызый, бәхетеңә, богавыңны иркенәйтмәдең! Шушы кулларым белән буып үтерә идем үзеңне!..

Көчсезрәкләрне җәберләп азган бу адәм үзенең кулга алыну хурлыгын һич кенә дә күтәрәсе килми. Ничек инде, бөтен авылны биетеп торткан гаярь ирне хатын-кыз җиңсен, имеш! Ни гаҗәп, әмма бу – чынбарлык.

Хәер, милиция офицеры Садыйкова катлаулы җинаятьләр ачып та танылган. Юкка гына халыкта: «Моның очына Зәйнәп кенә чыкса чыга инде!..» – дигән сүз риваять булып таралмаган бит.

Ахыры бар ■

Безнең мирас №8 август 2018

Истә, һаман да истә!

Рәссам, график Фәйзрахман Әминовның туууына 110 ел

Рәссам, график, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСРның атказанган рәссамы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Фәйзрахман Габдрахман улы Әминов** 1908 елның 10 августында Татарстаннан читтә – Пермь губернасының Көңгер шәһәрендә туа.

1930 елда Пермь сәнгать техникумын уңышлы тәмамлый.

1933 елда Ленинградта эшли башлый. Шул чорда Бөек Ватан сугышы каһарманнары портретларын күпләп ясый.

1960 елда, Габдулла Тукай әсәрләренә нигезләнеп, акварель белән байтак әсәрләр иҗат итә. Гомумән, рәссамның күпчелек әсәрләре Габулла Тукай образын киң яктырта:

«Сак-Сок» (1972);

«Салкын чишмә» (1970 нче еллар);

«Тукай – Кырлайда» (1970 нче еллар);

«Шүрәле урманы» (1970 нче еллар).

1984 елның 20 ноябрендә вафат була.

Хәрби һәм сәяси эшлекле, дипломат Хөсәен Мәүлетовның туууына 125 ел

Хәрби һәм сәяси эшлекле, дипломат, гәҗит мөхәррире, РКП(б)ның Пермь губерна комитетының татар-башкорт секциясе мөдире (1918-1919) ***Хөсәен Мәүлетов*** (Хөсәен Баһаветдин улы Мәүлетов) 1893 елның 17 августында Казан губернасының Чистай өязендә туа.

1937 елның 30 октябрендә һәлак ителә.

*«Гаҗәеп үзенчәлекле һәм сирәк очрый торган хәл: 1924 елның сентябреннән алып 1935 елның маена кадәрге гаять катлаулы чорда Кызыл Байраклы Кавказ армиясе штабының Разведка бүлеген дүрт татар – хәрби разведка генералы Минзакир Әпсәләмов һәм хәрби разведка полковниклары Һади Маликов, Миргазиян Крыймов, Хөсәен Мәүлетов җитәкли. Соңгы өч ел ярым буена шул вазыйфаны башкарган ике Сугышчан Кызыл Байрак ордены кавалеры, чыгышы белән Чистайдан булган Хөсәен Баһаветдин улы Мәүлетов – 1935 елның маеннан 1937 елның августына кадәр яңа оешкан Кавказ арты хәрби округында Разведка бүлегенең беренче башлыгы. Казан педагогы Роман Гузенфельд ассызыклаганча, ул чакта «хәрби разведкадагы сәләтле һәм үрнәк офицерларның берсе, озакламый хәрби званиесе күтәрелүен көткән полковник Хөсәен Мәүлетов Разведка идарәсе җитәкчесе Берзинның уң кулы була». **(Гузеньфельд Р.Л.** Кем был Хусаин Мавлютов? // Казанские ведомости. – 2016. – №51. – 14 апр.).* ■

ӘЗ-МӘЗ ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Равил Шәрәфи

Бөтен юклы-барлы усаллыгымны эшкә җигеп, «Чыгып китегез моннан!» – дип кычкыруымнан соң, йә чыннан да комиссия булып утыручылар залдан чыгып китә яисә үземне куып чыгаралар, дип уйларга да өлгермәдем, дәррәү купкан көлү тавышларына гаҗәпсенеп башымны күтәрдем. Комиссиядәгеләрнең һәммәсе дә көлә иде. Арада Шириаздан ага барысыннан да уздырып, өстәлгә иелә-сыгыла көлә. Зур күзләреннән хәтта яшьләр дә тамып-тамып ала иде. Аның бу йогышлы көлүе мине дә эләктереп алды. Куып чыгаралар хәзер дигән шик-шөбһәләр чигенә төште, авызымны колакка кадәр ерып үзем дә шаркылдап куйдым. Шириаздан абый, көтмәгәндә җитдиләнеп: «Ярый, Шәрәфиев, коридорга чыгып тор!» – дип боерды. Коридорда кабат күңелемә курку шуып керде. Авыл хуҗалыгы институтына алмаулары химия кебек җитди нәрсә аркасында булды, ә монда бит бөтенләй юк нәрсә белән яндым түгелме, дөрес итеп кычкырасы гына иде бит инде, югыйсә... Шириаздан абый хәтта кыяфәтләрен бозып мине коридорга куды. Әгәр: «Бу адәм көлкесеннән кеше чыкмас, эзенә көл сибеп калыгыз», – дип тә әйтсә?.. Искәртмәстән минем кырыйга бер яшь кенә артист килеп басты да: «Шириаздан абый сине яраткан», – дип куйды.

Гаҗәеп шатлыклы көн иде бу. 22 яшь кешене гомерләре буенча озатып барачак уртак шатлык белән бәйләп куйган истәлекле көн. Һәр очраган танышың Мәскәүдә укыячак бәхетле җан, дип изге теләк теләгәндә үзеңнең язмышыңдагы бу борылышны

Дәвамы. Башы журналның 4 нче (2018) санында.

тирәнрәк аңлыйсың. Сине инде завклуб һәм китапханәчедән тапшыртасы отчетның җәй буена сузылачак исәп-хисап эшләре дә алай ук борчый алмый. Ә бит юкса күпме кешедән китапларны җыеп аласы әле. Әнә алар гербаущик (вербовщикның безнең авылда бозып әйтелгән сүзе) Рәшит кулында гына да ничаклы. Үзе бит ул әллә кайлардагы Комсомольск-на Амуре шәһәре кебек җирләрдә бутала. Ай-һай тотнаксыз да кеше инде, фән телендә андыйларны, эксцесс хисләр иясе, диләр. Ул инде икенче класста ук «чикри-микри» дигән аңлаешсыз сүзләр кычкырып, укытучыбыз Разия апага «типкән» иде. Озак-озакка авылдан югалып торса да, тотып кире кайтарылганнан соң да әле, авылыбызның керәшчесе Нотыф абыйның улы Габделфәртне ияртеп тагы билгесез тарафларга китеп барды. Әнә шул кыланышы өчен бугай, аңа «гербаущик» дигән кушамат такты авыл халкы. Ни кызганыч, китә-кайта йөрсә дә авыл белән араны бөтенләйгә өзеп бетермәде – минем башыма бәла булып, бик күп китапларны җыеп китте. Китап санын тутырыр өчен, сугыштан инвалид булып кайткан дәү абыемның шәп тышлы, өр-яңа, әле ачып та каралмаган Сталин китапларын илттем. Авыл советы рәисе, бик аптырап: «Сталин фаш ителгәч, син бит үзең әнә бөтен авыл халкын җыеп XX съезд карарларын укыган идең, димәк, бу китаплар тыелырга тиеш», – дип караса да: «Китапларны тыю карары чыкмаган бит әле», – дип хәйләләп, китапханәнең җитмәгән китаплары санын тулыландыра алдым.

Икенче көнне үк ишегалдыбызга Хәлим Җәләлов җигеп биргән ат килеп керде. Нәни абыем мине арбага утыртып, Рыбныйдагы (Балык Бистәсе) пароход тукталышына илтте. Тормыш безгә акчаны кысып тотарга өйрәткәнгә, һәр тиен исәптә, иң арзан билетны иң түбән класстан алып, юлга чыктым. Күңел бик нечкәргән иде, туган ягым күбрәк күренсен өчен, шапор-шопыр кызулый башлаган пароходның иң биек урынына (өске палубага) күтәрелеп, минем пароходны чит якларга куып алып китүче Кама-Чулман елгасына карап тордым да, тиктомалдан елап җибәрдем. Елап туйгач, кесәмнән күз, борынымны сөртергә дип кулъяулыгымны тартып чыгардым. Аңа ияреп чыккан пороход билетымны җил шундук эләктереп алып, һавада күп тапкырлар әйләндереп-тулгандырып алгач, кирәкмәгән чүпне атып бәргәндәй, кайнап-быгырдап торган елгага ташлады. Инде елап туйган булсам да кабат еларлык хәл иде бит бу. Пароходтан чыкканда тикшереп штраф салсалар, нишләрсең?! Тикшерми калалармыни соң инде бездә, иң артка калып посып кына чыгарга маташсам да, тотып алдылар бит. И Казан, нурлы Казан, тимә инде ярлы татар малаеңа! Әй ялынам тикшерүчеләргә, әй сөйлим ничек билетсыз калуларымны. Әллә сөйләгәнемә ышандылар, әллә кыяфәтемнең мескенлеге кызгандырдымы, шөкер, штрафсыз да җибәрделәр. Мәскәүгә баручыларны озатырга кеше күп җыелган иде. Үгет-нәсыйхәтләрне, яхшы теләкләрне бөтен уку елына җитәрлек итеп алып, Советлар Союзы гимны астында башкалабыз Казаннан икенче башкалабыз Мәскәүгә кузгалдык. Икенче башкала, дисәм дә беренче дигәнебез башкала идеме соң? Миңа калса, аларның аермасы чын машина белән уенчык машинаныкы кебек. Уенчык машина чын машинаның күчермәсе булса да, чын машинаның бер генә эшен дә эшли алмый лабаса. Аннары Казан ябык шәһәр булуы белән дә әле бик күпне югалткан иде. Элек Герцен-Искәндәрләрне сокландырган Казан бүген инде хәрби заводларга урын бирергә мәҗбүр булып, бер ташландык кына шәһәр булып яшәп ята иде.

Ә менә безне алда чын башкала көтә. Анда бик-бик биек, очлары болытларга терәлгән Сталин йортлары да бар, дип сөйләгәннәре искә төшә.

Поездның радиосы гимн астында: «Наш поезд подходит к столице нашей Родины – Москве», – дип, безнең күтәренке күңелләрне тагын да күтәрә. Без инде 22 генә кеше түгел, 23 булганбыз икән. Юл буе гармун уйнап барган егетебез (Минзәлә артисты) Әхтәм Зарипов та безнең арада икән. Аны имтихансыз алырга булганнар.

Безнең мирас №8 август 2018

Малый театрның «Макбет» спектаклендә халык күренешләрендә катнашып йөргән чаклар. Уңда – Равил Шәрәфи

Мәскәүнең Казан вокзалына килеп төшсәк, без укыячак Щепкин училищесының берничә хатын-кызы безне көтеп тора. Шулар арасыннан берсе миңа чәчәк бәйләме бирде. Бу чибәребез Галина Петровна Аржапова икән. Соңыннан ул безнең «Актер осталыгы» кафедрасы укытучысы Владимир Константинович Смирновка кияүгә чыгып, Смирновага әйләнде. Бу яраткан укытучымны зурлап, училищены тәмамлаган көннәрдә үзем дә аңа матур чәчәк бәйләме тапшырдым.

Ул көннәргә кадәр әле ерак. Әлегә шул Казан вокзалыннан чыгып трамвайга утырдык та «Рига» вокзалы артындагы Трифоновская урамына килдек. Без яшәячәк тулай торак бик иске, ике генә катлы, диварлары ярылып-кубып беткән сары төстәге бер барак булып чыкты. Менә сиңа мә, бөтен дөнья ярлыларын ашатып һәм дә әлеге ярлыларга дошманнары кемнәр икәнен аңлатып, буржуйларга каршы көрәшү юлларын өйрәтеп, миллионлаган акчалар да биреп яшәүче илебезнең башкаласында шушындый да мескен, ярлылыкның соң чигенә чыккан урыннар бар икән бит! Үч иткәндәй, безне башкалага озатып җибәрүчеләрдән берәү әйткән сүзләр искә төште: «Сез анда биек-биек йортларда, очлы башлары болытка терәлеп торган Сталин йортларында яшәгәндә безне дә онытмагыз, яме, кунакка йөрешербез!»

Кызларыбыз – унау, егетләребез 13 кеше идек. Кызларыбызны илаһи-уптым бар-

Курсташлар

сын бергә бер бүлмәгә урнаштырдылар. Ә малайларны, икегә аерып, 6 һәм 7 кешелек бүлмәләргә керттеләр. Мин 7 кешелек бүлмәгә туры килдем.

Студентлар телендә Трифоновка дип йөртелгән бу тулай торакта – шыксыз баракта гомеребезнең иң күңелле мизгелләрдән торган өч ел ярымы узды. Кайларда гына булмадык та,ниләр генә күрмәдек. Иң әүвәл Мәскәүнең үзәген «Авыл хуҗалыгы күргәзмәсе» дип йөртелгән гаҗәеп матур комплекска тоташтырган «Проспект Мира» урамы белән таныштык. Мәскәүнең үзендә яшәү-уку турында димим, «бер тапкыр гына булса да барып күрәсе иде» дип хыялланган кеше алдында, Петр I патша әйткәнчә, «Олы дөньяга тәрәзә» ачылды.

Әйе, хәрабәгә әйләнеп барган бу тулай торак бик тиз арада үзен яраттыра алды. Ничәмә-ничә милләтнең безнең шикелле ул һәм кызлары тереклек итте анда. Гел аралашып тордык. Барысы да күз алдында үтә. «Союзный республикалар»дан килгән яшьтәшләребезнең мулрак тормыш белән яшәүләре дә безне алай ук көнләштерми. Нишләмәк кирәк, автономный гына бит безнең Татария. Кухняга кергәч, күпне күрмәү генә кирәк. Вермишель-фәләнеңне тиз генә маргаринда кыздырып, бүлмәңә «выж, Галләм» итмәсәң, әлбәттә, создаш республикалардан килгән яшьләрнең чаш-чош китереп пылау пешерүләренең шаһиты да буласың, андый чакта авызыңа сулар килә инде. Хәер, аңардан ни зыян, әлеге авызга җыелган сулар, маргарин гына салынган вермишелеңне дә ярты юлда калдырмыйча, кирәк җиргә кадәр шудыртып төшерә. Маргарин гына ягылган ипиеңне дә чын сыер мае белән ашагандай итә. Хельсинкида яшәүче бер татар кызы: «Май бик киммат!»– дия иде. Ә без, союздашлар ярдәмендә, авызга тулган сулар белән нефтьтән туган маргаринны да чын майга әйләндердек. Сәбәбен үзбәк, таҗик һәм башкаларның пылау пешерүләре ярдәмендә әйткән идем. Нишләптер, Рига вокзалы мәйданындагы зур кибеттән бер илле грамм колбаса яки 25 грамм сыр алганнар онытылып тора икән. Күрәсең, бу җәннәт ризыклары безнең

авызга бик сирәк эләкәннәндер. Сирәк булса да эләккән бит, шөкер! «Училищегызда буфет булмадымыни?», – диярләр. Дөрес, аннан ике өлеш винегрет белән бер чәй алгалый идек. Әмма без Әзһәр Шакиров белән күп очракта арзан ашханә эзләп йөрдек. Таптык та! Ул елларда, рәхмәт яугыры, Н.С.Хрущев ашханәләрдә ипине бушка ашату кагыйдәсен кертте. Һәм без Әзһәр белән әлеге ашханәдә бер стакан гына чәй алып, кечкенә дуңгыз баласы чаклы батонны бөкләп корсак бүлтәйтеп килеп чыга идек. Җәмгысы 3 тиенгә! Әлбәттә, икебез ике почмакка барып утырабыз, шулай иткәндә генә кеше башына бөтен бер батон тия. Өстәлләргә ипи куючы апа гына: «Бер стакан чәйгә бер батон булканы сыптырып куясыз, һич булмаса, бер стакан компот алыгыз инде», – дип аптырата. – Аңа: «Бик алыр идек тә, апа, безне дә кызыктырган компотың 6 тиен тора шул», – дип җаваплый идек.

Компот эчә алмасак та, культурага мәхәббәт тәрбияләүче остазлар безне Мәскәү буенча бөтен җирдә йөртәләр иде. Кызыл мәйданнан башладылар: Ленин-Сталин мавзолеенда да, Степан Разинның башын чабып өзгән таш бүкән кырында да, Василий Блаженный дип йөртелгән искиткеч матур, чалмалы манаралары белән балкып утырган храм кырында да... И-и, хозур, ничаклы байлык, матурлык бу Мәскәүдә! Красный сүзенең икенче бер мәгънәсе дә бар икән – урыс красный сүзе белән матур дигән сүзне дә аңлата икән. Болай булгач, Казандагы Большая Красная да Зур Кызыл урам дип тәрҗемә ителмәскә тиештер. Юкса, безнең татарның «наданлыгын» күр инде, Зур Кызыл дип тәрҗемә ясаган. Зур Кызыл, дигәч, бер дә матур дигән сүз килеп чыкмый ләбаса! Әллә ниткән шикле нәрсәләр аңлатырга тиеш түгелдер бит инде ул Большая Красная дигәннәре!

Инде училищедагы хәлләр турында язарга да вакыт җитте. Беренче тапкыр җыелгач, укытучыларыбыз белән таныштырдылар. Михаил Николаевич Гладков (ул чакта әле доцент кына) һәм профессор Лидия Ивановна Дейкун (анысы да актер осталыгы буенча укытачак иде) бездән этюдлар эшләтә башладылар. Дөресен әйтәм, этюд эшләүне бик яратып бетерми идем. Этюд эшләү – безнең хезмәттә бик җаваплы адым. Этюд эшләп күрсәт, Шәрәфиев, дигәч, беркавым каушап торуым да бу эшкә үтә җаваплы караудан иде. Кинәт кенә башыма сарык суеп күрсәтү уе килде. Сарык суюю күренеше ул бит инде авыл баласының күңеленә кечкенәдән кереп урнаша. Аны тоту мәшәкатьләрен, өч аягын бергә бәйләп, берсен иректә калдыруларны һәм бөтен шартын китереп бугазын чалу күренешләрен төнлә уятып сорасалар да әйтеп бирә бит инде авыл баласы! Этюдта мин белгәннәрдән бер генә деталь дә төшеп калмады, инде корбан тәкәсен хәләл итеп чалып башымны күтәреп укытучыларыма карасам, Лидия Ивановна агарыбрак калган чыраендагы күзләрен чытырдатып йомган килеш каткан да калган.

– «Я закончил, – диюмә каршы күзләрен ачмый гына башын аска иде дә, бер мизгел тын торганнан соң:

– Ты такой молодой и такой жестокий! – диде. Димәк, ул минем ни эшләгәннәремне сүзсез хәрәкәтләрем аша да күрә-аңлый алган. Этюдның төп бурычы шул бит инде. Ә кемнәрдер моны бүгенге истәлекләрендә башкача юрарга тырыша. Янәсе, Шәрәфинең иелә-бөгелә болганып йөрүләренең ни-нәрсә аңлатканын карап утыручыларның берсе дә аңламаган. Имеш, Равил Шәрәфинең этюд эшләргә осталыгы җитмәгән. Мин шаянрак кеше булгач, шаяртып сөйләргә дә яраткач, минем турыда теләсә нәрсә ялганласаң да ярый, дип уйлыйлар күрәсең. Шаян кешене дә рәнҗетергә ярамый бит, җәмәгать!..

Ахыры бар ■

Безнең мирас №8 август 2018

Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге

Җырлар артыннан илләр гизеп...

(Фольклорчы көндәлегеннән)

Эльмира Каюмова

КУКМАРА, САБА ЯГЫ

2014 елның көзе. Коеп яңгыр ява. Октябрьнең салкын көннәрендә мин Кукмара һәм Саба якларында музыкаль фольклор үрнәкләрен туплап йөрим. Билгеле ки, фәнни сәяхәт өчен җәйнең матур чаклары күпкә уңайлырак. Ни өчен шулай соңга калынды, дисезме? Чөнки 2014 елны миңа берсенә генә түгел, хәтта дүрт экспедициягә чыгарга туры килде! Июнь башында – Арча районы һәм Мари Иле Республикасының Мари-Төрек районына, июнь азагында – Апас төбәгенә, сентябрь аенда – Алексеевск районына һәм, ниһаять, октябрьдә – Кукмара, Саба якларына.

Туңып-өшеп йөрсәм дә, кешеләрнең йөрәк җылысын тоеп тордым. Кызыклы шәхесләр белән очрашулар, аларның төпле фикерләре, киләчәгебез турында борчылулар күңелемдә тирән эз калдырды...

Э.Каюмова (уң як кырыйда) Саба районының Урта Нырты авылы башкаручылары белән

Дәвамы. Башы журналның 5 нче (2018) санында.

Габдрахманова Әнисә Сәмигулла кызы (1938 елгы) әнисе чиккән күкрәкчәсе белән. Әнисе – Мортазина Зәйнәп Галләм кызы (1916 елгы). Кукмара районының Югары Арбаш авылы

Рәгыйпова Рәсүлә Равил кызы (1947 елгы) – мөнәҗәтләр башкаручы. Кукмара районының Төркәш авылы

Кукмара районының Төркәш авылы. Бу – Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең директоры Фәнзилә Хәким кызы Җәүһәрованың туган җире. Тарихи чыганаклар буенча, Төркәш авылы XVII гасырда барлыкка килгән. Халык сәнгатенә килгәндә, биредә элегрәк *Чупләмле, Наза, Түгәрәк уен, Капкалы, Кәрия-Зәкәрия, Биш парлы, Бармаклы* һ.б. җырлы-биюле уеннар таралган булган. 1987 елда иҗат ителгән бәетен дә язып алырга насыйп булды. Әсәрне Шәмсетдинова Миңлебикә (1930 елгы) үзенең этисенә багышлап, өчесен үткәргән көнне үк чыгарган. Шул бәеттә традицион җырларга хас сүз алымнары, сурәтләр чагыла:

Тәкәнеш больницасына
Көн дә барасым калган,
Күз керфекләрем талганчы
Озак карыйсым калган.

Туган якның тәмле була
Әче катыклары да,
Әти, кад[е]реңне белмәдек
Исән вакытларыңда.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Тәрҗемә,
Төрле вакытлар булгандыр,
Әтием, (э)рәнҗемә. <...>

Өстәлләрдә сары лимон,
Сары май, дисез мәллә?
Мин чит җирләрдә яшәгәч,
Сагынмый, дисез мәллә? <...>

Безнең авыл – зур авыл,
Килә кыйбладан давыл.
Бәлки соңрак җиңелрәк булыр,
Бүгенге көн бик авыр.

Китәм инде, китәм инде,
Китсәм – кайт[а] алмам инде.
Алтын канатыбыз сынды,
Сабыр ит[ә] алмам инде.

Кисәм каен, кисәм каен,
Кисәм каеннар гына.
Каеннар да башын ийгән,
Минем кайгыларыма.

Яшь гомерне уза, диләр,
Узганын күр[ә] алмадым.
Зиратларга төшеп мендем,
Әтине күр[ә] алмадым.

Аклы ситца күлмәккәем
Уңа торгандыр инде,
Һәркемдә дә бер хәс(е)рәт
Була торгандыр инде.

Саба районының Олы Нырты авылы мәчете

Музыка коралларыннан исә, хәзерге вакытта сирәк очрый торган мандолинага тап булдым. Муллина Кәүсәрия апа (1950 елгы), мандолина кылларын чиртеп, халкыбызның яраткан «Каз канаты», «Ай, былбылым», «Әпипә» һ.б. көйләрен өздереп уйнады. Әлеге коралның 1973 елда Ленинград шәһәрендә ясалуын, бәясе 11 сум булуын сакланган этикеткасыннан укып була[1].

Кукмара районының **Югары Арбаш** авылында «Дусай көе»н гаять моңлы иттереп күмәкләшеп башкардылар. Бу җыр тирә-юньдә бик данлыклы, борынгы җырларның берсе санала. Аны әүвәл егетләр күпләп (10-30 кеше) җыелып җырлап, урам әйләнәләр иде. Мортазин Хәлил абзый (1948 елгы) әйткәнчә, җырлап баралар да, аннары берсе бөтен көчен биреп: «Әлә-ләлә-ләлә-ләлә-ләлә-ләлә-ә-ә-ә-ә-ә!» – дип кычкырып җибәрә. Кәефләр күтәрелә, шуннан соң тагын җырлап баралар. Араларында 3-5 гармунчы. Урам тулып килә иде. «Дусай көе»н Саба районының Урта Нырты, Язлы Арташ авылларында

Гәзизуллина Тәгъзимә Шәмсимөхәммәт кызы (1941 елгы) янында Шәһвәлиев Йосып Мөхәммәтвәли улы (1939 елгы) җиз телле Бараксин гармунында уйный. Саба районының Урта Нырты авылы

[1] Муллина Кәүсәрия һәм гомумән мандолина турында тулырак мәгълүматны «Безнең мирас» журналының 2017 елгы 11 нче санында (Б.96-97) карый аласыз. – Ред.

Нәбиуллина Нурсама Миңнегали кызы (1929 елгы) – мөнәҗәтләр башкаручы. Саба районының Урта Нырты авылы

Саба районының Килдебәк авылы музее экспонатлары

да яхшы беләләр. Мәсәлән, Шәһвәлиев Йосып ага (1939 елгы) аны җиз телле *Бараксин* гармунында уйнап күрсәтте. Нindидер сихри көчкә ия көй!

Югары Арбашта гаять үзенчәлекле шәхес – Ынта апа белән озак итеп әңгәмә кордым. Милләте буенча ул – казакъ, 1939 елда Казакъстанның Уральск тирәсендәге авылда туган. Татар егетенә кияүгә чыгып, 1962 елдан бирле Татарстанда яши. Казакъстанда татарларны нугайлар дип атаганнар. Ынта апа үзе мулла кызы, Югары Арбашта мәчет салдырган, шуңа күрә мәчет «Ынта» исемен йөртә.

Экспедиция барышында шулай ук Саба районының Олы Нырты, Килдебәк авылларында да тикшеренүләр алып бардым.

Җыр, бию, бәет, мөнәҗәт язу белән беррәттән, дини көйләргә дә бик игътибар бирдем. Корьән уку, азан, салават, тәкъбирне көйләп әйтү – музыкаль мирасыбызның аерылгысыз өлеше. Шунысы куанычлы, җирле дин әһелләре татар мәкамнәрен сакларга тырыша. Мисал өчен, Харисова Хәдичә (Төркәш), Арикеев Мансур (Олы Нырты), Хәбиров Мирзаян (Килдебәк) башкаруында ислам көйләре нәкъ үзебезчә, искиткеч матур, колакка ятышлы яңгырый. Авылдашларының күңелләренә дә хуш килә алар.

Хәзерге заманда халык иҗаты җәүһәрләре, фольклор ансамбльләре аркасында, яшәешен дәвам итә. Әгәр дә элек-электән тапшырылып килгән көйләр бүген башкарылмаса, алар кулланыштан төшеп, онытылып, югалып та бетәләр. Югары Арбаш авылында олылар гына түгел, яшьрәк буын вәкилләре дә «Чабата» биюен белә. Хәрәкәтләрен кемнән, кайчан өйрәндегез, дип сорагач, 1982 елгы Гайнетдинова Энҗе («Балкыш» ансамбленең сәнгать җитәкчесе): «Үзем дә белмим, каннымнан киләдер», – дип җавап бирде. Авыл мәдәният йортлары каршында оешкан фольклор төркемнәренә киләчәктә дә бу изге эштә зурдан-зур уңышлар телим. Фольклор учагыбыз сүнмәсен!

Дәвамы бар ■

Э.Каюмова фотолары

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АИТ *г.* – татарда исем булып та йөргән сүз (мәс., *Аитов* фамилиясендә сакланган), *гает* (*гайд* – бәйрәм) сүзенең башкача әйтелеше. Татарда тагын *Гает, Гаетбай, Гаетгол, Гаетмөхәммәт, Гаетхан, Гаетхуҗа, Гаетҗан* исемнәре дә булган. Мондый исемнәрне гает бәйрәме көнне туган балага кушканнар. «Гаетмөхәммәт» исеменең фонетик һәм диалекталь вариантлары арасында очраган *Аетмөхәммәт, Аетмәт, Аймәт, Әйтмәт* исемнәренә игътибар итик. Мондый фонетик үзгәрешләр башка төрки телләргә дә хас. Мәс., күренекле кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның фамилиясе *Айт* һәм *Мөхәммәд* исемнәреннән тора, Мөхәммәд биредә *Мамат*-ка тикле кыскарган гына. (Алим Гафуров катлаулы исемнәрдә *Мамат*-ның *Мат*-ка тикле кыскаруын искәртеп китә; бездә, мәсәлән, *Колмәт* исемле авыл бар.)

АЙ (ӘЙ) – Чиләбе өлкәсе һәм Башкортстан территориясендә ага торган елга, Уфа елгасының сул кушылдыгы. «Башкорт АССРның топонимнар сүзлеге» елга исеменең «әйле» этнонимыннан булуы ихтимал дип саный. Озынлыгы – 549 км. Аның Башкортстандагы уң кушылдыгы *Ака (Ока)* дип атала.

Әй елгасы (Башкортстан)

Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

АЙ ТӘҢРЕСЕ *бор.* – төрки мифологиядә Баш Тәңредән, аннары Йерсу һәм Һомайдан соң кече тәңреләр рәтендәге Алла («Татар мифлары» китабы, төзүчесе – Галимҗан Гыйльманов).

Халык ышанулары буенча, Ай калыкканда кычкырып көләргә, зәхмәтле урынга, шулай ук мал суйган җиргә утырырга, шакшы су чыгарып түгәргә, тырнак кисәргә, ялгыз гына мунча керергә ярамаган. Ай калыкканда изге теләкләреңне теләргә, Тәңредән бәхетеңне, тәүфыйгыңны сорарга киңәш иткәннәр.

Айны кызларның химаячесе, яклаучысы дип исәпләгәннәр. Хатын-кызлар, бигрәк тә кияүгә чыкмаган кызлар айлы алка тагып йөрергә тиеш булган.

«Борынгы төркиләр Айны вакыт белдерү өчен мөкатдәс саныйлар вә шул инсаннарның эшләренә тәэсир итә дип ышаналар иде» (Г.Баттал «Татар тарихы»). Кол Шәрифнең «Зөфәрнамәи вилайәте Казан» («Казан өлкәсенең җиңүе») дигән хезмәтеннән күренгәнчә, *«Болгар вилаяте, – җиденче икълимендә Ай тәрбиясендәдер һәм Айның яклавындадыр»*.

Мәс., тулган Айның беренче төнендәге хыял чынга аша дип өметләнгәннәр, Ай кими башлаган чорда киләчәккә ният-планнар кормаска киңәш ителгән. Ерак сәфәргә Ай тулысында чыгу хуп күрелгән. Тулган Ай вакытында туучылар озын гомерле, сәламәт булалар икән. Ир балалар гадәттә Ай тулган чорда яралалар дип тә ышанганнар. Ай кимегән чакта чәч кистерергә дә кушмаганнар, чөнки чәч коелучан була, дип уйлаганнар.

Татарлар Айның түгәрәк йөзендә (Маһруйда) көянтә чиләкле кыз (Айсылу яки Зөһрә) сурәтен күрәләр.

Айны төштә күрү гадәттә яхшыга юрала. Мәс., төшендә Ай күргән мөселман байлык һәм муллык, мәртәбә казаныр, карендәшләреннән сөенер. Тулган Ай күрү бәхетле мәхәббәт, саулык-сәламәтлек, эшеңнең уңышлы төгәлләнәчәген хәбәр итә. Яңа Айны күрү – никахка. Ай тотылганны күрү йогышлы авырулар турында кисәтә. Әгәр төштә Ай кан-кызыл төстә күренсә – сугышка һәм ызгышка дип юрыйлар.



Чыңгыз Айтматов

Йокыдагы кешенең күзенә төшеп торган Ай яктысы аның төшендә хатын-кыз сурәте барлыкка китерә, диләр. Сүрән Ай нурлары йокыдагы аң төпкелендә Айсылу сурәтен уятсалар, гаҗәп түгел.

АЙАРА – иске Ай бетеп яңа Ай туганчы булган ара. Ике-өч тәүлек дәвам итә. Шуңа күрә ай башын билгеләүдә кыенлыклар килеп чыккалый һәм кайчак, Г.Тукай үзенең «Ай башы» дигән фельетонында (1908, 20 сентябрь саны) әйтеп киткәнчә, *«Истамбулда, Казанда, Кырымда, Хиҗазда вә гайре җирләрдә ай башы якшәнбә көн, бары ялгыз Бохарада гына шинбә көн булган»*, имеш. Шушындый хәл аркасында, заманында Мәрҗани хәзрәтне дә имамлыгыннан читләштереп торганнар. Мондый очракларда яңа Ай туган мизгелне астрономнардан белешү зарур. Моңа Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) дә каршы булмаган.

Латинча – *interlunis.* ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

И.А.САХАРОВ ТУПЛАНМАСЫ

Чираттагы китаплар тупланмасы – Россиянең танылган мәгърифәтчесе, Казан уку-укыту округы инспекторы, гамәлдәге статс-киңәшче Иван Александрович Сахаровныкы (1815-1885). Ул 40 еллык хезмәт гомерен мәгариф системасына багышлый. Башта Түбән Новгородта, соңрак, 1847 елдан, Казанда эшли.

Шәһәр Думасы 1872 елда, җәмәгать китапханәсен тулыландыру һәм китап туплаудагы «бушлык»ларны киметү максатыннан, И.А.Сахаровның шәхси тупланмасыннан 508 исемдәге китапны сатып алырга 1000 сум акча бүлеп бирә.

И.А.Сахаровның китаплары шактый озак вакыт Милли китапханәнең гомуми саклау урынында «төн күрә». Революциягә кадәрге фондларны кузгатып, кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә биргәннән соң гына, тәфсилләп барлау, тәртипкә китерү башлана. Шулай итеп, 2001 елда И.А.Сахаров коллекциясе «якты»га чыга.

Хәзерге көндә ул 440 исемдәге 665 том китаптан тора. Бөтенесе дә рус телендә. Басылган дәвере – XVIII гасыр азагыннан башлап XIX гасырның икенче яртысына чаклы. Китапларның гомум саныннан 45 исемдәгесе (72 том) – иске басма китаплар, документларның берсе – XVIII гасырга, 71 документ XIX гасырга карый, 1830 елга кадәр басылган. Арадан иң «борынгы»сы 1782 елда дөнья күргән. Бу – Ж.-Ж. Руссоның



Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.



«Кешеләр арасындагы тигезсезлекнең ничек башлануы һәм ничек урнашуы хакында фикер йөртү» дигән әсәре. Сахаров тупланмасында белемнең барча тармаклары буенча китаплар бар, ләкин, эчтәлегенә караганда, гуманитар юнәлеш өстенлек итә. Тел фәненә, рус һәм чит ил әдәбиятына караган китаплар өлешенә 40 процент басма туры килә. Күләм буенча икенче урында тарихка багышланган китаплар, алар – 21,3 процент. Географиягә багышланган китаплар 10 процентны тәшкил итә. Дини китаплар 8 процентка якын. Педагогика, психология, фәлсәфә, табигать белеме, авыл хуҗалыгы, техника һәм медицинага караган китаплар 1дән 3 процентка кадәр. Сахаров коллекциясендә 30га якын нөсхә – төрле энциклопедияләр, җыентыклар, альманахлар. Заманында иң популярларыннан А.Ф.Смирдин тарафыннан 1834-1846 елларда

бастырылган өч томлы «Новоселье» («Өй туе») альманахы, 1848 елда И.И.Панаев һәм Н.А.Некрасов нәшер иткән «Иллюстрированный альманах» («Рәсемле альманах»), 1825 елда А.А.Бестужев һәм К.Ф.Рылеев чыгарган «Полярная звезда» («Төньяк йолдызы») һ.б.

Тупланманың иң кыйммәтле өлеше – атаклы галимнәр, язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләренең үзләре исән чакта нәшер ителгән басмалары. Болар утызлап санала, В.И.Даль, И.С.Тургенев, Ф.И.Тютчев, У.М.Теккерей, А.А.Фукс, И.И.Лажечников, К.С.Аксаков, В.И.Панаев һ.б.ның китаплары. Тупланмадагы биш китапка авторларының бүләк итеп бирүләре хакындагы култамгалары куелган. Дүрт очракта авторларның

култамгасы белән китаплар Сахаровның үзенә бирелгән. Библиофиллар өчен алар зур әһәмияткә ия. Култамгасын салып китапларын бүләк итүче авторлар арасында Казан университеты профессоры К.К.Фойгт һәм язучы П.И.Мельников-Печерский бар.

И.А.Сахаров җыйган тупланма аркасында безнең китапханәбез Н.К.Баженовның «Казан тарихы» (Казан, 1847), Гомерның «Илиада» (СПб., 1839) һәм XVIII-XIX гасырларда дөнья күргән башка гаҗәеп уникаль китапларга ия булды.

Төбәк тарихын яктырткан 55 җыентык Казан типографияләрендә басылган, шуларның 45е – Казан университеты типографиясендә.

Фондтагы документлар шулай ук, Казан җәмәгать китапханәсендә башланган тәртип нигезендә, номер тәртибе буенча урнаштырылган. Саклануы – аерым тупланма сыйфатында. Титул битләренә «Из книг Сахарова Ивана Александровича» дигән зәңгәр төстәге мөһер сугылган. Фонд тасвирланган, укучылар өчен һәм хезмәткәрләр өчен төзелгән барча каталогларда да чагылдырылган. Карточкалы аерым тематик-топографик каталог та гамәлдә. Каталогның электрон варианты Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Интернеттагы сайтына кертелгән. Милли китапханәдә Казан җәмәгать китапханәсенең 1878 елда басылган каталогы да сакланып калган, анда Сахаров фонды да күрсәтелгән. ■

Безнең мирас №8 август 2018

«Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем...»

Ләйлә Мөхәммәтшина

Кушлавыч авылы Казан ханлыгы чоры авыллары исемлегендә искә алына. Авыл атамасы И.П.Ермолаев хезмәтендә 1676 елның 24 июль датасы белән теркәлгән. Д.А.Корсаков җыентыгында исә, Кушлавыч авылы чишмә янына утырган, дип телгә алына. Кушлавыч турында Н.Н.Вячеслав (1878) мондый мәгълүмат бирә: «Чишмә суы һәм коры чокыр янына утырган Кушлавыч авылындагы 121 йортта 368 ир-ат һәм 342 хатын-кыз көн күргән. Анда бер агач мәчет, кибет һәм тимерче алачыгы булган». Кушлавыч авылы И.А.Износков китабында да телгә алына. Анда 120 хуҗалык булып, ислам динендәге 411 ир-ат һәм 383 хатын-кыз яшәгәнлеге турында языла. Халык умартачылык белән шөгыльләнгән. 1898 елгы исемлектә, Кушлавыч авылында татарлар яши, дип искә алына. К.П.Берстель мәгълүматларына караганда, авылда барлыгы 798 татар кешесе яшәгән. 1938 елда Кушлавычка язучы Фатих Хөсни кайта. Ул «Совет әдәбияты» журналында Кушлавычта 150 йорт барлыгы турында әйтеп калдырган. Кушлавыч авылы табигатьнең матур урынына, Габдулла Тукай язганча, тау башына салынган. Ул Красна елгасының ике ярына урнашкан һәм ике зур урамнан тора.

Габдулла Тукайның әтисе **Мөхәммәтгариф** – элекке Казан өязенең Кушлавыч авылы имамы. Ул – җиде буын муллалар нәселеннән килгән Кушлавыч авылы мулласы **Мөхәммәтгалим**нең улы. Мөхәммәтгариф 14 яшьләрендә Кышкар мәдрәсәсенә китеп укый һәм 1864 елның 30 апрелендә муллалыкка указ алып, Кушлавыч авылындагы икенче мәхәлләгә мулла итеп билгеләнә. Мөхәммәтгариф 1886 елның 29 августында 44 нче яшендә дөнья куя.

Г.Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф үлгәндә, бабасы – Кушлавыч авылының беренче имамы Мөхәммәтгалим Шәмсетдин улының, картаеп, күзләре сукырайган була. Ул муллалык вазыйфасын башкара алмый. Указлы мулла Мөхәммәтгалим, озак авырудан соң, 1886 елның 14 декабрендә 84 яшендә вафат була. 1886 елның октябрендә Куш-

Габдулла Тукай туган йорт. К.Зөлфокаров фотосы. 1912-1913 еллар

Ләйлә Мөхәммәтшина – Габдулла Тукай әдәби-мемориаль музей комплексы составындагы Тукаевлар гаиләсенең музей-йорты мөдире. Кушлавыч авылы

Красна елгасы өстеннән салынган күпер. З.Бәширов фотосы. 1990 нчы еллар

лавычка яңа мулла – Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаган **Габделхәер Габделкәримов**ны (Хәйретдин мулланы) билгелиләр. Ул – чыгышы белән Буа районының Черки-Килдураз авылыннан. 1901 елда вафат була һәм Кушлавыч авылы зиратына җирләнә. Кабере билгеле.

1901 елда Кушлавыч авылына, Олы Мәңгәр мәдрәсәсен бетереп, тумышы белән Яңа Шимбер авылыннан **Мөхәммәткасыйм Мөхәммәтгалим** мулла килә. Ул 1954 елга кадәр мулла булып тора, шул елны ук вафат була. Мулла бик укымышлы була, аны авыл халкы да бик хөрмәт иткән. Аның улы – танылган язучы **Әнәс Галиев**, кызы – Татарстанның атказанган табибы **Мәсхудә Гыйззәтуллина**.

Мөхәммәткасыйм мулла яшәгән йорт Мөхәммәтгариф хәзрәтнең күршесендә генә була. Хәзер инде ул урын янәшәсендә авылның клубы урнашкан. Г.Тукайның туган йорты нинди булганлыгын 1912-1913 елларга караган бердәнбер фотосурәттән күрергә мөмкин. Аны татар фотографларының беренчесе **Кыйвамкарый Зөлфокаров** төшергән. Мөхәммәтгариф нигезе урынында 1956 елдан бирле шагыйрьнең бюст-һәйкәле тора.

XIX гасырда Кушлавычта күренекле урынны өч бүлеме дә куе сарыга буялган, яшел калай түбәле, сары манаралы мәчет алып торган. Язучы Әнәс абый Галиев үзенең «Чигенгәндә» дигән повестенда мәчетне Казан бае салдырганлыгы турында яза. Ул бай – тумышы белән Кушлавыч авылыннан булып, бераздан Казанга күчеп, бакалея һәм икмәк, соңрак тире белән сәүдә итә башлаган **Мифтахетдин Вәлишин** (1811-1904). 1870 елдан – икенче гильдия сәүдәгәр. Диндар кеше буларак, ел да мәчет-мәдрәсәләр файдасына зур-зур иганә акчалары бирә. Мулла Иле, Атабай, Аты, Мәрҗан авылларында мәчетләр, Яңа Татар бистәсендә (сәүдәгәр Г.Х.Абдуллин белән берлектә) кирпечтән мәдрәсә бинасы төзетә, Мәрҗани мәчетен төзекләндерүгә акча тота, мәчет манарасының



Кушлавычтагы «Мулла чишмәсе». З.Бәширов фотосы. 1990 нчы еллар

түгәрәк балконын челтәрләп эшләнгән тимер парапет (култыкса сыман җайланма) белән әйләндереп алдырта. 1850-1889 елларда ошбу мәчеттә имам-хатыйп булып күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, педагог, дин галиме **Шиһабеддин Мәрҗани** (1818-1889) эшли. Башта Вәлишиннар гаиләсе Мәрҗани мәчете ихатасындагы ике катлы агач йортта яши. 1872 елда Зәкәр урамында (хәзерге К.Насыйри ур., 19а й.) кирпечтән ике катлы (архитектор Шмаков проекты буенча) йорт салып керә. Әтисенең вафатыннан соң, әлеге йорт мирас буенча улы **Мөхәммәт Вәлишинга** кала. Ләкин ул сәүдәгәрлек эшен озак дәвам итми. 1915 елда **Габдулла Кариев** чакыруы буенча «Сәйяр» театр төркеменә актер булып урнаша. 1922-1924 елларда «Сәйяр» труппасыннан төзелгән Кызыл Октябрь исемендәге беренче татар дәүләт үрнәк драма театрында (булачак Камал театры) эшли. Соңрак Әстерхан татар театрына күчә. Иренә һәм бөек шагыйрь туган авыл исеменә ихтирам йөзеннән, аның хатыны артистка Рокыя үзенә псевдонимны әллә каян түгел, Тукай туган бишектән сайлап ала: **Рокыя Кушловская.**

1930 нчы елларда Кушлавыч мәчетен, манарасын сүтеп, мәктәп итеп үзгәртәләр. Шушы бина 1987 елга кадәр башлангыч мәктәп булып хезмәт итә. Кызганыч ки, мәчет бинасы хәзерге көнгә сакланмады, сүтелде.

1951-1953 елларда Казаннан рәссам-график ханым **М.К.Мавровская** бу бинада яшәп, Кушлавычта Г.Тукай белән бәйләнешле булган тарихи урыннарны рәсемгә төшерә. Алар арасында мәчет бинасы да бар, әлеге рәсемнәр музей экспозициясе залында урын алган.

Авылда, тау астында бөек шагыйребез Габдулла Тукайның бабасы Мөхәммәтгалим нигезенә якын чишмә бар. Ул чишмәне мулла үзе карап торган. Чишмәнең исеме, Мөхәммәтгалим мулла хөрмәтенә, «Мулла чишмәсе» дип аталган.

Кушлавыч авылының хәзерге замандагы күренеше. З.Бәширов фотосы

Авыл халкы шушы чишмәнең суын эчкән. Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдә дә шул чишмәгә йөргән, нәни Габдуллаҗанны «Мулла чишмәсе»нең суы белән коендырган. Булачак шагыйребез, Кушлавыч авылыннан киткәнче, шушы чишмә суын эчеп үскән.

Озак еллар халыкны суы белән туендырган чишмә 1996 елларда яңартыла. Тик соңгы елларда авыл йортларына су килә башлагач, аңа игътибар бераз кимегән иде.

Олы җанлы игелекле шәхес, «Таттелеком» АҖ генераль директоры **Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин** һәм аның егетләре халкыбызны районыбыздагы тарихи объектларны төзекләндерү кебек изге гамәлләр белән һәрвакыт куандырып тора. Бу көннәрдә Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф хәзрәт муллалык иткән мәчет урыны алар тарафыннан яшел калай койма белән әйләндереп алынды, истәлек тактасы куелды.

Инде чират «Мулла чишмәсе»нә дә җитте. «Таттелеком» АҖ җитәкчелеге чишмәне генә түгел, Красна елгасы өстеннән салынган күперне дә алмаштырды. Авыл халкы исә үз чиратында өмә ясап, мәчет, чишмә, күпер тирәсен чүп-чардан, корыган үләннәрдән арындырды. Кушлавыч авылы халкы «Таттелеком» җәмгыяте җитәкчелегенә, бездә эшләгән егетләргә мең-мең рәхмәтле. Әлеге җәмгыять иҗади төркеменең быел алган Габдулла Тукай исемендәге премиясен сөекле шагыйребезнең туган авылы өчен тотуы – үзе үк зур мәртәбә, батырлык. Кылган игелекләре өчен әҗер-саваплы булсыннар, изге гамәлләрендә Аллаһы Тәгалә ярдәм итсен. Хәзер мәчет, чишмә тирәсе танымаслык булып үзгәрде. Ул инде авыл халкының да, кайткан кунакларның да яратып йөри торган урынына әйләнде. Бу хезмәтләргә Тукаебызның рухы да шат булгандыр.

Кушлавыч бәләкәй Габдуллаҗанга нибары дүрт ай хәсрәтсез, борчусыз гомер бирә. Ләкин әнә шул бишектә уздырган, үзе хәтерләмәгән кыска Кушлавыч чоры шагыйрь күңелендә мәңгелек илһам чыганагы булып кала. Дөньяның байтак ачы-төчесен күргән Тукай, 23 яшенә җиткәч, Кушлавычны сагынып язган «Туган авыл» шигырен искә төшереп, язмамны тәмамлыйм:

«Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер — кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем». ■

Тиздән яңа төзекләндерелгән әлеге тарихи объектларны рәсми ачу тантанасы да булачак. Бу турыда алдагы саннарның берсендә язарбыз, иншаллаһ. – Ред.

КУКМАРА МИРАСЫ

Киез итекләр иле

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

КУКМАРАДА БАШКА ТӨР ЭШМӘКӘРЛЕК ҺӘМ СӘҮДӘ ЭШЕ

Киез-киез итек басу эшчәнлегеннән тыш, ул вакытта Кукмарада башка төр кәсеп һәм сәүдәгәрлек белән шөгыльләнү дә киң таралган була. XX гасыр башында биредә сбруйчылар-каешчылар, итекчеләр, буяучылар, балта осталары, аркан-бау үрүчеләр һәм башка һөнәр ияләре дә яши.

Авылларда почта-элемтә станцияләре эшли башлый. Фабрика конторалары бер-берсе белән даими сөйләшеп торсын өчен, элемтә җайланмалары урнаштырыла.

Һәр дүшәмбедә, билгеле ки, күп санлы халык белән базар көне үткән. Монда авыл хуҗалыгы продукцияләре, әйтик, җитен һәм киндер орлыклары, атлар, мөгезле эре терлек алып килеп сатканнар. Базар мәйданында сату һәркөн дәвам иткән. Базар иртә белән ачылган һәм кич белән генә ябылган. Әгәр карап торсаң, шаккатмалы хәлгә тарыр идең: «Искитмәле кыяфәт белән йөргән рус белән бергә ашыкмыйча гына әйбер караштырган ар (удмурт), аннан бер тамчы калышмыйча йөргән хатыны, чирмешләр, ул да түгел һәммә җиргә «борынын тыгып йөрүче» – әле бөтен нәрсәне сатып алучы, әле теләсә нәрсә сатучы татарлар...»

Володиннар җитештергән товар. Кукмарадагы туган якны өйрәнү музееннан

Казан фәнни-сәнәгаи күргәзмәсендә (1890) бирелгән медаль. Ул медальгә, киез каталар өчен, В.А.Комаров, бакыр эшләнмәләр һәм аркан-баулар өчен, ике мәртәбә Н.Д.Володин, шулай ук А. һәм М.Володиннар, бертуган Родигинннар лаек була

Элгәре әйткәнебезчә, Туеш заводы эшчеләре – бакыр белән оста эш итүчеләр. Николай Дмитриевич Володин 1865 елдан оештырылган остаханәсендә бакыр эшләнмәләр ясау белән шөгыльләнгән. 1890 елда инде ул самавырлар, ләгәннәр, комганнар, мәчет манаралары өчен очлыклар эшли башлаган. Бакыр эше осталары самавыр ясауга аерым игътибар биргән. Н.Володин остаханәсендә генә дә 16 оста хезмәт куйган. Аларның уртача хезмәт хаклары 12-16 сум булган. Николай Володин эшен аның уллары дәвам иткән. «Бертуган Володиннар» дигән сәүдә маркасы астында алар бакыр һәм аркан-бау эшләнмәләр ясаганнар. Соңга таба Александр Николаевич бакыр эшләнмәләр белән генә, ә инде Василий Николаевич канатлы бау үрү эше белән шөгыльләнә башлый. А.Н.Володинның бакыр эшләнмәләре Казан фәнни-сәнәгаи күргәзмәләрендә (1890) хәтта медальләргә дә лаек була. Ул чордагы самавырларда һәм комганнарда «Югары сәнгать һәм зур хезмәт өчен» һәм «Кукмарада, Александр Володин» дигән язулар еш кулланылган.

Василий Володинның аркан-бау остаханәсе үз гаиләсе яшәгән ике катлы агач йортта урнашкан була. В.Н.Володин, моннан тыш, төрле ашамлыклар, кирәк-ярак әйберләр белән бергә, кирпеч кибете дә тоткан.

Н.Д.Володин йорты. 1990 нчы еллар фотосы

Созиннар гаиләсе

1917 елда әлеге йортка 1897 елда туган Александра Михайловна ия була. А.М.Володина 1928 елда, сайлау хокукыннан мәхрүм булу сәбәпле, эшчәнлеген туктата. Шаһитлар әйтүенчә, А.М.Володинаның ике улы да үзләре теләп Кызыл Армиягә язылган, ә үзе исә соңгы елларын Ленинградта яшәп үткәргән. «Караңгы» үткәне өчен, Александр Николаевич Володинның хатыны Юлия Корниловнаны да (1866 елда туган) шундый ук язмыш көткән була, ләкин гомере буе мөгаллимәлек иткәнлеге сәбәпле, аны сайлау хокукыннан мәхрүм итмиләр.

Кукмара авылы тарихында бер эшмәкәр ханым да бар: ул – Валентина Михайловна Коновалова (1890 елда туган). В.Коновалова ашханә, кибет һәм икмәк пешерү йорты (пекарня) тота. Ул эшмәкәр булган заманда аның кибет киштәләрендә кайнар ипи, прәннекләр, клиндерләр дә сатыла. Коноваловның оешмасы хәзерге Пугачев урамында, ә Валентина Михайловна үзе ике катлы таш йортта торган. 1918 елда аның ире, үзе теләп, Кызыл Армиягә языла, ә инде 1920 елда тимгелле тифтан вафат була. Ни кызганыч, В.М.Коновалованы да 1928 елгы ачы язмыш көтә. Җитмәсә, 1930 елда ТАССР ГПУсы «өчлеге» аны, 58-10 нчы маддә нигезендә, биш елга «хезмәт белән төзәтү лагерена» җибәрә. Кеп-кечкенә балалары исә Кукмарада Валентинаның әнисе Пелагея карамагында кала.

Ни белән генә шөгыльләнми Кукмара кешеләре! Мәсәлән, Созиннар гаиләсе атаклы «Зингер» компаниясенең тегү машиналарын сата. Ул вакытта тегү машинасы 25 сумнан алып 66 сумга кадәр торган. Башка тегү машиналары белән чагыштырганда (мәсәлән, 22,5 кг), «зиңгерләр»13,5 кг гына авырлыкта булган.

ФОТОХАТИРӘ

Сулдан уңга: җырчы Миңгол Галиев, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, «Кукмара киез-киез итек комбинаты»ның хәзерге генераль директоры Ләлә Шамил кызы Шәрипова, язучы Рабит Батулла, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин. 2017 ел

Комбинатның ашханәсе һәм кибете урнашкан бина

*Язманы **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Гамьле мирас

Филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, Төрек лингвистик җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы, Татарстан Фәннәр академиясенең гуманитар бүлеге академик-секретаре, Халыкара төрки академиянең татар бүлеге бюросы рәисе, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мирфатыйх Зәки улы Зәкиевнең 1952 елдан алып 1158 фәнни эше (1042 мәкаләсе, 116 китабы һәм җыентыгы) басылып чыга. 2015 елда исә «Мәгариф-Вакыт» нәшриятында галимнең тел гыйлеме, татар телен укыту методикасы, тел тарихы һәм социолингвистикага караган сайланма мәкаләләре тупланган китабы дөнья күргән иде. Быел, ниһаять, җиде томлык сайланма әсәрләре дә укучылар хозурына барып ирешә.

I том – «Төрки-татар теленең формалашу тарихы (европоцентризмнан адекват тюркологиягә таба)», **II том** – «Төрки-татар теленең адекват тюркологиягә нигезләнгән тарихы», **III том** – «Этноэкология таләпләрендә татар телен саклау һәм

Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев – Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры. 1986 ел

үстерү», **IV том** – «Фонетик, лексик, грамматик категорияләр һәм аларны укыту методикасы», **V том** – «Гуманитар фәннәрне үстерү проблемалары», **VI том** – «Танылган шәхесләр һәм аларның хезмәтләре», **VII том** – «Укытучылар әзерләү проблемалары» дип атала. Томлыклар М.Зәкиевнең монографияләренә, дәреслекләренә, программаларына, уку кулланмаларына, фәнни җыентыкларына кыскача аннотацияне, галимнең вакытлы матбугатта, төрле фәнни җыентыкларда басылып чыккан йөзләрчә фәнни, фәнни-публицистик мәкаләләрен тәшкил итә.

Туган телебезне, шанлы һәм фаҗигале бай тарихыбызны өйрәнүгә зур өлеш керткән олпат галимнең фәнни эшчәнлеге дәвамлы булсын, дигән теләктә калам.

Малик Хәйруллин,
филология фәннәре докторы, профессор

РЕДАКЦИЯДӘН: Мөхтәрәм галимебез Мирфатыйх Зәки улы ЗӘКИЕВкә 14 августта 90 яшь тула. Аны гомер бәйрәме белән котлап, сәламәтлек, иминлек һәм игелекле олы хезмәтендә уңышлар телибез!



Мирасворд

Урман эчендәге чәчүлек җир

Балта үткенли торган таш

Давыдов, Бакиров

Мәскәү татарларының иҗтимагый оешмасы

Йолдызнамә билгесе

... - мөлкәт

Ркаил Зәйдулла поэмасы

Нәсел агачы

Хәсәнов, Идиятуллин

Шарык поэзиясендә ике юллык шигырь

«Бер тауда ... чишмә» (Сибгат Хәким)

... малын сөйләр, ярлы моңын сөйләр (мәкаль)

Түбә түшәмәсе астына, бәнкәләргә аркылы салынучы такталар

Талкан сыман татлы чәй ризыгы

Нәбирә Гыйматдинова повесте

... - де - Жанейро

Нәсел, кан кардәшләре булган берничә буын

Борынгы кельт кабиләләре кешесе

«Намус», «Җидегән чишмә» романнары авторы

Пан ... Мун

Камыр ачыту өчен савыт

Рәт, мәгънә, җай

Алтын Урда шәһәре

Хайван аркасы

Мордва халкындагы ике этник төркемнең берсе

Көнбагыш (диал.)

Япония автомобиле

Ыкның сул кушылдыгы

Ахунов, Гобәй

Орышу, тиргәү

Әнәс Галиев романы

Урта Азия халкы

Борчылу, гамь

Әйләнә (диал.)

... - д'Ивуар (Африка иле)

Ау эте (диал.)

Камыр башы, ачыткы

Актриса ... Гәрәева

Татар халык дастаны

Хат, записка (иск.)

Перу территориясендә яшәгән югары мәдәниятле борынгы халык

Җайдак утыргычы



Рәис Габдулла төзеде.

7 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Ногман, Госман, таң, «Шомбай», игәр, Мишә, Гата, Кубрат, фирка, әзи, аймак, янычар, лур, Исәнбәт, «Мцыри», Үрсу, изен, бәк, еш, скетч, репс.
Өстән аска: ятим, шигрин, цинк, ошак, «Ыргыз», Нигъмәти, чу, Решт, Афзал, инеч, стан, Мамай, Ус, «Аң», зурат, нан, нукәр, Гәрәй, Өбрә, Азак, әсбап, рети, Уту.

Безнең мирас №8 август 2018

Ш.Маннур һәйкәле.
Авторы – Бакый Урманче.
Мамадыш шәһәре

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / август

765 ел элек (1253)

Илче, францискан-монах Гильом де Рубрук, француз короле Людовик IX исеменнән тез чүгү өчен, Батый хан янына, Алтын Урданың башкаласы Каракорымга килә.

240 ел элек (1778)

Мәскәү университеты типографиясендә рус уку йортлары өчен беренче басма татар әлифбасы (авторы – Сәгыйть Хәлфин) нәшер ителә.

195 ел элек (1823)

30 августта, 1552 елда Казанны яулап алганда һәлак булган илбасарлар хөрмәтенә Казансу елгасындагы утрауда һәйкәл ачыла.

135 ел элек (1883)

11 августта дин һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы, нашир һәм журналист Борһан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1883-1942) дөньяга килә.

100 ел элек (1918)

4 августта Казанга, Көнчыгыш фронтка, В.И.Ленинның махсус вәкиле итеп, Мулланур Вахитов җибәрелә.

6 августта ак чехлар Казанны алалар.

19 августта М.Вахитов (1885-1918) акгвардиячеләр тарафыннан атып үтерелә.

95 ел элек (1923)

15 августта Галимҗан Ибраһимов, «Безнең көннәр» романының икенче бүлеген язып бетереп, Шәрык нәшриятына тапшыра.

85 ел элек (1933)

23 августта Мәгариф Халык Комиссариаты Мәскәүдә татар театры филиалын ачу турында карар кабул итә.

70 ел элек (1948)

7 августта шагыйрь Миргазиз Укмаси (1884-1948) вафат була.

60 ел элек (1958)

Драматург Мирхәйдәр Фәйзигә Башкортстанның Баймак каласында һәйкәл ачыла.

55 ел элек (1963)

«Совет әдәбияты» журналының август ае санында Роберт Әхмәтҗановның «Йолдызстан» поэмасы дөнья күрә.

45 ел элек (1973)

«Казан утлары» журналында Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап» повесте басыла башлый.

Журналга ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■



СОДЕРЖАНИЕ. АВГУСТ 2018

Историческое наследие: «Гаухаршад». О.Иванова; «Судьба Казанского ханства». Б.Хамидуллин; «Полковник Пугачева Масагут Гумеров». В.Имамов; «Реализация татарского языка». Х.Габидуллин; «Ичкинские татары». Р.Исакаев; «Нигматулла хаджи». Р.Фахруддин; «Родство великих». Р.Нуруллин; «Мачкара – средоточие просветительства». Р.Шарафиева; «Татарский учёный, открывший Японию» (тема Японии в рукописях Абрара Каримуллина). Ф.Байрамова.

Тюркский мир: «Знатный сын чуваш»; «Чуваши». З.Башири.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов.

Литературное наследие: «Национальные и религиозные мотивы в романе Аяза Гилязова «Яра» («Рана»)». Раджап Шукру Гунгер; «Творчество, призывающее к борьбе»; «Дружба на всю жизнь». К.Саттаров.

В глубине памяти: «Отважная Зайнап». И.Салихджан.

Художественное наследие: «Немного о себе». Р.Шарафи.

Слово – украшение языка: «Словарь национальных терминов». А.Тимергалин.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Страна валенок».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. AUGUST 2018

Historic heritage: «Gaukharshad» by O.Ivanova; «The fate of Kazan khanate» by B.Khamidullin; «Masagut Gumerov is a colonel of Pugachev's army» by V.Imamov; «The problems of Tatar language's usage» by Kh. Gabidullin; «The Ichken Tatars» by R.Isakaev; «Nigmatulla hadji» by R.Fakhruddin; «The kinship of the great ones» by R.Nurullin; «Maskara village is a focus of enlightment» by R.Sharafieva; «The Tatar scientist having discovered Japan» (Japanese theme in the manuscripts of Abrar Karimullin) by F.Bayramova.

Turkic world: «The prominent son of the Chuvashes»; «The Chuvashes» by Z.Bashiri.

Religious heritage: «Islamic world» by G.Ibragimov.

Literary heritage: «National and religious motives in the novel of Ayaz Gilazov «Wound» by Radjap Shukru Gunger; «The creative work calling to struggle»; «Our friendship was eternal» by K.Sattarov.

In the deepest store of memory: «Braveheart Zaynap» by I.Salikhdjan.

Creative heritage: «Something about myself» by R.Sharafi.

The word is a decoration of language: «The national terms' glossary» by A.Timergalin.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «The felt-boots country».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

«Алтын көз». Киндер, майлы буяу

Мәхмүт Госман улы Госманов

1918 елның 25 октябрендә Кукмара районының Адай авылында туа.

1938 елда Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлый.

Бөек Ватан сугышы ветераны, Кызыл Йолдыз һәм II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары кавалеры.

1947 елдан – СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы.

ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1975), ТРның халык рәссамы (1980), Россиянең атказанган рәссамы (1999).

Казан шәһәрендә яшәп иҗат итеп, 2006 елда вафат була һәм Чаллы шәһәре зиратында җирләнә.

«Оргсинтез». Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Утәмешевләр гаиләсе: гаилә башлыгы Исмәгыйль Гали улы Утәмешев, хатыны Зөбәйдә Мөхәммәтҗан кызы, Түрфәндә һәм (Үзбәк) Рөстәм. 1929 ел **(Р.Мәһдиев. «Галим Рөстәм Утәмешев»)**

Рәсим Хәбибулла. Бүре кыйссасы
Рөстәм Мәһдиев. Галим Рөстәм Утәмешев
Рәфкат Шаһиев. Ризаэддин Фәхреддин кызы Әсма Шәрәф хатлары
Фәйрүзә Хисамиева. Ольга апа бәете
Альберт Хәсәнов. Әдәбиятыбыз күгендә якты йолдыз булып калды

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналына башкача язылу:
* *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
* *редакциядә*
* *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*